ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№5 (317) – МАЙ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Картлыктан
дару бармы?

Бу мәктәптә
биш телдә сәламлиләр

Солдат йөрәген
җылыткан җырлар

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Сафа Гәрәев, Ксения Сёмина, Индус Таһиров,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: Александр Ефремов

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

БӘЙРӘМ КӨТӘ

Олы футбол бәйрәме якынлашкан саен, кәефләребез күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Бигрәк тә балачакларына Дөнья чемпионатын үз күзләре белән күрү генә түгел, футбол йолдызлары белән аралашу бәхете тәтегән малайларның.

Гомумән, балаларның хыялларын тормышка ашыру – ул әкият миссиясе. Гадәттә мондый эшләр белән Кыш бабай шөгыльләнә – аның һөнәре шундыйрак. Ә инде ул берүзе генә өлгерә алмаганда, аңарга ярдәмгә волонтерлар – әти-әниләр, әби-бабайлар, ягъни балаларының сабый вакытлары барлык хыяллар да тормышка аша торган иң бәхетле чак булуын теләгән кешеләр ашыга. Мондый олылар командасы исә – көч инде ул! Казанны дөнья футболы үзәгенә әверелдерерлек көч! Һәм, димәк, бер ай дәвамында кечкенә балаларның да, җанатарлар дип аталган зур «сабыйларның» да уй-хыяллары чынга ашачак. Шуңа күрә футбол көннәрендә без дә балачакка әйләнеп кайтачакбыз – күтәренке кәеф, ягымлы мөгамәлә һәм, әлбәттә, бөтен дөньябызны биләп алган патриотизм, горурлык хисе! Чөнки үзебезнекеләр өчен үзебездә җан атабыз! Чын һәм ихлас күңелдән! Хәер, үзебезнекеләр өчен булмаса да, барыбер җан атабыз! Футбол бәйрәме кәефен үзебезгә сеңдереп калдыру өчен һәм, әгәр инде бөтен тормышыбыз әле алда икән, аны футболга багышлау, профессионал булу һәм, ватаныбызны данга күмеп, җиңү шатлыгы китерү өчен!

БӘЙРӘМ КӘЕФЛӘРЕ ТЕЛӘП, СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-1175

Басарга кул куелды: 25.05.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Илдар Вәлиуллин «Иске Әтнә».

МАЙ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. «Цифр»лы телевидение.
Безне нинди яңалык көтә

6. Озын гомерле булу серләре.
Галимнәр картлыктан нинди дару тәкъдим итә

10. Чепья мәктәбе.
Бу мәктәптә биш телдә сәламлиләр

12. Татар теле буенча халыкара олимпиада.
Японнар татар телен ни өчен өйрәнә

14. Болгарның тарту көче.
Без һичшиксез күрергә тиеш изге ядкәрләр

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18. Каюм Насыйри рецептлары.
Татарча борщ ничек пешерелгән

22. Саба районы Югары Утар интернат-йорты.
Балачакны озынайту

26. «Ак Барс» феномены.
Казан Гагарин Кубогы өчен көрәштә ни өчен җиңде

30. Кумирларыбыз.
Юдино егете ничек дөнья футболы йолдызына әверелгән

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

36. Генерал язмышы.
Әхәт Юлашевның тормыш линиясе

38. ТАССРның 100 еллыгына.
Идел–Урал штаты нигә төзелмәгән

40. Татар тарихы.
Кол Гали турында нәрсәләр беләбез

78. Сугыш җырлары.
Солдат йөрәген җылыткан көйләр

82. Нурбәк Батулла:
«Битлек»ле биюче

84. Китап киштәсе.
XXI гасыр татар прозасыниләр турында уйланырга чакыра

90. Татар авыллары.
Ары – Әтнәнең иң биек ноктасы

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

10.05

Смаил Аллауа, Алжирның РФндәге илчесе, – Казанда, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit – 2018» Халыкара икътисадый саммит ачылышы көнендә:

– Ни өчен кешеләр Kazansummitka киләә? Беренчедән, яңа идеяләр алыр өчен. Яңа партнёрлар белән очрашу өчен. Һәм моннан тыш – биредәге кунакчыллыкны тояр һәм өйләренә атаклы чәкчәкне алып китәр өчен. Мин ышанам, Казан елдан-ел халыкара аренада зуррак урын ала барачак.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

05.05

Мичел Сальгадо, ФИФА легендасы, Испания җыелма командасының һәм Мадрид «Реал»ының элекке уенчысы, – Казанда ЧМ-2018 Футбол паркы ачылышында:

– Дөнья чемпионаты – бу теләсә кайсы футболчы өчен истә калырлык вакыйга. Бу тиңдәшсез тәҗрибә. Россия өчен бу шулай ук биниһая зур тәҗрибә, ул турнирның хуҗасы булачак. Дөнья чемпионаты – ул ярыш кына түгел, гомуми бәйрәм атмосферасы да, спорт атмосферасы да, сез аны тоярсыз, дип өметләнәм.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

08.05

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты, – М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгына багышланган бәйрәм чарасында:

– Җиңү көне – изге бәйрәм, аны безгә сез – безнең әтиләребез, бабаларыбыз һәм бабаларыбызның әтиләре – бүләк иттегез. Сугыш кырларында Татарстаннан 700 меңгә якын кеше сугышкан. Безнең якташларыбыз бик күп хәрби операцияләрдә катнашкан, Җиңү хакына кырларда, фабрикаларда, заводларда һәм госпитальләрдә эшләгән. Бөек Ватан сугышы елъязмасында татарстанлыларның батырлыгы үрнәкләре мәңгегә калыр. 100 меңнән артык якташыбыз каһарманлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнгән.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Аналог»ны **НИЧЕК** «цифр»га алыштырырга

Кеше гомерен **НИЧЕК** озынайтырга

Күпмилләтле мәктәп **НИЧЕК** яши

Японнар татар телен **НИ ӨЧЕН** өйрәнә

Борынгы шәһәрне **НИНДИ** киләчәк көтә

ХУШ, «АНАЛОГ». ИСӘНМЕ, «ЦИФР»!

2019 елның гыйнвар башында Россиядә уникаль тарихи вакыйга булачак дип әйтергә була: илдә аналоглы телевидениене кушмаячаклар, киресенчә, өзәчәкләр. Шуңа күрә яраткан каналларын киләчәктә югалтырга теләмәүчеләр моңа алдан ук әзерләнә башларга тиешләр. Репортажыбыз әлеге процесста Татарстан Республикасының Радиотелевизион тапшыру үзәге белгечләренең катнашуы турында.

Автор:
Ксения Сёмина

Зәңгәрле-кызыллы-аклы логотип төшерелгән махсус киемле ир-ат авыл өе капкасының кыңгыравына баса. Капканы өлкән яшьтәге апа чыгып ача.

– Мин телеүзәктән. Яңа елдан сезнең телевизор аналоглы каналларны күрсәтми башлаячак, – дип аңлата кунак. Аны өйгә чакыралар, телевизор торган залга уздыралар.

– Безнең болай да спутниклы ТВ. Ә сез башканы тәкъдим итәсезме? – дип кызыксына йорт хуҗасы.

Техник аңлата:

– Мин аналоглы, бар кешедә дә күрсәтә торган гадәти телевидение турында сөйлим. Бер каналда – бер программа… 2019 елның башында аны өзәчәкләр. Моннан соң бушлай ТВны инде «цифрда» карап булачак. Әгәр өйдә иске үрнәктәге телевизор булса, махсус приставка алырга кирәк булачак.

– Ә спутниклы ярамыймы? Кыйммәт торамы ул?

Техник спутниклы ТВ өчен түгел, цифрлы ТВ өчен приставка кирәк булуын аңлата.

– Тагын пенсионерлар хисабыннан акча эшләргә җыенасыз! – дип сүзгә кушылып китә хуҗабикә.

– Без бит ул приставкаларны сатмыйбыз, – дип елмая техник.

– Без инде спутниклы өчен түлибез, хәзер инде сезнеке өчен дә түләргәме? – дип ачулана апа.

– Цифрлы тапшырулар өчен түләргә кирәк түгел. Дәүләт аны бушлай тәкъдим итә. Сезгә приставка гына сатып алырга туры киләчәк – бер генә тапкыр, – дип, сабыр гына аңлата техник. Ул приставкаларның күп төрле булуы, бер-берсеннән нигездә бәяләре белән аерылып торуы (500 сумнан 2000 сумга кадәр) турында сөйли. Аларның электроника кибетләрендә сатылуы турында әйтә. Ә телевизорларның яңа модельләре приставкаларны алыштыручы приёмниклар белән болай да тәэмин ителгән. Көйләүнең берниндди катлаулылыгы юк, инструкцияләрдә яхшылап аңлатылган, белгеч чакырырга кирәк тә түгел.

– Әмма тышкы, урам антеннасы кирәк булачак. Аны чарлак яисә өй түбәсе турысында мөмкин кадәр югарырак урнаштырырга кирәк булачак. Сигнал шулчакта яхшы була… Сүз уңаеннан, менә кайнар линия телефоны – безнеке һәм федераль… – Техник хуҗаларга мәгълүмат һәм контактлар язылган буклетны тапшыра.

Өйдән чыккач, техник сәгатенә күз сала. Сәгать уклары инде уникегә якынлаша, ә кичкә кадәр бөтен урамны йөреп чыгасы бар.

– Әй егет! – Каршы яктагы матур, төзек йорт капкасы янында чал башына түбәтәй кигән ныклы гына ир-ат басып тора. – Син телеүзәктәнме? Менә сезнең телевидениегез эшләми әле.

Техник өйгә керә. Хуҗа аңа ике телевизорын да, ике приставкасын да күрсәтә: берсе – кунак бүлмәсендә, берсе – аш бүлмәсендә.

Фотолар ТР Радиотелевизион тапшыру үзәгеннән алынды





– Кунак бүлмәсендә – спутниклы, аш бүлмәсендәге – эфирлы цифрлы, республика ТНВсын карар өчен мин аны пульт белән аналоглыга да күчерәм. Приставканы шунда ук алдым. Төрле бүлмәдә телевизорны яхшы сыйфатта карар өчен. Цифрлысы башта эшләде, ә күптән түгел сигнал югалды һәм күрсәтми башлады. Ничек инде алай? Спутниклысы эшли бит.

Мастер ишегалдына чыга.

– Барысы да бик гади. Цифрлы антеннаны агач каплап тора. Агач яфрак ярган да сигнал югалган. Антеннаны йортның икенче почмагына күчерергә һәм безнең телевышка ягына юнәлтергә кирәк – әнә теге якка, – мастер юнәлешне күрсәтә.

– Димәк, аналоглыны яңа елдан соң бөтенләй өзәчәкләр? Ярый әле, җирлек башлыгы, халык белән бу турыда җыелыш үткәреп, барысын да аңлатты. Минем кияү – технарь, шуңа күрә мин барлык җиһазларны алып куйдым. Ә менә башкалар, белмим, аңлаганнардырмы, – дип сөйли хуҗа антеннаны күчерүче техникка ярдәм итә-итә. – Ә ТНВ ничек? «Цифрлы»га күчәме?

Техник төбәк каналларының егерме канал исәбенә, ягъни цифрлы ТВ тапшыруларының беренче һәм икенче пакетларына (мультиплексларына) кермәве турында аңлата. Әмма лицензиясе булган ТНВ һәм башка каналлар, әгәр дә шундый карар кабул ителсә, «аналог»та эшләүләрен дәвам итә алачак. Тапшыруларны беркем дә тыймаячак.

Телевизорның күрсәтә башлавына инангач, техник рәхмәтле хуҗага мәгълүмат язылган буклетны тапшырып да урамга чыга. Шулай да бөтен кешене йөреп чыгу һәм киләсе елда туктаусыз шалтыратуларга дучар булмас өчен, киләсе яңалыклар турында хәзер сөйләп чыгу яхшырак.

Владимир Якимов, Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре филиалы «Татарстан Республикасы радиотелевизион тапшырулар үзәге» директоры:

– «Женева-06» халыкара килешүе буенча 2006 елда бу документка башка илләр белән бергә кул куеп, Россия үз өстенә аналоглы телевидениедән цифрлыга күчү белән бәйле бурычларны алды. РФ Хөкүмәте шуңа ярашлы федераль максатчан программа булдырды. Татарстан, үз чиратында, бу программаны үтәп, 2018 елда тиешле инфраструктура төзү эшен тәмамлый. Бу күчеш әлеге дә баягы мәгълүмати тигезсезлекне юкка чыгарырга булышачак: шәһәр һәм авыл кешеләре 20 цифрлы каналны карау мөмкинлегенә ия булачак, моңа кадәр шәһәрләрдә 15 канал трансляцияләнсә, авылда 2–3 кенә булган. Аналоглы тапшырулар бер ешлыкны бер каналга чыгаруны күздә тотты, шул ук вакытта ешлыклар саны чикләнгән иде. Ә «цифр» бер ешлыкка ун каналны сыйдыру мөмкинлеген бирә. Шулай итеп, хәзерге вакытта ике ешлыкка бер мультиплексның 10 каналы һәм икенче мультиплексның 10 каналы сыя. Бу – төп федераль каналлар. Телевизор караучылар өчен «аналог»тан «цифр»га күчүнең өстенлеге тапшыруларның сыйфаты – сурәтләрнең дә, сигналның да – сизелерлек яхшыруыннан гыйбарәт. Татарстан радиотелевизион тапшырулар үзәге федераль максатчан программаның операторы булып тора. Шуңа күрә без «цифр»га күчергән чакта халыкка булачак үзгәрешләр турында мәгълүмат җиткерү һәм консультатив ярдәм күрсәтү ягыннан мөмкин кадәр булышлык итәчәкбез. Безнең белешмәләр буенча, беренче мультиплекс тапшырулары Татарстанның 99% йорт хуҗалыгына ирешә (федераль программа таләбе – 95%). Без бу елда ук инде ахыргача формалашкан икенче мультиплексның да шушы ук күләмдә трансляцияләнүен көтәбез.

**Кайнар линия:
8-800-220-20-02**

**Консультацион ярдәм үзәге:
+7 (843) 200-05-28**

Чаңгыда узышу буенча ветераннар арасында 17 мәртәбә дөнья чемпионы, йөгерү буенча ветераннар арасында 12 мәртәбә дөнья чемпионы. Сүз журналыбызның гыйнвар саны герое Әхмәт бабай Сираҗиев турында бара. 90 яшьлек Әхмәт бабай үзенең төп җиңүләрен 60 яшьтән соң яулый һәм, гомумән, илледән соң тормыш әле башлана гына, дигән фикердә тора.

КАРТЛЫКТАН ДАРУ БАРМЫ?

Фото Әхмәт Сираҗиевның шәхси архивыннан

Кеше гомерен ничек озайтырга? Картлыктан саклый торган «тылсымлы таблетка» якын киләчәктә пәйда булырмы? Татарстан башкаласында узган «Гомерне озайту юллары» халыкара конференциясенә дөньяның 17 иленнән җыелган фән йолдызлары бу һәм башка сорауларга җавап табарга тырышты.

Әле 2005 елда гына да казанлылар уртача 65 ел яшәгән – күп иратлар хәтта пенсиягә дә чыгарга өлгермичә үлә торган булган. Бүген исә Татарстан башкаласында уртача гомер озынлыгы 75 яшькә җиткән, һәм бу ил буенча уртача күрсәткечтән югарырак.

Сүз уңаеннан, 1 мартта Владимир Путин Федераль Җыенга еллык мөрәҗәгате белән чыгыш ясады. Андагы иң кызыксыну уяткан санның берсе – 80. 2030 елга россиялеләрнең уртача гомер озынлыгы нәкъ менә шулкадәр һәм хәтта югарырак булырга тиеш икән.

Әгәр моңа ирешә алсак, без озын гомерлеләр яши торган илләрнең «80+» клубына керәчәкбез. Анда бүген Гонконг беренче урында бара, биредә уртача гомер озынлыгы 84 яшь тәшкил итә. Аннары Япония (83,5), Италия (83,1), Сингапур (83) белән Швейцария (83), Испания (82,6) килә. Безнең илебез исә, 2017 елда күрсәткечне 72,5 елга җиткереп үз рекордыннан өстен чыкса да, әлегә лидерлар дистәсеннән бик ерак.

ОПТИМИЗМ ӨЧЕН СӘБӘП БАР

Конференциянең модераторы – танылган алып баручы Борис Корчевников безне дистанцион сораштыруда катнашырга чакыра. Үзебезнең күпме яшәргә җыенуыбызны әйтергә кирәк. Вариантлар мондый: 70 тән азрак, 70 тән 90 га чаклы, 90 нан 100 гә чаклы яки «яңа технологияләр белән йөз яшьтән соң барысы да башлана гына әле». Мин икенче төймәгә басам һәм азчылык сафында булып чыгам. Хөрмәтле тикшеренүчеләрдә һәм аларны тыңларга килгән яшь галимнәрдә оптимизм миңа караганда күбрәк икән.

Залда җыелучыларны, шул исәптән мине дә, нәрсә соң ул картлык, дигән сорау борчый. Төрле чирләр кеше картайгач башланамы яки, киресенчә, инсанны төрле патологияләр картайтамы? Төгәл җавапның әлегә кадәр булмавы ачыклана. Альберт Эйнштейн исемендәге Медицина колледжы (АКШ) профессоры Ян Вайг әйтүенчә, картлык – ул ниндидер мистик процесс, ихтимал, аңа киләсе унъеллыкта гына төшенергә мөмкин булачак әле.

– Шулай булса да, оптимизм өчен сәбәп бар, – дип сөендерде ул безне. – Инде бүген үк кеше организмының потенциалы мәгълүм, һәм ул уртача гомер озынлыгыннан күпкә югарырак. Киләчәктә без картлыкны кисәтү механизмнарын таба алырбыз, дип өметләнәм. Бурыч – кеше гомерен 115, 150 һәм хәтта 200 елга кадәр озайту. Бу бары тик тикшеренүләргә һәм вакытка гына бәйле.

Менә, мәсәлән, иске автомобильнең сафтан чыккан детальләрен даими алыштырып торсаң, ул бит әле тагын бик озак йөри. Ә моны кешеләргә карата кулланып булмыймы икән?

– Машинадан аермалы буларак, кеше организмына мультиморбидлык феномены хас – өлкәнәйгән саен, чирләр дә кар өемедәй туплана бара, – ди Mayoclinik клиникасы (АКШ) тикшеренүчесе Джеймс Киркленд. – Һәм, әгәр сездә яшькә бәйле бер чир бар икән, тиздән икенчесе, аннары өченчесе килеп чыгу ихтималы зур. Әмма кемдер 85 яшендә дә гольф уйный, ә кемдер 45 яшендә үк әллә ничә авырудан интегә. Бу ни өчен шулай соң?

Конференция барышында бу сорауга берьюлы берничә галим җавап биреп карады. Алар барысы да кешенең чын – биологик – яше мөһимрәк дип саный, ул исә паспортта күрсәтелгәненнән шактый аерылырга мөмкин. Әйтик, Летбридж университетыннан (Канада) Ольга Ковальчук тикшеренүе нәтиҗәләре тәмәке тартучыларның (аеруча хатын-кызларның) биологик яше тартмаучыларга караганда уртача 5–7 елга югарырак булуын ачык күрсәтә. Болонья университеты профессоры Клаудио Франчески исә әлеге мәсьәләдә генетик аспект тапкан: озын гомерлеләрнең варислары үзләренең «гади» яшьтәшләренә караганда уртача биш елга «яшьрәк» икән.

Автор:
Ольга Туманская

Фото: Александр Ефремов

ИТАЛИЯЛӘРНЕҢ ОЗАК ЯШӘҮ СЕРЕ

Минем кулымда – конференциянең пресс-релизы. Анда бәхетле һәм озын гомер кичерү өчен 10 киңәш тә бар, менә аларның кайберләре. Тормышка җиңелрәк карагыз. Рәхәтләнеп көлегез. Акыл активлыгын саклагыз. Ашауда чама белергә өйрәнегез. Беренче урында – гаилә...

– Сәламәт яшәү рәвеше – гомеребезне озайту өчен без үзебез эшли алган нәрсәләр ул, – ди конференцияне оештыручылардан берсе, аның илһамландыручысы Фәния Маганова. Фәнни-житештерү фармацевтика компаниясен оештыручы буларак, ул да гомерне озайту чараларын эзли. **Картлык сәбәпләрен өйрәнеп, инде 25 ел буе озын гомерлеләрне тикшерүче Клаудио Франчески да аның белән килешә.**

– Үз илемнең күрсәткечләреннән чыгып исәпләгәндә, мин җитмеш елдан әз генә артыграк яшәячәкмен, әгәр мин Италиягә күчеп китәм икән, анда 11 елга озаграк яшәрменме соң? – дип мөрәҗәгать итә аңа алып баручы Борис Корчевников.

– Әлбәттә! – дип куандыра аны шундук галим. – Бүген Италия бу мәсьәләдә Япония белән ярыша. Без гомернең шулай озын булуы илнең географик урыны һәм климатына, шулай ук бар кешегә дә иң сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтергә сәләтле сәламәтлек саклау системасына бәйле, дип саныйбыз. Моннан тыш, бездә өлкән яшьтәгеләр өчен сәламәтлек саклауның махсус программалары бар. Италиядә туган-тумачаны картлар йортына урнаштыру оят эш санала, шунлыктан

бездә өлкән яшьтәгеләр гаиләләре белән яши һәм актив тормыш алып бара. Дөньяда иң сәламәтләрдән саналган Урта диңгез буе ризыкларын да онытмау мәслихәт!

Озак яшәүнең тагын бер мөһим факторы – галимнәр күптән «икенче ми» дип йөрткән эчәклек микробиотасы. Аңа безнең нәрсә ашавыбыз гына түгел, кайчан ашавыбыз да йогынты ясый икән. Эш циркада ритмнарында – ашказаны асты бизе, бавыр һәм башка әгъзаларыбызда, шулай ук баш миебездә бара торган биологик процессларның циклик тирбәлешләрендә. Әгәр сез билгеле бер сәгатьләрдә ашарга күнеккәнсез икән, шул тәртипне саклау зарур. Галимнәр аз калорияле диетага да кат-кат әйләнеп кайтты, ул картаюны акрынайту мөмкинлегенә бирә торган механизмнардан берсе санала.

– Без бер-ике ел дәвамында аз калорияле ризык белән тукланучылар төркемен озын гомерлеләр төркеме белән чагыштырдык һәм күп кенә параметрлар буенча аларның организмнарында охшаш процесслар баруын күрдек! – дип тикшеренү нәтиҗәләре белән уртаклаша Клаудио. Мин исә аннан «Татарстан» журналын укучылар өчен шәхсән үзенең озак яшәү серен ачуын үтенәм.

– Минем серем тормышка оптимистларча карауда. Әгәр кеше бәхетле икән, бу инде озын гомерлелеккә бер адым. Минем өчен стакан беркайчан да яртылаш буш түгел, ул һәрвакыт яртылаш тулы. Гаиләм минем бар гамәлләремне дә хуплый, һәм шушы мине һәрвакыт яшь калырга мәҗбүр итә!

ХӘТЕРНЕ ЯХШЫРТУ ХӘЕРЛЕ

Мин тизелеп киткән картиналарга карыйм – һаман көчәя барган Альцгеймер авыруыннан интегүче рәссам Уильям Утермолен берничә ел дәвамында үзен сурәтләп барган. Еллар үткән саен, сурәттәге сөйкемле ир-ат танымаслык булып үзгәрә. «Соңгы стадиядә кеше үзенең көзгедәге чагылышын танымый», – дип шәрехли күргәннәремне дөньякүләм танылган генетик, РФА Гомуми генетика институтының эволюцион геномика лабораториясе (Россия) мөдире һәм Массачусетс университеты Медицина мәктәбе (АКШ) психиатрия профессоры Евгений Рогаев. Чир җиңә, ә башкача булуы мөмкинме соң?

Альцгеймер авыруы – баш мие картаюның төп патологиясе, тайпылышы. Дөньяда әлеге чирдән якынча 46 миллион кеше интегә. Үзенең коллегалары белән Евгений Рогаев әлеге чирнең молекуляр сәбәпләрен өйрәнә. Галимнәр бу мәкерле чирне нинди механизмнар китереп чыгаруын ачыкларга тырыша. Генетика гаеплеме, әллә әйләнә-тирә мохит факторларымы?

– Аеруча ышанычлы тикшеренүләр баш мие җәрәхәтләнүенең Альцгеймер авыруына китерүен күрсәтә, – ди Рогаев. – Тагын йокысызлык, аз йоклау, озак вакытлы анестезиянең дә чирләп китү ихтималын арттыруы мәгълүм. Әмма шулай да гаилә анамнезы, ягъни генетик нәселдәнлек, шулай ук картлык җитдирәк сәбәп булып тора.

Евгений Рогаев, башка галимнәр белән бергә, Альцгеймер авыруы өчен җаваплы һәм аның тиз вә иртә (65 яшькә кадәр) башлануына сәбәпче дүрт төп генны тапкан. Тикшеренүчеләр бәяләвенчә, әлеге «чирле» геннар Европа популяциясендәге халыкның 10 процентында бар. Бу ачыш авыруны диагностикалау үсешенә этәргеч биргән. Бүген сабыйның геномы буенча аңарда әлеге чирнең 65 яшькә кадәр үк башлануы мөмкинлеген 90 процентка кадәрле ихтималлык белән ачыклап була. Тик бу нигә кирәк соң? Әлеге авыруны дәвалый торган дару һаман уйлап табылмаган булгач, бөтен кешене нигә тикшерергә? Мин бу сорауны Евгений Рогаевка бирәм.

– Мәсәлән, мондый тестны йөклелекне планлаштыру стадиясендә булган яшь парлар үтә ала. Әгәр

аларда «чирле» геннар бар икән, балаларына тапшырмас өчен, ясалма аталандыру вакытында бары тик «сәламәт» геннарны гына сайлап алып файдаланырга була.

Бүген Рогаев җентекле геном анализы ярдәмендә шактый сәламәт йөз яшьлек кешеләрне өйрәнә. Ул Альцгеймер авыруыннан сакларга сәләтле факторларны табарга өметләнә. Һәм бу сорауга җавап эзли: ни өчен кайбер кешеләр әлеге патологиягә бирешүчән, кайберләре исә бирешми? Яки ни өчен авыру нәкъ менә картайгач башлана? Әмма галимнәр моңа җавап эзләгәндә, әби-бабалары әлеге куркыныч чирдән интегүчеләрне башка нәрсә борчый: алар үзләрендә мәкерле чир башланмасын өчен, нәрсә дә булса эшли аламы?

– Бүген Альцгеймер авыруын кисәтүгә юнәлтелгән препаратлар юк, – дип җавап бирә Рогаев. – Димәк, бөтен профилактика кешенең яшәү рәвешенә бәйле. Беренче чиратта, баш миен даими күнектерергә, һаман нәрсәне дә булса истә калдырырга өйрәтергә кирәк. Шигырь ятлагыз! Сездә авыру симптомнары күренә башлаганчы, шул рәвешле ниндидер резервуар булдырырга мөмкин, бу чирне әкренләп артка чигерәчәк.

ГЕНГА ӨМЕТЛӘН, ҮЗЕҢӘ ТАЯН

Безнең каршыда ике фоторәсем. Аклы-каралысында – сөйкемле сабый, янәшәсендә мылтыклы малай, кырыйларында – бантик таккан ике кыз. Икенче – төсле сурәттә – шул ук персонажлар, әмма... туксан елдан соң! 102, 104, 107 һәм 109 яшь – бу кешеләр шулкадәр яшәгән. Бертуганнарның берсе соңгы көненә кадәр Уолл Стритта эшләгән – аның 750 миллион долларлык компаниясе булган. 104 яшьлек апасы 100 яшьлек төпчек сеңелләренең юбилеен шәхсән үзе оештырган. Шул яшендә дә ул биергә яраткан һәм икенче абыйлары белән көн саен музейларга йөргән.

– Әйе, алар тулыканлы тормыш белән яшәгән. Аларның озын гомерлелегенең төп факторы генетика булуында шикләнмисездер бит инде?! – дип тәэсирләнеп мөрәҗәгать итә залга Хайфа университетыннан (Израиль) Гил Ацмон. Аның чыгышы шоуны хәтерләтә.

Гил Ацмон менә инде 15 ел буе 100 яшьтән узучыларны өйрәнә. Галимнәр командасы белән бергә ул гомер озынлыгы өчен җаваплы 6 ген ачкан. Ацмон – озын гомерлелекнең «генетик» теориясе яклы кебек, әмма барысы да бераз катлаулырак булып чыга...

– Без өлкән яшьтәгеләрнең сәламәтлек саклауга яшьрәк үлүчеләрдән азрак акча тотуын ачыкладык. Ни өчен? Чөнки 100 дән узганнар 100 гә җитмәгәннәрдән күпкә сәламәтрәк! Без яңа төрләрнең эволюциясен күрәбез. Бик озын гомерлеләр әйләнә-тирәлеккә җайлаша, үзләренең компенсация механизмнарын үстерә.

Сүзләрен дәлилләп, Ацмон тикшеренү нәтиҗәләрен китерә. Игътибар үзәгендә – йөзьяшәрләр һәм «нибары» җитмеш яшьлекләр. Беренче төркем күп күрсәткечләр буенча сәламәтрәк күренә. Гәрчә аларның 40 проценты шулай ук артык авырлыктан интегә, шул ук күләмдә алкоголь куллана, ниндидер диета да тотмый. Араларында хәтта тәмәке тартучылар да очрый! Нигә алар озаграк яши соң?!

– Әйдәгез, аларның когнитив функцияләренә тукталыйк, – дип дәвам итә галим. – Йөзьяшәрләрдә ул нормада, аларның бик өлкән яшьтә дә аңнары ачык. Һәм тагын бер нәрсә. Алар оптимист булган, тулыканлы, чагыштырмача сәламәт гомер кичергән, ягымлы һәм киң күңелле булган, көләргә яраткан. Бәлки, гомер озынлыгын когнитив функцияләрнең сакланышы билгелидер?

Галимнең нәтиҗәсе мондый: озын гомер сере генетикага һәм әйләнә-тирә мохиткә бәйле. Өстәвенә, мәдәният һәм традицияләрдәге аерымлыклар аркасында әлеге балансның төрле популяцияләрдә төрле үзенчәлекләре бар: Япониядә бу – гел яңа әзерләнгән ризык кына куллану, Кытайда – кояш күплеге, Италиядә – Урта диңгез диетасы, Казахстанда – кымыз...

Ацмон әйтүенчә, кеше йөз яшькә җитсә, аңа башка бернәрсә дә әллә ни йогынты ясамый инде. Тик сездә озын гомер гены булмаса, ә озак һәм бәхетле яшисегез килсә, табиб киңәшләренә колак салу зарур: тартмаска, исерткечләр белән мавыкмаска һәм физик эштән курыкмаска. Кызганычка, башка уртак серләр юк – кемдер өчен файдалы булган нәрсә икенче берәүгә зыян китерергә мөмкин.

– Менә шуңа күрә бүген персоналаштырылган медицина турында күп сөйлиләр, чөнки, әгәр без әйләнә-тирәлекне һәр конкрет кешегә җайласак, 100 ел һәм тагын да артыграк яши алачакбыз.

> **– Машинадан аермалы буларак, кеше организмына мультиморбидлык феномены хас – өлкәнәйгән саен, чирләр дә кар өемедәй туплана бара, – ди Mayoclinik клиникасы (АКШ) тикшеренүчесе Джеймс Киркленд.**

Сүз уңаенда, персоналаштырылган медицинага яки «Өч П» (персоналаштырылган, превентив, предиктив) медицинасына күчү зарурлыгы турында фән йолдызлары күптән сөйли инде. Галимнәр гомер озайту ачкычын нәкъ менә шунда күрә. **Әлеге стратегия яклыларның берсе, РФА Биология институты профессоры һәм бу конференцияне оештыручылардан берсе Алексей Москалёв актив озын гомерлелек өчен көрәшкә күп елларын багышлаган, шунлыктан картаюның биология белән медицинадагы иң комплекслы һәм катлаулы проблема булуын яхшы белә.**

– Киләчәктә, картаюның ни икәнен яхшы белгән чакта, без комплекслы терапия булдыра алачакбыз. Ул персональ маркерларга, һәр конкрет кешенең шәхси профилен һәм картаю тизлеген үлчәүгә нигезләнәчәк. «Өч П» медицинасына өстенлек биреләчәк. Картлыктан саклый торган «тылсымлы таблетка» түгел, нәкъ менә ул бөтен кеше өчен картаюны шактый акрынайтырлык, бәлки әле бөтенләй туктатырлык механизмга әйләнәчәк.

Фото: Александр Ефремов

БУ МӘКТӘПТӘ БИШ ТЕЛДӘ СӘЛАМЛИЛӘР!

Балтач районында Чепья авылы бар. Биредә, бер авылда, удмурт, мари, татар, рус һәм башка милләт кешеләре яши. Авылда мәчет тә, чиркәү дә бар. Биредә башка салалар белән чагыштырганда бәйрәмнәр дә күбрәк билгеләп ителә, чөнки һәр халык үз гореф-гадәтләрен саклый. Шулай булгач, удмуртлар – татарларны, татарлар мариларны бәйрәмнәре белән котлый... Күпмилләтле Чепьяның мәктәбе дә үзенчәлекле. Анда булып, сөйкемле балалар белән аралашып, «өлгергән» проблемалар хакында сөйләштек.

Автор:
Руфия Фазылова

«ТАТАР ТЕЛЕ СӘГАТЬЛӘРЕ ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК КЫНА КАЛДЫ»

Чепья урта мәктәбендә 304 бала белем ала, 17 авылдан килеп укыйлар. Аерым авыллардан укучылар 10, 11 нче сыйныфларга гына килә. Мәктәптә алты-җиде милләт баласы белем ала. Күпчелекне удмуртлар тәшкил итә – барлык укучыларның 53 проценты, икенче урында татарлар – 37 процент, 8 проценты мари балалары һәм калганы – башка милләт балалары.

Мәктәпкә килеп кергәч тә, бер үзенчәлеккә игътибар иттем: күбесе татарча аралаша.

– Башка милләт балалары татарча каян белә? – дим мәктәп директоры Сәйдәш Нурмиевкә.

– Бездә халык бер-берсе белән нык аралашып яши. Өлкән яшьтәге удмурт, мари хатыннары татарча иркен сөйләшә. Балалар да кечкенәдән бер-берсенең телен ишетеп, өйрәнеп үсә. Аннан, мәктәптә укучы һәр бала, дәүләт теле буларак, атнасына 2 сәгать татар теле укыды.

– Ә ни өчен үткән заманда сөйлисез?

– Ноябрьнең унберендә татар теле сәгатьләре бетерелде. Хәзер һәр укучы атнасына ике сәгать туган телен өйрәнә.

Татар телен укыту тирәсендә ыгы-зыгылар башлангач, прокуратура вәкилләре Чепья урта мәктәбенә дә килгән. Укыту программаларын тикшергәннәр. Нәтиҗәдә, татар телен укыту кыскартылып, дүрт татар теле укытучысына унар сәгать дәрес калган. Укытучыларның берсе башлангыч сыйныфларны укытырга күчәчәк, моның өчен махсус курслар узган. Тагын берсе лаеклы ялга китәчәк.

– Дөресен генә әйткәндә, берничә ата-ана: «Безгә татар теле кирәкми», – дип прокуратурага хат язган, – диде Сәйдәш абый. – Быелгы уку елына кадәр татар телен дәүләт теле буларак укытуга каршы чыккан кеше юк иде. Атааналар бер-берсеннән ишетә, күрә. Укымаска да мөмкин, дигән хәбәр таралуга, безнекеләр дә кушылды. «Безнең балаларга бик авыр биремнәр бирәләр. Унтугызынчы йөз әдәбияты нәрсәгә кирәк, аны алар барыбер аңламый», – ди ата-аналар.

– Шулай фикер йөртүчеләр арасында татарлар бармы? – дим.

– Чын татар гаиләләре алай ук әйтми, әмма башка милләт, катнаш гаиләләр арасында андыйлар очрый. Миңа калса, чынлап та, башка милләт балалары өчен татар теле укыту программасы авыррак иде. Бәлки күбрәк сөйләм теленә игътибар бирергә кирәк булгандыр.

Шулай да Чепья урта мәктәбе директоры төшенкелеккә бирелми: яңа уку елында атнасына өстәмә



1 – Соңгы елларда укучылар саны 300дән артык тора. Мәктәпнең киләчәге бар, – диде директор Сәйдәш Нурмиев.

ике сәгать туган тел дәресе кертергә җыена.

– Укучылар, кайсы милләттән булуларына карап, сыйныфларга бүленә. Катнаш никахтан булган гаиләләр күбрәк татар телен сайлый. Хәтта удмурт, мари балалары арасында да татар теле дәресен сайлаучылар бар. Ничек кенә булмасын, атнасына ике сәгать туган тел дәресе бик аз. Ничек тә өстәмә ике сәгатькә урын табарбыз, Алла боерса.

«БЕЗНЕКЕЛӘР – ИҢ МАТУРЛАРЫ!

Чепья мәктәбендә укучылар үзгә тоелды, төс-кыяфәтләре белән диюем. Җирән чәчлеләр, кап-кара күзлеләр, сары чәчле, яшел күзле малай-кызлар дисеңме.

– Төрле милләт балалары булганга шулай төрле алар, – дип елмайды директор. – Катнаш никахтан туган малай-кызлар аеруча сөйкемле. Мин аны гел әйтәм: безнең мәктәп балалары иң матурлары!

Мәктәпнең дүрт автобусы, көн саен икешәр рейс ясап, балаларны авылларга барып ала, дәресләр беткәч кайтарып куя. Авыл исемнәре кызык тоелды: Яңгырчы, Күскем, Сырия, Тагашур, Сизнер, Мельничная – болары удмурт авыллары. Пыжмара, Чепья, Куремьял – татар авыллары: керәшен татары авыллары – Иске Чепья, Дорга; мари авылы – Улисьял. Укыту рус телендә бара.

1844 елда эшли башлаган Чепья урта мәктәбе гомер-гомергә Балтач районындагы иң зур мәктәпләрнең берсе саналган. Бервакыт меңәр бала укыган вакытлар да булган.

– Соңгы елларда укучылар саны 300дән артык тора, – диде Сәйдәш Нурмиев. – Киләсе елларга да шуннан кимергә тиеш түгелбез. Ике ел элек мәктәп белән янәшә балалар бакчасы салып куйдылар. 120 урынга исәпләнгән ул. Тик бакчада урын барыбер җитми, балалар саны бик күп. Шулай булгач, мәктәпнең киләчәге бар. Моңа һич шикләнмим.

Кайсы мәктәпкә барып чыксаң да, укудан тыш аларның янә бер шөгыль-кызыксынулары була. Чепья урта мәктәбе укучылары спорт белән «җенләнгән». Стандартларга туры китереп эшләнгән ачык боз мәйданы, ике спорт-заллары бар. Кул көрәше, билбау көрәше, хоккей (үзләренең махсус формалары бар), футбол – барысы да югары дәрәҗәдә оештырылган. Район күләмендә ярышлар да еш кына Чепья урта мәктәбендә уза.

– Төрле авыллардан килеп укуның зур кимчелеге – укучылар кичке якта мәктәпкә килә алмый, – ди директор. – Алар бит әле өчкә, дүрткә мәктәп автобусы белән кайтып кына җитә. Шулай да 9, 10, 11 нче сыйныф укучылары өчен җомга көн «бәйрәм» ясадык – бу көнне автобус ике тапкыр әйләнә. Укучылар, кичен мәктәпкә килеп, спорт белән шөгыльләнә, имтиханнарга әзерләнә.

«УКЫРГА ӨЙРӘНЕП КИЛҮ ХӘЕРЛЕРӘК!»

Без килгәндә Чепья мәктәбендә кызу эш бара иде. Белем бирү йортының ике гектар җире бар. Ел буе үзләренә җитәрлек суган, кишер, чөгендер үстерәләр.

– Хәзер балаларны кул хезмәтенә бик кушып булмый, закон буенча да ярамый бит, – ди Сәйдәш Нурмиев. – Шуңа күрә җир эшкәртергә мотоблок алдык. Әлбәттә, бакчага балалар да чыга. Аларсыз гына булмый. Тик нигездә бакча техник персоналлар өстендә.

Авыл мәктәбендә бирелә торган белем дәрәҗәсе турында да сөйләштек. Узган ел ике мөгаллим, «Ел укытучысы – 2017» республика бәйгесендә катнашып, финалга чыккан. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Константин Грахов өченче урынны алган. Быел да ике укытучылары Казанга финалга узган. Ике ел элек, «Иң яхшы мәктәп» конкурсы кысаларында, беренче унлыкка кереп, ике миллион грант откканнар. Ул акчага мәктәпнең техник базасын тулысынча яңартканнар.

– Авыл мәктәбендә дә бер дигән мөмкинлекләр бар, – диде Константин Викторович. – Укучыларыбыз ел саен республика күләм олимпиадаларда урыннар ала. Шул ук ике миллион грантны да болай гына бирмиләр. Аның өчен бөтен күрсәткечләр югары булырга тиеш.

Сыйныфларга кереп укучылар белән күрешеп чыктым. Биш телдә сәламлиләр! Гаҗәп: бер класста синең белән биш телдә сөйләшәләр. Бу бит шәһәрнең бер текә билингваль үзәге түгел, ә гап-гади авыл мәктәбе.

Беренче сыйныфка кергәч, алдагы партада утырган җирән чәчле, шомырт кара күзле, түгәрәк йөзле бер малайга күзем төште. Исеме Георгий, фамилиясе Смагин икән.

Беренче сыйныфка кергәч, алдагы партада утырган җирән чәчле, шомырт кара күзле, түгәрәк йөзле бер малайга күзем төште. Исеме Георгий, фамилиясе Смагин икән.

– Милләтең буенча кем син? – дим.

– Әтием рус, әнием удмурт. Ә әнинең әнисе башкорт булган...

– Безнең Гоша активист, бик яхшы укый, – дип сүзгә кушылды малайның сыйныф җитәкчесе Алена Туктарова.

– Шәһәр җирендә бала беренче сыйныфка кергәндә укый-яза белсә, яхшырак дип әйтәләр. Сездә ничек? – дим укытучыга.

– Әлбәттә, укый белеп керсә яхшырак. Үзенә җиңелрәк булачак. Укучылар яңа елга кадәр үк мөстәкыйль эш язалар. Ә анда баланың үзенә укып эшләргә кирәк. Ни әйтсәң дә, бүгенге мәктәп программалары алдан өйрәнеп килгән балаларга йөз тота.

...Күпмилләтле Чепья мәктәбенә сокланып кайттым. Төрле милләт вәкилләренең бергә дус-тату яшәп, төрле телләрне үзләштереп, укып, әнә нинди уңышларга ирешеп булганлыгына ачык мисал алар.

ТАТАР ТЕЛЕ... ЯПОНИЯГӘ ИЛТӘ

Агымдагы уку елында, мөгаен, иң күп телгә алынган фән – татар теле булгандыр. «Татар теле авыр, аның методикасы эшләнмәгән» дип тә карадылар, «Аның нигә кирәге бар?» дип әйтергә дә кыенсынмадылар. Япон егете Чихиро Тагучи бу мәсьәләдә бөтен кешегә үрнәк. Япониядә яшәп, үзлегеннән татарча өйрәнгән ул. Бер дигән итеп сөйләшә, хатасыз яза. Япониядә татар теле ни өчен кирәк? Ә иң мөһиме – ничек шулай өйрәнергә була? Татарстанда яшәүче бик күп ватандашларыбызга японнар тәҗрибәсе кызык та, үрнәк тә булыр, дип уйлыйм.

Автор:
Руфия Фазылова

«МИН РУСЧА ДА БЕЛӘМ!»

Тукай туган көнен билгеләп, традицион Шигырь бәйрәмен үткәргән көннәрдә Казанда татар дөньясы өчен әһәмиятле тагын бер зур чара – Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиада үтте. Алтынчы тапкыр узды ул быел. Чихиро Тагучи әлеге олимпиадага килгән иде. Егет анда катнашып кына калмады, ә I дәрәҗә диплом белән дә бүләкләнде.

Ни кызганыч, татар телен камил белүче Чихиро белән, күзгә-күз карап, сөйләшеп утырып булмады. Халыкара олимпиада тәмамланганнан соң ук, туган ягына кайтып китте ул. Ләкин теге «Малыш һәм Карлсон» мультфильмындагы шикелле: «Ул китте, ләкин яңадан әйләнеп кайтырга вәгъдә бирде...»

Чихиро белән Интернет аша аралаштык. Иң беренче чиратта шуны әйтим: егет мин биргән сорауларга җавапларны бер хатасыз язды.

Фото: «Татар-информ»; автордан алынды.

Җөмләләре төзек, камил булуы белән таң калдырды. Казанда яшәгән рус баласы түгел, татар малай-кызларының да күбесе болай булдыра алмаска мөмкин бүген.

Җавап, дигәннән... Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиаданың жюри рәисе – филология фәннәре докторы, профессор Фираз Харисов Чихиро белән бәйле бер кызык вакыйга турында сөйләде:

– Олимпиада үзәгенә рус телле журналист килгән иде. «Үзенчәлекле бер катнашучы белән әңгәмә корасы иде», – ди бу. «Хәзер, бер гаҗәеп егет белән таныштырам сезне», – дидем дә, журналист егетне Чихиро янына алып килдем. Япон егете елмаепкөлеп татарча сөйләшә башлады. Журналист: «Кызганыч, мин сезне аңламыйм, татарча белмим», – диде. Чихиро исә аптырап калмады, русча сөйләргә керește. Дөрес, аның татарчасы яхшырак, шулай да рус телендә дә фикерен җиренә җиткереп белдерә ала.

Менә бу очрак – бик күпләргә үрнәк. Теләгең булса, димәк татарчаны рәхәтләнеп өйрәнеп була. «Татарча нигә кирәк?» – дигән сорауга да җавап анык: «Аралашыр өчен!» Тормышта нинди генә хәлләр булмый. Бүген кирәкмәсә, иртәгә кирәге чыгарга мөмкин. Өстәвенә, Татарстанда яшибез, көн саен татарча сөйләшүне ишетәбез.

«ҮЗЛЕГЕМНӘН ӨЙРӘНДЕМ»

Чихиро Токиодагы Кэйо университетының политология факультетында укый. Дүртенче курсны тәмамлап килә. Гаиләдә алар өч ир малай икән, Чихиро – иң кечесе.

– Гаиләмдә, туганнарым арасында татарча берәү дә белми, – дип язды ул. Ә менә татар телен камил белүче танышлары, дуслары бар икән. Шуларның берсе – 2017 елда узган татар теле һәм әдәбияты халыкара олимпиадасында Гран-при яулаган кыз – Мидзуки Накамура. Нәкъ менә бу кыз Чихирога олимпиадада катнашырга тәкъдим иткән дә. Чихиро кызны укытучысы итеп тә күрә, чөнки хәзер Накамура татар телен тагын да камил дәрәҗәдә белә икән. Узган елгы олимпиадага килгәч, кыз, моңлы итеп татар җырын җырлап, барысын да шаккатырган иде. Накамураның әбисе тумышы белән Башкортостан якларыннан, шуңа да татарча өйрәнә башлавы гаҗәп түгел кебек. Ә менә Чихирода татар каны юк. Телләр өйрәнү – аның хоббие.

– Япон теленнән тыш, инглизчә, немецча, французча, татарча, әрмәнчә һәм русча беләм, – дип язды миңа егет. – Аеруча төрки телләр белән кызыксынам. Татар теле дә төрки телләрнең берсе, шуңа татарча өйрәнергә теләк туды.

Чихиро татар телен 2014 елдан бирле өйрәнә икән. Дүрт ел элек Токиода татар теле курслары ачылган булган. Анда егермеләп кеше язылган.

– Курслар искиткеч шәп оештырылган иде, татарчаны тиз өйрәндем, – ди Чихиро. – Укытучыбыз Гөлнара Карасава, күп телләрне яхшы белгәнгә күрә, русча аңлаган укучыларга башта русча, төрекчә белгән укучыларга төрекчә аңлатты. Нигездә дәресләр татарча үтте. Курслар әле дә килә. Мин исә укытучым Гөлнара Карасова белән аерым да шөгыльләнәм.

Чихироның тагын бер дусты – татарчаны яхшы белүче егет Юто Хисияма. Ул да алдагы елларда Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада җиңү яулаган булган. Чихиро, татарчасын камилләштерү максатыннан, Юто белән татар телендә аралашырга тырыша икән.

– Әллә Япониядә сез татарча гына аралашасызмы? – дип яздым Чихирога, уенын-чынын бергә кушып.

– Әйе, менә әти-әниләрне дә татарчага өйрәтеп ятыш, – дип егет тә шаяртты. – Дөресен генә әйткәндә, без, японнарга, татар телен өйрәнү бик авыр түгел. Күпмедер дәрәҗәдә ул безнең туган телебезгә охшаган. Аеруча грамматикада уртак яклар күп.

Бүген Чихиро татар телен күбрәк Интернет аша өйрәнә. «Ана теле» онлайн-мәктәп аша да татарчасын камилләштергән.

– Япониядә татарча дәреслекләр юк иде. Хәзер Казан белән аралар бәйләнгәч, бу проблема актуальлеген җуяр, дип ышанам. Дәреслекләр шактый җыелды. Интернет аша да күп мәгълүмат табарга була, – дип язды егет.

Чихиро Тагучи укытучысы Гөлнара Карасова белән.

...Чихиро Тагучиның хыялы тормышка ашкан – Казанга килеп өчпочмак, бәлеш, пәрәмәч ашаган. Кремль, Кол Шәриф мәчетен барып караган.

– Казанга килгәч, бик тәэсирләндем. Кимендә, тагын бер атнага каласым килгән иде, тик мөмкинлек булмады. Һичшиксез, тагын киләчәкмен. Татар тарихы белән якыннанрак танышасым килә. Һәм өчпочмак, кыстыбый пешерергә өйрәнәсе иде. Бу ризыклар белән өйдәгеләрне дә сыйлап шатландырасы. Минем өчен бу хыял түгел, ә тормышка ашырып була торган эш...

Кыскасы, япон егете тиздән татар ризыклары пешерергә өйрәнәчәк. Ә егетнең иң яраткан җырлары – «Туган тел» белән «Аерылмагыз» икән. Музыкаль белемгә ия булган Чихироның (пианинода уйный ул) җырлаганын интернетта табып була. Ачык күңелле, татар җанлы бу егетнең тавышы күпләрнең күңеленә хуш килер, дип уйлыйм.

СҮЗ УҢАЕННАН

Татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиаданың йомгаклау турына Финляндия, Төркия, Казахстан, Япония, Үзбәкстан, Кыргызстан, Эстония, Франция, Индонезия, Кытай, Пакыстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Азәрбайҗан һәм Россия төбәкләреннән катнашучылар килде. Татарстаннан – 217, Россия төбәкләреннән – 108, чит илләрдән 30 кеше татар теле буенча үзен сынап карарга Казанга җыелды.

КИЛӘЧӘККӘ ОМТЫЛГАН
БОРЫНГЫ ШӘҺӘР

Болгар – Татарстанның рухи үзәге. Республиканың гына түгел, бөтен Россиянең дә төп тарихи һәм мәдәни кыйммәтләренең берсе. Бирегә килгән чакта «Татарстан» дәүләтебезнең шулкадәр күпкырлы һәм бөек тарихына кагылды.

УРЫННЫҢ УНИКАЛЬЛЕГЕ

Болгарга килүгә, иң элек шундый хис биләп ала: «Минә бу борынгы шәһәрдә минем бабаларым исламны кабул иткән!»

Күп баскычлы итеп төзелгән таш бина, әлбәттә инде, шәрык стилендә – иске шәһәргә керү капкасы кебек. Юкка чыккан цивилизацияләрнең өч мәдәни үзәге булган Болгарны, Суарны һәм Биләрне символлаштыручы өч манара безгә корылманың фасадыннан карап тора. Димәк, без Болгар цивилизациясе музеенда. Ә аның беренче катында Болгарның елга вокзалы «теркәлгән».

Бирегә, пристаньга, «Метеорлар» килеп туктый, өченче-дүртенче катларда музей экспозицияләрен күрергә, ә алтынчыдан – туп-туры культ объектлары урнашкан калкулыкка чыгарга була. Чыгарга һәм керергә. Болар барысы да – урынның уникальлеге турында сөйли һәм, әлбәттә, ул шулай булырга тиеш тә. Гаҗәеп шәһәр.

ТАРИХИ МАТУРЛЫКНЫ САКЛАП

Әле бирегә килергә өлгермәгән кеше болай дип уйлап куярга мөмкин: үткәннәрнең катып калган салкын корылмалары яңа заман төзелеше белән бердәм ансамбль төзи алмый. Әмма чынлыкта нәкъ киресенчә килеп чыга. Болгар, үзенең тарихи матурлыгын саклаган хәлдә, бүгенге көндә шәһәр төзелеше турындагы күзаллауларны күп яктан үзгәртә. Биредә борынгыларның тәҗрибәсе һәм осталыгы заманча технологияләрдә һәм архитектур табышларда чагылыш таба. Мо-

Фото: Александр Ефремов; «Грань» ҖЧҖ архивыннан

2012 елда «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» проекты кысаларында уникаль объект – Болгардагы Ак мәчет комплексы искиткеч рәвештә тормышка ашырылды. Матурлыгы һәм нәфислеге белән сокландыра торган заманча ислам архитектурасы һәйкәле. Тыштан да, эчтән дә ул Италиядән махсус кайтарылган фил сөяге төсендәге уникаль ак мәрмәрдән эшләнгән. Шундый ук мәрмәр Милландагы күренекле Ла Скала опера театрын тышлауда кулланылган булган. Комплекс мәчеттән, мөфти резиденциясеннән, мәдрәсәдән һәм мусәллә* рәвешендәге намаз мәйданыннан тора. Мәчет янындагы паркта утыртылган үсемлекләр елның төрле вакытында бары тик ак чәчәк кенә ата.

* Мусәллә – шәһәр читендәге бәйрәм мәчете



ның ачык дәлиле – борынгы Болгар шәһәрлеге белән янәшә торгызылган Ак мәчет.

Бер генә фото да Ак мәчет комплексының уникальлеген һәм матурлыгын тулысынча күрсәтергә сәләтле түгел. Йөреп чыгыйкмы аны? Шикәрдәй ак гүзәл бинаның көзгедәй су өстендәге чагылышына гына карагыз! Ул кай ягы беләндер Һиндстанның Таҗ-Махалын хәтерләтә. Сәнгатьле итеп эшләнгән шәрык колонналары белән уратып алынган намаз мәйданы, манараларның нечкә шпильләре, гаҗәеп витражлар белән бизәлгән биниһая зур түп гөмбәз, Коръән аятьләре, лалә чәчәкләре һәм челтәрле шәрык орнаментлары белән бизәлгән диварлар – барысы да бер стильгә буйсындырылган чып-чын архитектура җәннәте! Каршыбызда – бер стильдә ясалган ике агач фонарь һәм эскәмия. Үзеңне борынгы бөек цивилизация үзәгендә итеп тоясың.

ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ БОРЫЛЫП

Гомумән, Болгарда комплекс интерьерларының гүзәллеген бәяләү өчен, биналарның эчендә йөрергә кирәк. 922 елда Идел Болгарстаның исламны кабул итүе хөрмәтенә куелган Истәлек билгесен бәяләгез. Бина традицияләргә «борылып», борынгы болгар архитектурасы үрнәге стилендә төзелгән: ул сигез кырлы, гөмбәзле, аның очына ярым ай куелган. Истәлек билгесенең люстрасы үзенең үлчәмнәре белән таң калдыра – аның авырлыгы 1,5 тонна тирәсе, биеклеге 18 метр! Төп залдагы махсус пьедесталда дөньядагы иң зур Коръән урын алган. Китапның озынлыгы – 2 метр, киңлеге – 1,5 метр, ә авырлыгы 800 кг. Китапның тышлыгы зөбәрҗәт ташлары һәм шәрык орнаментлары, һәм шулай ук башка ярым кыйммәтле ташлар белән бизәлгән. Мондый гаҗәеп зур нәфис-зәркән эшләнмәсен барып күрергә кирәктер!



2017 елда Болгарда дөньяның барлык мөселманнары өчен әһәмиятле вакыйга булды – Болгар ислам академиясе ачылды. Ул дөньяның иң яхшы белем бирү комплекслары белән тиңләшерлек өч баскычлы ислам мәгарифе системасы – мәдрәсәсе, вузы, академиясе булган берләшмә. Узган елның сентябрендә аның ачылышында чыгыш ясап, РФ Президентының Идел буе федераль округы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич болай диде: «Моңа кадәр РФндә мондый тулыканлы система юк иде. Хәзер Россия мөселманнары, чит илләргә чыкмыйча да, иң югары сыйфатлы дини белем алу мөмкинлегенә ия».

БОРЫНГЫ ШӘҺӘР ТУРИСТЛАРНЫ ТАРТСЫН ӨЧЕН

Бүген туристларны бөтен дөньяда тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр белән генә түгел, отельләр белән дә гаҗәпләндерәләр. Алар төрле урыннарга урнашкан, күп төрле материаллардан әзерләнгән булырга һәм теләсә нәрсәне күз алдына китерергә мөмкин. Иң мөһиме – гаҗәпләндерергә.

Шик юк, болар барысы да дөрес. Әмма изге Болгар кебек урында барысын да «матур, яхшы һәм уңайлы» гына түгел, «урынлы» да итәргә кирәк. Шуңа күрә дә ул Татарстан Республикасы өчен бик тә мөһим проект, һәм аны тормышка ашыру өчен иң яхшысы гына файдаланылган.

Кунакханә комплексы 300дән артык урынлы 5 катлы «Кол Гали» кунакханәсеннән, рестораннан, SPA-үзәктән, балалар уен мәйданчыкларыннан, ясалма күлдән, мини-гольф кырыннан һәм ландшафт зоналарыннан тора. Комплекс Болгар шәһәрлегенең тарихи урыннан читтәрәк урнашкан. Кунакханә комплексы астында – 128 урынлы җир асты паркингы.

XIV гасырның тарихи Ак пулаты үрнәгендәге мунча комплексына ия булган «Кол Гали» кунакханәсе борынгы шәһәрне туристлар өчен тагын да кызыклырак итәргә тиеш. Шәрык колоритындагы архитектура элементлары бирелә иң заманча материаллар һәм технологияләр белән аралашып тора. Шулай итеп, якын арада туристлар Изге Болгарга сәяхәтләрен дөнья дәрәҗәсендәге отельдә идеаль рәвештә тулыканлы ял итү белән берләштерәчәк.

СҮЗ УҢАЕННАН

Ак мәчет комплексы, Ислам кабул итү хөрмәтенә Истәлек билгесе, Болгар ислам академиясе, ТР Фәннәр Академиясенең Тарих институты Халыкара археологик тикшеренүләр үзәге, Фестивальләр-вакыйгалар комплексы, Габдрахман коесы... Болгардагы барлык бу объектлар «Грань» төзелеш компаниясе тарафыннан салынган.

Хәзерге вакытта оешма «Кол Гали» кунакханәсен төзү эшләрен төгәлләп килә, һәм шулай ук Казандагы ике инвестицион проекты – «Соловьиная роща» торак комплексы һәм «Новые Горки» шәһәр-парк төзелешләрен тормышка ашыра. 20 еллык эшчәнлеге дәвамында компания торак һәм сәнәгать төзелешендә төрле дәрәҗәдәге катлаулылыкка ия 85тән артык объектны сафка бастырды, Татарстан территориясендәге кайбер мәдәни мирас объектларын реставрацияләү һәм реконструкцияләү эшләрен башкарды.

Дөньяда үзләренең тышкы күренеше белән генә дә иң күп төрле хисләр – шаккату, гаҗәпләнү, соклану хисләрен уята торган урыннар шактый. Ә менә Изге Болгар, балачак кебек үк, туктаусыз үзенә тарта. Сәбәбе аны терелтү һәм киләчәге өчен дөрес сайланган интонациядә түгелме икән?

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Гагарин Кубогын **НИЧЕК** яуларга

Юдино егете **НИЧЕК** дөнья футболы йолдызына әверелгән

Каюм Насыйри заманында **НӘРСӘЛӘР** пешергәннәр

Саба интернаты: **КЕМНЕҢ** кулы җылы

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

КАЮМ НАСЫЙРИГА ИЯРЕП – ЧӨГЕНДЕР ШУРПАСЫ

Автор:
Руфия Фазылова

Редакциябез кухнясына чибәр дә, зыялы да туташ – Резедә Хәсәнова килде. Күпләр аны «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесе аша белә. «Кичке аш» тапшыруы алып баручысы, күп тапшырулар авторы, «Шаян ТВ»ның мөхәррире, «Созвездие–Йолдызлык» фестиваленең жюри әгъзасы... Кыскасы, балалар кайда, ул шунда. Начарга караганда яхшылыкның җиңеп чыгасына ышана, дөньяны якты төсләрдә генә күрә...

Ул безне башкаланың бер милли ресторанына чакырды. «Анда мич бар, ә мин әзерләгән ризык нәкъ менә шунда пешәргә тиеш», – диде.

ҮЗЕБЕЗЧӘ!

Бактың исә, Резедә мичтә аш пешерергә җыена икән. Тик гади түгел, ә Каюм Насыйри рецепты буенча чөгендер шурпасы. Башта күз алдына борщ килде. Ә белгәнебезчә, ул украин, рус милләте ризыгы булып санала. Әллә борщка татарлар да дәгъва кыламы?

– Өч ел элек Икътисад, идарә һәм хокук институты Каюм Насыйри рецептларыннан торган «Иршад әл-Әтбиха» китабын яңартып бастырды, – диде Резедә. – Татар, рус телләрендә ул. Әлегә кадәр Каюм Насыйри рецептлары рус телендә басылмаган булган. Мине шул китапны тәкъдир итү кичәсенә чакырдылар. Һәм үзеннән-үзе Каюм Насыйри рецептлары белән кызыксынып киттем. Аерым ризыкларын пешереп тә карадым. Ә чөгендер шурпасы аеруча кызык тоелды. Бер карасаң, борщка да охшаган ул. Күрәсең, элек әби-бабаларыбыз башка милләт ризыкларын да әзерләгән. Тик чөгендер шурпасы борщтан аерыла. Беренчедән, анда бәрәңге юк. Икенчедән, аны чүлмәктә мичкә куеп пешергәннәр. Гомумән, әзерләү алымнары да бүтән.

Без килгәндә ит пешкән, шулпа әзер иде. Дүрт чүлмәккә бер литр шулпа җитә икән.

Резедә шулпаны чүлмәкләргә тигезләп бүлеп чыкты. Аннан итне турап чүлмәк төбенә салды. Һәм суган белән кишерне турап (нәкъ менә озынча итеп турарга) табага кыздырырга куйды.

– Яшелчәләр сүрән утта ике-өч минут торырга тиеш, – ди Резедә. – Аш-су әзерләгәндә яхшы кәеф, изге уйлар белән эшкә тотынырга кирәк. Әнием дә гел шулай әйтә: «Күңелеңне биреп әзерләгән ризык тәмлерәк була».

Резедә табада кызган кишер белән суган өстенә озынча итеп туралып пешерелгән чөгендер салды. Шуңа тагын аш серкәсе, бер кашык он өстәде:

– Аш серкәсе чөгендер төсен үзгәртмәсен өчен кирәк, ә он шулпаны куертып җибәрә, – диде пешекчебез. – Элек онны шулпага, икенче ашларга салганнар, ризык туклыклырак булсын дигәннәрдер инде.

РЕЗЕДӘ ХӘСӘНОВАДАН ЧӨГЕНДЕР ШУРПАСЫ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:

1. Шулпа – 1 литр
2. Сыер ите – 0,5 кг
3. Суган – 1 баш
4. Кишер – 1 баш
5. Чөгендер – 1 баш
6. Он – 1 аш кашыгы
7. Аш серкәсе – 1 аш кашыгы

Фото: Александр Ефремов

Редакция кухнясы

1. Бүләбез!

2. Салабыз!

3. Ваклыйбыз!

4. Кисәбез!

5. Турыйбыз!

6. Кушабыз!

7. Өстибез!

8. Кыздырабыз!

9. Салабыз!


10. Мичкә куябыз!

– Каюм Насыйри 1902 елда вафат булган. Ул яшәгән чорда татарлар аш серкәсе кулланганмы икән? – дим.

– Каюм Насыйри язып калдырган икән, димәк, булган. Һәрхәлдә, шәһәр халкы кулланган, дип уйлыйм...

Шуннан Резедә чүлмәкләргә яшелчә кыздырмасын бүлде. Шулпа бер мизгелдә кызыл төскә керде.

– Каюм Насыйри яшелчәләрне чи килеш пешерүне күздә тоткандыр. Ә без чөгендерне пешереп салдык, – ди Резедә. – Моны һәркем үзенчә эшли ала. Чи чөгендерне саламлап турасаң, чүлмәктә пешә инде. Зыян юк...

Һәм туташ чүлмәкләрнең өстен каплап мичкә тезде.

– Авылларда хәзер мичле кешеләр бик сирәк калды. Газ мичендә пешерсәң ярыймы? – дим.

– Әлбәттә, ярый. Мич безгә хәзер музейдагы экспонат кебек: сирәк күренеш. Утын мичен күптән газныкына алыштырдык... Тик ничек кенә булмасын, утынныкына җитми инде ул. Шуңа да сезне бирегә чакырдым – ашның тәме Каюм Насыйри язганча булсын, дидем.

ТАМЫРЛАР ТУРЫНДА...

Резедә Хәсәнова тумышы белән Спас районыннан. Ләкин ул алай дип әйтергә яратмый. «Мин Болгар җирлегеннән», – ди горур гына. Туган җире, балачагы турында менә нәрсәләр сөйләде:

– Минем өчен Болгар җирлеге – аерым бер көчкә ия урын. Кечкенә вакытта дәү әнием: «Кызым, тамырларың кайсы җирдән икәнен онытма», – дия иде. Тарихи, изге саналган туган ягым турында кечкенәдән бик күп төрле риваятьләр ишетеп үстем. Соңрак китаплардан Болгар җирендә булган бәрелешләр, тарихи яулар турында укыдым. Еллар узган саен туган җиремә карата булган ихлас мәхәббәт, соклану катыш горурлану арта гына бара. Менә шуңа да үземне Болгардан дип күрсәтәсем килә...

Резедәнең бер зур теләге бар – Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашып, чын күңеленнән рәхмәт әйтәсе килә:

– Минтимер Шәрипович Болгарны торгызырга алынмаса, безнең җирлек беткән булыр иде. Анда бит теләсә кем килеп, кабер ташларына кадәр казып алып китте. Әле без балачакта ук кулларына металл эзләүче җайланма тоткан кешеләр изге җирләрнең өстен аска әйләндерәләр иде. Андый кешеләр аеруча төннәрен йөрде. Аллага шөкер, дим, тарихи хәзинәбез бүген дәүләт карамагында, киләчәк буыннарга ядкарь булып бара. Моңа чиксез сөенәм...

БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК...

Резедә мичне ачып карады. Шулпа күмерле мичтә акрын гына пешеп утыра.

– Ә синең балачакта мич бар идеме? – дим Резедәгә.

– Бар иде. Әти-әнием укытучылар. Гаилә белән үткәрү өчен бары бер көн – якшәмбе генә бар. Бәйрәм көн кебек ул. Якшәмбе әни беренче эш итеп камыр куя, аны мичтә пешерә. Өйгә хуш ис тарала... Аның исе һаман борынны кытыклап тора. Бүген дә камыр ризыклары пешерсәк, балачагым искә төшә.

– Иң яратып әзерли торган ризыгың нәрсә? – дим.

– Әлеге дә баягы камыр ризыклары. (Көлә. – Авт.) Авылда мичне махсус калдырдык. Әти-әнием янына кайткач, камыр ризыгы пешерми калмыйбыз. Камыр пешкән йортта тормыш матуррак кебек.

Резедә гаиләсе турында сөйли башлагач, янә кадерле кешеләрен искә алды – дәү әтисе белән дәү әнисе. Нәкъ менә алардан ул күп нәрсәләргә өйрәнгән:

– Акыллы һәм яшь булып каласың килсә, биштән кечерәк һәм җитмештән олырак булган кешеләр белән сөйләш, дия иде мәрхүм дәү әнием. Күбрәк яшәгән саен дәү әнинең шул сүзләре искә төшә, хак әйткән. Бу яшьтә кешеләр ихлас була, нәрсә уйлый, шуны сөйлиләр. Дәү әтием Бөек Ватан сугышын үткән кеше. Ул минем өчен чын герой иде. Дәү әни белән дәү әти эшне яратырга, тыйнак, тәрбияле булырга өйрәттеләр. Мин аларга бик рәхмәтлемен, һәрчак догада торам. Ни кызганыч, бүген күп балалар әби-бабай белән яшәүдән мәхрүм. Тормышта алар гына бирә ала торган кыйммәтләр бар. Аны сүз белән генә әйтеп тә булмый. Алар аны үз мисалында – сиңа булган, башкаларга карата мөнәсәбәте аша күрсәтә. Аннан әби-бабай белән үскән балаларның эчке дөньялары баерак була төсле. Бүген дә башларына ак яулыгын бәйләгән, сөйкемле әбиләр белән аралашырга яратам. Аларның акыллы сүзләрен бернинди китап та, курслар да бирә алмый.

Безнең милләткә генә хас тәрбия, гореф-гадәтләр – бары шул ак әбиләрдән...

«КАМЕРАНЫ ВАТАСЫҢ!»

Резедә белгечлеге буенча – укытучы. Хәер, нәселләре белән шушы һөнәргә тугрылар икән. Әтисе – Татарстанның атказанган укытучысы.

– Бабаларым җиде буынга кадәр муллалар булган, аннан укытучылар килә, – диде Резедә. – Әни гел әйтә: «Телевидениедә дә балалардан ерак китмәдең». Бу чынлап та шулай. Безнең балалар редакциясенә биш яшьтән унҗиде яшькәчә булган малай-кызлар килә. Һәрберсе белән уртак тел табып, сәләтен күреп, ачарга тырышабыз.

– Бүгенге балалар белән эшләү ничек: кыенмы, җиңелме дигәндәй. Унөч ел телевидениедә балалар белән эшлисең бит, – дим.

– Хәзерге балалар үткенрәк, – ди Резедә. – Алар теләсә нинди сорауга тиз генә җавап бирә. Күрәсең, компьютер, төрле гаджетлар үзенекен эшли... Бүгенге заман тизлек таләп итә, балалар шуңа иярә генә. Яшьләр, шул исәптән балалар да озак планнан төшерелгән фильмнарны карарга яратмый. Аларга ике-өч секунд саен үзгәргән кадрлар, «экшен», ягъни гамәл кирәк.

Бер ун ел элек студиягә балалар куркып кына, оялып, итагатьле итеп килеп керә иде. Камера күргәч бөтенләй каушап кала торган малай-кызлар булды. Татар балаларында бу аеруча сизелде. Аларда кыюлык тәрбияләү өчен күпмедер вакыт кирәк иде. Ә бүгенге балалар, киресенчә, артык кыю, тик утырмас. «Балам, тынычрак, хәзер камераны ватасың бит!» – дип әйтеп торырга кирәк.

– Бүген бакчага йөрүче бала да үзен телефон камерасына төшерә, «репортажлар» ясый. Шуны дуслары, туганнарына җибәрә. Ә мәктәп яшендәгеләре интернет аша туры эфирларга чыга. Бернинди кыенсыну юк. Бәлки бу да балаларны камерадан курыкмаска өйрәтәдер? – дим.

– Әйе, алар күпмедер дәрәҗәдә баланы ача, – ди Резедә. – Бер яктан карасаң, яшь буын үткен, аралашучан булып үсә. Икенче яктан... Балачаклары бармы соң аларның?! Безгә килгән балалар биюгә, җырга, шахматка, йөзүгә, тагын әллә никадәр түгәрәккә йөри. Аларның вакыты минутлап язылган. Еш кына: «Сез ничәдә торасыз һәм ятасыз?»- дип сорыйм. Әлбәттә, безнең балачак икенче төрле иде. Урамга чыгып, җыелышып уйныйбыз. Хәзер урамда уйнау дигән әйбер бөтенләй юк. Һәрхәлдә, шәһәрдә. Бу да һаман шул заман таләбе. Моның начармы-яхшымы икәнен әйтү кыенрак. Вакыт күрсәтер...

«БЕЗ – ИҢ СӘЛАТЛЕЛӘР!»

Сөйләшә-сөйләшә, утыз-кырык минут вакыт узганын сизмәдек дә. Чөгендер шурпасы пешеп чыкты.

– Рәсемдәге кебек булган бу, – диештек, чүлмәкне ачкач.

Аш яшел укроп белән бизәлеп, табынга чыгарылды. Авыз итәбез... Борщтан аерыламы икән, дигән идем – аерыла. Әллә мичтә пешкән булганга, шулпасы бик тәмле тоелды. Аш серкәсе әчкелт бер тәм биргән кебек.

– Тәмле иттән шулпа тәмле була, – ди Резедә. – Әнием дә гел: «Тәмле аш пешерим дисәң, күп итеп, әйбәт ит сал», – дия.

– Каюм Насыйри рецепты буенча тагын нәрсәләр әзерләгәнең бар? – дим.

– Кабак боткасы, кабак мантые пешергән идем. Күбрәк яшелчәләргә өстенлек бирергә тырышам. Ә кабак иң файдалы яшелчәләрнең берсе.

Каюм Насыйри рецептлары арасында төрле ризыклар: пылауның берничә төре, борчак өйрәсе, бәрәңге кесәле, бозау башына кадәр бар. Танылган этнограф, галим, язучы төрле эчемлек рецептларын да җыйган: әллә ничә төрле компот, йорт сырасы, лимон сиробы, баллы ачыткы (квас сыман). Хәтта «мәшрубатлар» дип аталган исерткеч эчемлек рецепты да бирә үзенең китабында.

– Ризыкны яхшы кәеф белән әзерләү бер булса, матур уйлар белән ашарга да кирәк, – дип сүзен дәвам итте Резедә. – Мин үзем ризык талымламыйм: нәрсә бар, шуны ашыйм. Табын алдында укымыйм, телефонны да карамыйм.

– Телевидение, «Созвездие–Йолдызлык», балалар белән бәйле тагын башка проектларда да буласың. Барысына да ничек өлгерәсең? – дим.

– Эшеңне яратып эшләгәндә өлгереп буладыр. Дөресен генә әйткәндә, бүгенге балаларга кызыгып карыйм. Мисал өчен, «Созвездие–Йолдызлык», «Сәләт» кебек проектлар Россиянең башка бер генә өлкәсендә дә юк. Буш сүзләр түгел: республикада балаларга, аларның талантын ачу өчен бик күп мөмкинлекләр тудырылган. Безнең вакытта боларның берсе дә юк иде. Читтән килгән кешеләр дә әйтә: Татарстан балалары сәләтләре, үз-үзен тотышлары белән аерылып тора. Киләчәктә дә шушы югарылыктан төшмәсәк иде.

КАЮМ НАСЫЙРИ КИҢӘШЛӘРЕ:

– Ризык ашаучы кешегә авызына алган ризыкны озак чәйнәргә кирәк, җиңел үзләштерелсен өчен.

– Сәламәт кешегә гадәттә ризык сеңдерү өчен 4 сәгатьтән 5 сәгатькәчә вакыт кирәк. Ләкин ашказаны бераз ял итәргә мохтаҗдыр. Ул вакытта ике ризык арасы 6–7 сәгать булу кирәк.

– Төнлә ашаудан сакланырга кирәк, чөнки бу вакытта ашказанына ике эш тиеш була, йокларга да кирәк, ашны сеңдерергә дә.

– Эссе тарафларда яшелчә ашау яхшырактыр, салкын якларда итле ризык. Безнең җиребез уртача тарафтан булганга, яшелчә белән итле ризык катыш кулланырга яраклыдыр.

– Ашаган вакытта укудан туктап торырга кирәк, чөнки гакыл рәхәт булсын вә зиһен һичнәрсә белән мәшгуль булмасын.

– Ашаган вакытта кайгы һәм көенеч китерә торган сүзләрне сөйләшмәскә тырыш. Күңел хуш вакытта ризык сихәтлерәк һәм тәмлерәк булыр.

БАЛАЧАКНЫ ОЗЫНАЙТУ

Балалар йортыннан һәрвакыт авыр тойгы белән чыгам. Үземә төбәлгән йөзләгән күз карашыннан куырылып киләм. Ул гөнаһсыз күзләр: «Ни өчен мин мондый язмышка дучар ителдем?!» – дип сорый кебек. Ә менә Саба районы Югары Утар акылга зәгыйфь балалар интернат-йортыннан бөтенләй үзгә тәэсирләр белән кайттым. Яткан җиреннән кузгала алмаган бала елмаерга тырышып сиңа кулын суза. Бала дип, аңа инде унҗиде яшь, ә гәүдәсе ике яшьлек сабыйныкы кебек. Ләкин ул аны белми, ә янына килгән һәркемгә сөенә...

Автор:
Руфия Фазылова

ЧАРАСЫЗЛЫК?!

Мондый балалар белән беренче очрашкангамы, башта үземне ничек тотарга да белмәдем. Бер урында таптанып тик торам. Тәрбияче апалары:

– Янына барыгыз, әнә Зәринә сезгә елмая, – диде.

Икенче караватта тагын шундый ук сабый гәүдәле бала ята.

– Бу балаларга ничә яшь? – дип сорыйм интернат-йортның өлкән тәрбиячесе Люция Ибәтуллинадан.

– Төрлесе бар. Биш яшьлекләре дә, унҗиде яшендәгеләре дә...

Әлеге бүлмә йөри алмый торган балалар өчен дип махсус эшләнгән икән. Ортопед матраслары, күтәрелә-төшә торган махсус караватлар... Тагын шунысын әйтергә кирәктер: бүлмәләр иркен, аллы-гөлле, якты төсләрдән тора.

– Бүгенгеге көндә интернатта 81 бала тәрбияләнә, – диде Люция Ибәтуллина. – Шуларның 35е ятып кына тора. Аларны көче тәрбиячеләр көн саен юындыра. Аларга рәхмәт, үз вазыйфаларын бик тырышып үтиләр. Йөри алмый торганнар арасында 30–40 килолы балалар да бар. Аларны бит күтәрергә, төшерергә кирәк.

Бу эшләрнең барысы да хатын-кызлар җилкәсендә икәнен белгәч, бирeдә эшләүнең ни дәрәҗәдә катлаулы икәнен чамалавы авыр түгел...

Физик яктан әзерлекле, чыдам булу – бер хәл, биредә рухның нык-лыгы да кирәк. Һәрхәлдә, фотограф кызга да, шәхсән үземә дә аралашу процессы җиңел барелмәде. Монда элеккәч, тормышка бөтенләй икенче күзлектән карыйсың: дөньяның кемнәре генә юк! Тәэсирләргә тиз бирешүчән кешеләр биредә озак эшли алмый – гариза язып үз теләкләре белән китәләр икән.

Коридорның бер башында әллә нинди сәер тавыш ишетелде.

– Курыкмагыз, – диде Люция ханым. – Монда бит акылга зәгыйфь балалар, төрлесе бар. Кемдер сәгатьләр буе әнә шулай акырырга мөмкин, икенчеләре идәнгә ятып бәргәләнә. Аларны тынычландырабыз, юатабыз.

– Агрессия күрсәткәннәре дә бармы? – дим.

– Була инде. Шуңа балаларны беркайчан да үзләрен генә кал-

Фото: Лилиана Вәлитова

дырмыйбыз. Тәрбиячеләр тәүлек буе кизү тора.

– Малайлар, кызлар аерым бүлмәләрдә яшиме? – дим.

– Әйе, яшь аермасына карап та бүләбез. Бездә кызларга караганда ир балалар күбрәк.

81 баланың 13е генә тома ятим икән, калганнарының әтисе яки әнисе исән. Дөрес, аларның күбесе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән. Ә 15 баланы ата-анасы үз теләкләре белән, гариза язып китергән.

– Гаҗәпләнәсе юк, – ди интернатның өлкән тәрбиячесе. – Мондый балалар белән бик авыр. Күбесенең берничә төрле диагнозы бар: акылы зәгыйфь – бер кимчелеге булса, церебраль паралич – икенчесе. Өченчеләренә даими рәвештә табиб күзәтүе кирәк. Менә шундый очракларда ата-ана баласын интернатка бирү өчен гариза яза. Чарасызлыктан дияр идем: тормышны алып барырга, башка балаларны да үстерергә кирәк бит...

– Димәк, биредә тулы, яхшы гаиләдән булган балалар да яши? – дим.

– Әлбәттә. Андый гаиләдәге ата-аналар балалары янына килеп йөри. Мисал өчен бер гаилә бар: ата кеше университет укытучысы, ана кеше дә зыялы, югары белемле. Өченче балалары акылга зәгыйфь булып туган. Малай шактый агрессив, аны гел күзәтеп торырга кирәк. Сигез яшенә җиткәч, атаанасы аны интернатка бирергә мәҗбүр булган. Ничек кенә сәер, куркыныч яңгырамасын, әлеге очракта бу – дөрес карар. Балага монда барлык шартлар да тудырылган, ул кыенлык күрми. Ә өйдә әтиәнисенә, ике апасына бик авыр булыр иде.

«АЛТЫН ЙӨРӘКЛЕ КЕШЕ»

Югары Утар интернат-йортына килгәнче үк, аның директоры Имаметдин абый Гәрәев турында бик күп җылы сүзләр ишеткән идем. РСФСРның атказанган социаль тәэминат хезмәткәре, Татарстанның «Фидакарь хезмәт өчен» медале, II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале иясе, «Алтын йөрәкле кеше» исеменә лаек булган, «Россиянең иң яхшы кешеләре» энциклопедиясенә кертелгән, тагын башка дистәләгән мактау грамоталары, билгеләре алган җитәкче ул. Хәер, бу очракта әлеге сүз бик үк туры да килми: интернатта аны җитәкче итеп түгел, ә әти дип күрәләр. Дөресрәге, шулай дип атап йөртәләр.

Имаметдин абыйга апрель аенда 79 яшь тулган. Шуның илле өч елын ул Югары Утар интернат-йортында эшли. Яшьлеге дә, картлыгы да биредә узган дигәндәй.

– Бик сирәк ир-атлар гына авыру балаларны үзенеке кебек якын күреп, шулар өчен яши ала, – диде интернатның музыка җитәкчесе Ландыш Хамматова. – Безнең директор аларны ихластан якын итә. Бала күңелен алдап булмый, диләр бит. Имаметдин Гәрәевичны күргә, алар аңа әллә каян елмая, күпләре «әти» диеп эндәшә.

Имаметдин абый белән аның бүлмәсендә очраштык. Стенага беркетелгән күпсанлы дипломграмоталарга күзем төште:

– Монда әле барысы да түгел. Кырык тугыз ел интернат директоры булып эшләү дәверендә җыелган инде, – дип елмаеп куйды җитәкче. – Кайбер конкурсларга миңа әйтмичә дә кызлар үзләре документларны тутырып җибәргән. Әле быел тагын берничә конкурста катнашырга тәкъдим иттеләр. «Җитәр инде, башкалар да алсын исемнәрне», – дидем.

Имаметдин Гәрәев Югары Утар акылга зәгыйфь балалар интернат-йортына Минзәлә медицина училищесын тәмамлагач килә. 1965 нче ел була ул.

– Район хастаханәсендә дә урын бар иде, тик мин интернатны сайладым, – диде Имаметдин абый. – Күңел шундый: балачакта зәгыйфь яшьтәшләремне башкалардан якладым, булышырга тырыштым. Илле ел элек интернат агачтан ясалган иске бер бинада урнашкан иде. Ут кермәгән, лампа белән яшәдек. Тау астындагы чишмәдән көн саен көянтәләп су ташыдык. Сигез чакрым ераклыктагы Шәмәрдән урманына барып, кышын ягар өчен 8–9 вагон утын әзерләдек. Тик салкыннарда мичнең җылысы әллә ни озакка җитми – балалар салкын тиеп еш авырыйлар иде. Әле бит өсләрендә пальто, башларында бүрек, кулларында бияләй...

1969 елда Имаметдин абыйны интернатның директоры итеп билгелиләр. Һәм шуннан башлана

1. Интернатның «әтисе» –Имаметдин Гәрәев.

2. Өлкән тәрбияче Люция Ибатуллина һәм музыка җитәкчесе Ландыш Хамматова.

инде. Ярдәм сорап кемнәргә генә мөрәҗәгать итми: матди ярдәм күрсәтә алырдай аерым кешеләргә дә, җирле җитәкчеләргә дә, район башлыгыннан башлап – министрлыкка кадәр. Тырышлык юкка китми: интернат өчен яңа бина төзелә, балаларның яшәү шартлары бер әкият дөньясына әйләнә.

– Балалар хәзер «Мин мөстәкыйль яши алам!» дип исемләнгән программа буенча укый, – диде Имаметдин абый. – Авыруына карамастан, һәр баланы укытырга омтылабыз. Бездә исем-фамилиясен яза белмәүче бала сирәк. Дөресен әйтим, бу балаларның иң рәхәт чаклары биредә уза. Бездән киткәч, алар зурлар өчен булган махсус интернатка эләгә. Ә анда мондагы шартларның күбесе юк. Нинди генә авыру булсалар да, яхшы белән начарны алар бик яхшы аңлый. Кызганыч, безнең кебек шартлары булган махсус интернат республикада бүтән юк.

Тәрбиячеләр, аның белән бергә директор да, һәр баланы күз яшьләре белән озатып кала. Азмы-күпме акылы булган балалар үзләре дә аерылышу сәгатендә үрсәләнеп елый икән. Әйтерсең, алда нәрсә көткәнен аңлый алар, күңелле балачагы белән хушлаша...

– Бездә балалар 18 яшькәчә яшәргә хокуклы иде, – ди Имаметдин абый. –Малай-кызларыбызның балачакларын озынайту максатыннан кайларга гына язмадым. Шөкер, безне ишеттеләр. Хәзер балаларыбыз 23 яшькәчә биредә яши ала. Минем өчен бу зур сөенеч. Димәк, аларның балачаклары тагын биш елга озынайтылды.

Имаметдин Гәрәев белән шәхси тормышы турында да сөйләштек. Егерме бер ел элек тормыш иптәше инфарктган кинәт вафат булган. Ул да гомере буе интернатта табиб булып эшләгән.

– Интернат хәзер эшем дә, өем дә, – ди директор. – Көне-төне монда мин. Хатынымның үлемен бик авыр кичердем. Шушы балалар тормышка кайтарды булса кирәк. Балалар ун күзләп көтеп торалар, шулар өчен дип йөреп, үз кайгыларымны да оныттым. Бердәнбер улыбыз Түбән Камада яши, лаеклы ялга чыкты инде. Ул да, безнең кебек, табиб һөнәрен сайлады.

ЯҢА ЙОРТ

Әле ике ел элек кенә интернатның яңа корпусы төзелгән. 1200 квадрат метрлы ул. 55 миллион сумга эшләп чыкканнар.

– Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка зур рәхмәт, – ди директор. – Беркайчан теләк-гозеребезне кире бормый. Аның бирегә килгәне дә бар. Безнең ничек эшләвебезне, балаларның нинди шартларда тәрбияләнүен белеп тора.

Элек ятып кына торучы балалар кысан бүлмәләрдә яшәгән. Яңа корпус ачылгач исә, авыру балаларга да, барысы да бик күпкә җиңеләйгән. Махсус юындыру бүлмәләреннән башлап, заманча технологияләргә кадәр кертелгән. Мисал өчен, хәрәкәтләнергә авыр булган балалар өчен кинезотерапия, «Адели» дәвалау костюмы, «Атлант» тернәкләндерү пневмокостюмы һ.б. сатып алганнар. Дәвалау өчен кирәк булган тагын әллә нинди колак ишетмәгән җиһазлар бар биредә.

– Әлбәттә, безнең балалардан тулыканлы сау-сәламәт кеше ясап булмый инде, тик бу җиһазлар

аларның сәламәтлеген ныгыта, тотрыклы халәттә тотарга ярдәм итә, – диде интернатта эшләүче шәфкать туташлары.

Интернат үзе берничә корпустан тора. Мондагы пөхтәлекне, матурлыкны күргәч, аптырап та, сокланып та куясың. Хәтта урамда зур сәхнәгә кадәр эшләп куйганнар. Анда җәен концертлар, төрле чаралар уза икән. Эстрада артистлары биредә – даими кунак. Шулай ук аерым җитәкчеләр, хәйриячеләр – Югары Утар интернат-йортында булган кешеләрнең исемнәрен саный китсәң, бер журнал гына җитми.

– Безгә бер килгән кеше янә килә, – ди Имаметдин абый. – Күбесе моннан күз яшьләре белән китә. Безнең проблемалар чүп кенә икән, диләр. Шуннан соң тормышка икенче күз белән карый башлаучылар да шактый.

Интернатның үз зоопаркы бар. Анда нинди генә кош-корт, хайван юк! Тавык-чебидән башлап, аккош, пони, маймылларга кадәр. Балалар хайваннарны ашата, алар белән сөйләшә, уйный, атларга утырып йөриләр.

– Үзенә күрә бер терапия бу, – ди Имаметдин абый. – Интернатта хайван, кош-кортлар яши башлаганга унбиш еллап инде. Кызык өчен генә дип алып кайткан идем, шуннан китте. Ул хайваннарны бүләк итеп тә бирәләр, сатып та алабыз. Әлбәттә, аларны кышлату бер дә җиңел түгел. Тик ул җан ияләреннән башка да булмый: балалар да, үзебез дә ияләндек. Кайберләре өчен бу бигрәк тә мөһим: тынгысыз балалар хайваннар янына чыккач тынычлана, кәефләре яхшыра...

Интернатның 7 гектар җире бар. Ул аларга чын-чынлап акча китерә. Җылытыла торган теплица эшләгәннәр. Март аеннан ук анда үсентеләр, яшел тәмләткечләр утырталар. Кыяр, помидор, борыч – барысы да үсә биредә. Балалардан калганын сатуга чыгаралар.

– Әйе, балаларның интернаттагы тормышлары көйле, нурлы, ямьле икән. Ә аннан соң? Барысын да өлкәннәр өчен булган махсус интернат көтәме? Гаиләләренә кайткан очраклар, тормышта үз юлын тапкан кешеләр бармы? – дим директорга.

– Сирәк кенә интернаттан үз гаиләләренә яңадан кайткан очраклар була. Ә тормышта үз юлын тапканнар... Хәзер балалар мондый җирләргә кат-кат комиссия узып килә. Ә безгә иң авырларын җибәрәләр. Кызганыч, ничек тырышсак та, без алардан сау кеше ясый алмыйбыз. Шулай булгач, тормышта үз юлын табуны башкачарак аңларга кирәк. Мөстәкыйль рәвештә, үз-үзеңне карап яши алу – безнең балалар өчен иң кыйммәтлесе шул.

Шулай да бер очрак бар. Берничә ел элек кабинетыма яхшы киенгән, бик акыллы сөйләшүче бер ир-ат килеп керде. «Имаметдин Гәрәевич, исәнмесез, сез мине танысызмы?» – ди. Танымадым. Мин әйтәм, кайчандыр безнең интернатка булышкан кешедер. Баксаң, 1980 нче елларда бездә тәрбияләнгән, биш ел яшәгән икән. Интернаттан соң туганнары аны Мәскәүгә алып киткән. Шунда белем алган, эшкә урнашкан. Соңрак үзенә бизнес ясаган. Өйләнгән, ике сау-сәламәт баласы бар. Хәзер дә без аның белән аралашып торабыз. Бәйрәмнәр үткәргәндә Мәскәүдән кайта, матди яктан да ярдәм итә. Ләкин бу очрак искәрмә генә. Күрәсең, комиссия малайны тикшереп тормаган, начар укыгач, тотканнар да интернатка җибәргәннәр. Югыйсә акыллы, үткен егет булган. Әйткәнемчә, хәзер балаларны кат-кат комиссия аша уздырып тикшерәләр. Бүген андый балалар безгә берничек тә эләгә алмый. Шулай да кайвакыт могҗизалар була. Кем белә, бүген биредә тәрбияләнүче балалар арасыннан да Мәскәүдә яшәүче егетебез кебек кеше чыгар...

...1 июнь – Россия күләмендә Балаларны яклау көне. Еш кына уйлана идем: ни өчен балалар көне генә түгел, ә яклау да. Аларны кемнән яклыйбыз? Аллага шөкер, сугышлар бармый, ул-кызларыбыз нәрсә ашыйсылары килсә, шуны ашый, кия, уенчыкларның нинди генә юк... Югары Утар интернат-йортына баргач, әлеге сорауга җавап таптым: менә бу балалар яклауга мохтаҗ. Алар өчен өзелеп торучы әти-әниләре юк, алар үз-үзләрен яклый да, саклый да алмый, акыллары зәгыйфь, аяк-куллары йөрми. Янналарында олы йөрәкле, киң күңелле, ярдәм итәрдәй кешеләр булмаса, бу балалар озак яши алмас иде. Мең рәхмәт, интернатта тәрбияләнүче малай-кызларның янәшәләрендә андый кешеләр бар. Димәк, аларга бәхет елмайган.

«АК БАРС» ФЕНОМЕНЫ

Хоккей белгечләре бертавыштан Гагарин кубогын Санкт-Петербург СКАсы яки ЦСКА командасы яулап алачак, башкаларның һичбер мөмкинлеге юк, дип сөйләде. Ә «Татарстан» журналы плей-офф башланырга бик күп вакыт алданрак вакыйгалар сөрешенең үз вариантын тәкъдим иткән иде. Һәм юраганы бик юш килде: 22 апрельдә Гагарин кубогы өчен бәйгедә Казан өстен чыкты.

Автор:
Сафа Гиреев

Сигез Олимпия чемпионын сыендырган Мәскәү клубын «барс»ларның хәлиткеч матчта җиңгәненә бер ай узды. Җанатарлар плей-оффның иң мөһим мизгелләрен теркәп калдырган видеосюжетларны әле һаман да тәмләп-тәмләп күзәтә. ЦСКА белән хәлиткеч уендагы Роб Клинкхаммерның «алтын» голын инде йөзенче тапкыр карыйлардыр. Финалда иң кыйммәтле уенчы исеменә лаек булган Джастин Азеведо керткән алкаларны алкышлыйлар. Гагарин кубогын инде бишенче тапкыр яулаган Данис Зариповның голларына һәм «акыллы» пасларына сокланалар. Капкачы Эмиль Гарипов янында уенчылар кайнашкан йөрәк өшеткеч мизгелләрне янәдән кичерәләр...

«Ак Барс» җиңгән командаларның тренерларына эш катлаулырак. Көндәшеңнең җиңүләренә соклану бер нәрсә. Иң мөһиме – Зиннәтулла Билалетдинов дружинасының көндәшләргә көчләп таккан уенына каршы аларның ни өчен төпле җавап бирә алмаганын аңлау. Әле шунысы да бар: чираттагы уңышсыз уеннан соң тренерларның һәркайсы диярлек бер үк сүзләрне кабатлады: Зиннәтулла Хәйдәрович егетләренең ничек эш йөртәчәген алар бик әйбәт белә иде дә, тик менә килеп чыкмады... «Металлург»ның баш тренеры Виктор Козлов, «Трактор» остазы Әнвәр Гатиятуллин, ЦСКАның баш тренеры Игорь Никитин –алар барысы да Биллның бик тәфсилләп куелган капкыннарына бер-бер артлы эләгә торды.

АКЧА ЯНЧЫКЛАРЫ ҺӘМ ИСЕМНӘР ЯРЫШЫНДА

Быелгы Гагарин кубогы тагын бер тапкыр шуны дәлилләде: составтагы йолдызлы уенчылар саны һәм клубларның колач җитмәс бюджеты җиңүгә һич кенә дә гарантия бирә алмый. Акча янчыклары һәм атаклы исемнәр ярышында «Ак Барс» СКА белән ЦСКАдан гына түгел, кайбер башка клублардан да шактый калыша иде.

Фото: www.ak-bars.ru

Сезонның иң башыннан ук казанлылар күзгә күренгән һәркемне, һәрнәрсәне түгел, ә берәм-берәм сайлап кына сатып алачаклары турында белдереп куйды. Аларның максаты – чыннан да ныгыту таләп ителгән позицияләргә генә уенчы эзләү иде. Хәер, бу ниндидер яңалык түгел, сәмәнне уйлапуйлап тоту гына, бигрәк тә акча ягы җитенкерәмәгәндә.

Икенче яктан, команданы көчәйтү үрнәк булырлык итеп башкарылды дияргә мөмкин. Сезон башында команда чыннан да аны шактый ныгыткан хоккейчылар белән тулыланды. Элекке НХЛчы, швед Антон Ландер, мәсәлән, теләсә кайсы клубның саклаучыларын куркытып торырлык звено барлыкка килсен өчен, Азеведо – Секач берлегенә җитеп бетмәгән уенчының нәкъ үзе булып чыкты. Россиягә «Вашингон кэпиталз» клубыннан кайткан Станислав Галиев, Магнитогорск «Металлург»ыннан «Ак Барс» ка кайткан Данис Зарипов Владимир Ткачев белән матчның язмышын хәл итәрлек икенче удар звеноны тәшкил иттеләр. Милли хоккей лигасыннан кайткан тагын бер уенчы – Андрей Марков команданың саклау зонасын сизелерлек ныгытты. «Аның очколары – безнең җиңүләребез», – дип, кыска гына бәяләде саклаучының гомуми җиңүгә керткән өлешен Зиннәтулла Билалетдинов.

Түбән Новгородта үз урынын тапмаган һөҗүмче Алексей Потапов та, «Магнитка»га җибәрелгән Алексей Чибисовка алмаш итеп алынган Ярослав Косов та «Ак Барс» командасында нәтиҗәле уйнап китте. Сүз уңаеннан, ике һөҗүмче дә чемпионат барышында килде, ләкин бу аларга «Ак Барс»ның уен схемасына кереп китәргә комачауламады. Әлеге хәл шуны бик яхшы исбатлый:

Эмиль Гарипов:
– Үз уеныма бәя бирергә теләмәс идем. Без чемпион, бу – иң мөһиме.



Роб Клинкхаммер:
– Бу голны гомергә онытмам, аның турында оныкларыма сөйләрмен. «Ютуб»та аны гомер буе караячакмын. Мин бик бәхетле!

сайлау этабында Казан командасы уенчыларның осталыгын һәм потенциалын гына түгел, «барс»лар һәм аларның остазлары үз иткән хоккейга җайлашу сәләтен дә исәпкә ала.

Минемчә, бер генә нәрсәдә селекционерлар әллә ни уңышка ирешмәде. Регуляр чемпионаттагы берничә уен нигезендә фикер йөрткәндә,«Югра»дан чакырып китерелгән голкипер Александр Шарыченковның, иң җаваплы урында төп капкачыны алыштыра алуы бик шикле. Ә плей-офф этабына бердәнбер ышанычлы капкачы, хәтта аның фамилиясе Гарипов булса да, бик тәвәккәллек сорый торган адым. Җәрәхәтләнү, психологик яктан бирешү, арыганлык... – плей-офф дип аталган

Александр Свитов, капитан:
– Кубокны тапшыргач гына, җиңүебезгә ышандым. Шулчакта гына үзебезнең иң шәпләр булып чыгуыбызны аңладым.

матавыкта теләсә нинди сюрпризлар көтәргә мөмкин. Хәер, безнең очракта Эмильнең капка янында шаккаткыч һәм, иң мөһиме, тотрыклы уены җиңүгә китерде.

БАРЛЫК УЕННАР ДА «СОҢ ЧИККӘЧӘ» БУЛГАНДА

– Егетләр, мин сезнең белән бик горурланам. Бары тик намуслы хезмәт кенә җиңүгә, менә шушы кубокка китерер дип, мин сезгә гел әйтә килдем. Авыр булды, кыен булды, шулай да сез намус белән хезмәт куйдыгыз. Җиңү белән сезне, барыгызны да яратам! – Бу сүзләрне казанлыларның баш тренеры Зиннәтулла Билалетдинов «барс»ларның киенү бүлмәсендә Гагарин кубогы җиңүчеләр шәрабы белән мөлдерәмә тутырылган мизгелдә сөйләде.

Гадәттә бик кырыс һәм азсүзле Биллның хисле чыгышы – «Ак Барс» «феноменын» аңлар өчен тагын бер ачкыч ул. Континенталь хоккей лигасы матчларын старт уеннарыннан ук башлап күзәтеп барган һәркем сүземне куәтләр: чемпионатка кереп барган «Ак Барс» белән драматик финалда җиңү яулаган «Ак Барс» – икесе ике команда. Уенның гомуми төзелеше ягыннан караганда, бәлки, үзгәрешләр бик күзгә ташланмыйдыр. Ләкин һөҗүмчеләрнең, саклаучыларның үзара хәрәкәте, бәйләнеше, командадагы тәртип дәрәҗәсе хәлиткеч финалларга гаҗәп рәвештә үсте. Капкачының уены турында әйтеп тә торасы юк. Чемпионат барышында әллә ни күтелмәгән алкаларны керттергән Эмиль Гарипов («Амур» белән уенда көндәшләр ягыннан сугып кертелгән алканы гына да искә төшерик) финалда

Артём Лукоянов:
– 30 гектар бәрәңгене кул белән утап чыккан кебек! Һәм менә соңгы буразна иде, без анысын да утап бетердек. Хәзер ял итәчәкбез.

кыя кебек каты торды һәм ышанычлылык ягыннан Василий Кошечкин, Павел Францоуз, Илья Сорокин, Ларс Юханссон кебек көндәшләрен артта калдырды.

Зиннәтулла Билалетдинов җитәкчелегендәге тренерлар төркеме «барс»ларны мөһим матчларга иң яхшы әзерлекле формада чыгаруга ирешә. Боздагы тамашаның һәр актеры хоккей профессорлары тарафыннан үзенә бөртекләп язып бирелгән рольне төпле белә иде. Болар барысы да, башка шартлар тигез булганда, хәлиткеч әһәмияткә ия булды.

Биллның, җиңүдән соң тәүге хискичерешләр бераз тынычлангач, күңел төпкелен ачып әйтелгән башка чыгышыннан:

– Барлык уеннар да соң чиккәчә барды. Мин хәзер уеннарны яңадан караштырам, команда теләсә нинди ситуациядә дә уйный белә – җиңеп барганда да, оттырганда да. Бер алка аерма белән уйнаганда да, холык ныклыгы һәм психология кирәк. Егетләр бу яктан үсте. Уенны ничек башласалар, шулай дәвам итәләр. Минем өчен бу мөһим.

УЕНГА ГАҖӘП БИРЕЛГӘНЛЕК ХИСЕН ФИНАЛ ӨЧЕН САКЛАП ТОРДЫК

«Ак Барс» Гагарин кубогын өченче тапкыр яуларга сәләтле икәнен тәүге тапкыр кайчан аңладык? Алар конференциядә җиңеп чыккандамы? Плей-оффта «Магнитка»ны тез чүктергәндәме? Әллә үз бозында бәйгенең «рәсми» фавориты саналган ЦСКАны финалда ике тапкыр рәттән откачмы? Ә «барс»ларның инде шактый күптән – октябрь аенда СКАны овертаймда җиңгәнен хәтерлисез микән? Казан командасының чын мөмкинлеген нәкъ менә шул матч күрсәткәндер, дип уйлыйм. Павел Дацюк, Илья Ковальчук һәм Никита Гусев кебек йолдыз уенчылар бихисап булган команда моңарчы үз бозында бер дә җиңелмәгән иде, ә көтмәгәндә «барс»-

Джастин Азеведо:
– Үлсәң үл, тик җиңәргә кирәк – бу матч әнә шундый иде. Без булдырдык!

ларга оттырып куйдылар. Юк, хәтта ул уенда да кунак команданың хуҗаларны әйдәп баручы уенчыларыннан калышканы сизелә иде. Фәкать ул калышу уенга бирелгәнлек һәм тәвәккәллектә дә, матчка тренер тарафыннан билгеләнгән планны йөз процентка үти белүдә дә түгел иде.

Дөресен әйткәндә, «барс»лар мондый өстенлекләренең барысын да чемпионат барышында һәм плей-оффның беренче раундларында шомарта килде, чөнки башка шартлар тигез булганда, үз-үзеңне тулысынча уенга багышлау һәм оешканлык кына җиңүне гарантияли ала. Осталыкта җиңүгә күнеккән петербурглылар, күрәсең, кирәкле вакытта менә шуңа күрә дә гайре табигый тырышлыкны эшкә җигә алмаган. Регуляр чемпионат барышында көндәшләрне еш кына ихтыяр көчен җыеп җиңәргә туры килгән казанлыларга хәлиткеч уеннарда

ниндидер яңа нәрсәне «кушып» җибәрү кирәкми дә иде. Хәер, «барс»ларның финалда үз-үзләрен уенга ихлас багышлаулары хәтта аларның остазлары өчен дә күпмедер дәрәҗәдә ачыш булды.

– Иржи Секачның карары шаккатырды, – дип бәян итә Зиннәтулла Билалетдинов. – Бөтенесе дә аның уйнамаячагын сөйләде, ә ул яныма килде дә: «Мин уйнаячакмын», – дип белдерде. Токранов белән дә шундыйрак хәл булды. Имгәнгән иде, без сабырлык белән аның уенга әзер булуы турында үзенең әйтүен көттек. Аннары гына уенга куйдык. Альберт Яруллин сөягә сынган килеш, уколлар кадатып кына уйнады, Свитов та шулай. Бик күп егетләр укол кадатып кына уйнады. Алар үз-үзләрен аямады. Егетләрнең һәрнәрсәгә әзер булуы мине бик куандыра иде. Зарипов алка каршына ятты. Ул беркайчан да мондыйга бармый иде! Аның уенга омтылышын күз алдына китерәсезме?! Азеведо алка каршына хәтта йөз белән ятты. Уенга менә нинди бирелгәнлек булды!

ХОККЕЙ ИНТЕРНАЦИОНАЛЫНЫҢ МИЛЛӘТПӘРВӘРЛЕГЕ

– Мин бар көчемә уйнамадым, имгәнгән урынны дәвалап бетермәгән идем. Ләкин команда өчен хәлемнән килгәннең барысын да эшләдем. Мине алга сөйрәгән егетләргә рәхмәт. Бу искиткеч командалы җиңү булды! – дип белдерде финалдан соң Иржи Секач.

Чех Секач, канадалы Джастин Азеведо һәм Роб Клинкхаммер, фин Атте Охтамаа, швед Антон Ландер, россияле Александр Свитов, Данис Зарипов, Эмиль Гарипов, Владимир Ткачев... Әлеге хоккей интернационалы, чыннан да, танылган йолдыз уенчылар да каршы тора алмаган командага әйләнде. Монда, әлбәттә, остазлары Зиннәтулла Билалетдиновның хезмәте аеруча зур. Һәркайсы индивидуальлеге белән ачык аерылып торган легионерлар белән россиялеләрне бердәм коллективка туплау, стратегиянең хаклыгына һәркемне инандыру – үз-үзеңне гайре табигый рәвештә уенга багышлау менә шул очракта гына көтелә ала.

Мөгаен, уңышның сәбәбе тагын шундадыр: «Ак Барс» Континенталь хоккей лигасы клубларының бик сирәкләренә генә хас «серле коралга» ия. Сүз «барс»лар составында кубәя барган үз уенчылары, үзе тәрбияләп үстергән хоккейчылар турында бара. Алар өчен Татарстан даны, клуб даны буш сүзләр генә түгел. Болар – капкачы Эмиль Гарипов та, һөҗүмчеләр Владимир Ткачев белән Артем Лукоянов та, саклаучылар Василий Токранов белән Альберт Яруллин да... Кайчандыр Татарстан хоккей мәктәбе укучылары спортчы бәхетен күбрәк читтә эзләсә, хәзер исә «Ак Барс» өчен уйнау – мондагы бик күп яшүсмерләрнең хыялы. Бәхеткә, үрнәк алырлык затлар бар.

– Мин беркемгә дә, бернәрсә дә исбатларга җыенмадым, үзем үскән клуб белән җиңү яуларга гына теләдем, – дип бик гади генә аңлатып узды уңышлы уенын Эмиль Гарипов. – «Ак Барс» белән

Данис Зарипов:
– Без сезонны җиңү теләге белән башладык, һәм моны чынга ашыра алдык.

Алексей Потапов:
– Данис Зарипов уен алдыннан әйтеп куйды: «Егетләр, я хәзер җиңәбез, я соңыннан бик авыр булачак. Артка бер адым да атлыйсы түгел, бары алга гына!»

кубок яулау хыялы баштан ук бар иде, Аллага шөкер, кубок безнеке. Мин татар егете, Казанда тудым, шунда яшим, үзем үскән клуб белән кубок яуладым.

Сүз ахырында, «Татарстан» журналы әле декабрь аенда ук ясаган фаразны искә алыйк. Ул вакытта бөтенесе дә СКА белән ЦСКАны җиңүче итеп юрый иде. Өзек: «КХЛның төп бүләген откан «алтын» «Ак Барс»тан составта хәзер бары Данис Зарипов белән... Василий Токранов кына бар. Ике ел элек финалда җиңелгәннәр исә шактый күбрәк. Фәкать кайчак оттыру зур җиңүгә караганда да шәбрәк тәҗрибә. Бу тәҗрибәне тулысынча эшкә җигү өчен иң кулай вакыт. Россиядә Гагарин кубогын өч тапкыр алган клуб юк әле. Ни өчен әле «Ак Барс»ка бу юлы да тарихта беренче булмаска?»

Бүген «Ак Барс» – Гагарин кубогын өч тапкыр яулаган команда.

ҖИҢҮЧЕЛӘР КОМАНДАСЫ КАПИТАНЫ

Ул УЕФА Суперкубогын баш өстенә чөя, Кубоклар Кубогыннан җиңү шампанын татып карый, Европа чемпионаты финалында уйный һәм дөньяның иң шәп җыелмалары капкасына шедеврга тиң голлар кертә. Казан янындагы Юдино бистәсендә үскән егет җитмешенче елларда СССР җыелмасы капитаны була, җанатарлар исә аны Йохан Круифф, Герд Мюллер һәм тоталь футбол эпохасының башка йолдызлары белән бер сафка куя.

Автор:
Әскәр Сабиров

Виктор Михайлович Колотов (1949–2000). 1972 елгы Европа чемпионатының көмеш призеры. 1972 һәм 1976 елларда Олимпия уеннарының бронза призеры. СССР җыелмасы өчен 55 матч үткәргән, 22 гол керткән. Алты тапкыр СССР чемпионы, ике тапкыр СССР Кубогы иясе. УЕФА Кубоклар кубогы иясе (1975). УЕФА Суперкубогы иясе (1975). Юдинодагы «Локомотив» балалар командасы шәкерте. Яшел Үзәннең «Чайка» (1967), Казанның «Рубин» (1968–1970), Киевнең «Динамо» (1971–1981) командаларында уйнаган. Украина Олимпия җыелмасының баш тренеры (1995–1996, 1998–1999).

Виктор Колотовка бөтенсоюз күләмендә танылу бөтенсоюз дәрәҗәсендәге гауга белән бер үк вакытта диярлек килә. Икенче (!) футбол лигасындагы «Рубин» уенчысының СССР җыелмасында кинәт пәйда булуына һәм шундук туп кертә башлавына җанатарлар күнегеп тә өлгерми, «Советский Спорт» газетасында аны фаш иткән мәкалә басыла. Яшь талантны аумакайлыкта һәм үз файдасын гына кайгыртуда, «совет спортчысына лаексыз» тәртиптә гаеплиләр. Янәсе, ул берьюлы өч клубка (Киев «Динамосы», башкаладагы «Торпедо» һәм ЦСКА) гариза биргән һәм үзенә оҗмах бакчасындагыдай шартлар таләп иткән.

Чынлыкта исә Колотов үзе өчен беркайчан да бернәрсә дә таләп итә белми. Ә менә клублар, талантлы Казан футболчысын үзләренә алырга теләп, аңа басым ясаудан тартынмый. Бигрәк тә армия клубы тәкатьсезләнә, футболчыны солдатка җибәрү белән яный. «Лампаслы ике парламентер, – дип сөйли торган була Виктор, – мине Төньяк боланнары көтеп торган урынны СССРның зур картасында да күрсәтте...»

Генералларны тыңламыйча, Киев «Динамосын» сайлаганы өчен аны бер елга дисквалификациялиләр. Әмма алда Европа чемпионатының сайлап алу матчлары көткәнгә, «үз файдасын кайгыртучы» футболчы җыелма командага бик кирәк булып чыга. Нибары ярты елдан соң, 1971 елның маенда ук, Виктор Колотов Испания җыелмасы капкасына җиңү тубын кертә.

СУПЕРКУБОК НИЧЕК ЯУЛАНА

Ил җыелмасында һәм Киев «Динамосында» уйнаганда Виктор

Фото: FreeSMI.by

Колотов керткән искиткеч голларны җанатарлар хәзергә кадәр хәтерли. Иң матуры, ихтимал, 1975 елның маенда Европа чемпионатының сайлап алу матчында Ирландия җыелмасы командасы капкасына кертелгән туптыр. Футбол күзәтүчесе Лев Филатов үз репортажында әлеге эпизодны мәңгеләштерә: «Туп Веремеевта. Еракта ирландиялеләрнең капкачысы һәм сакчысы. Һәм Веремеев беренче карашка бик сәер тоелган карар кабул итә – тупны шушы ике ирландияле арасына җибәрә. Билгеле, ул тупның кемгә әзерләнгәнен белеп тибә. Курку белмәс, озын сыйраклы, бераз эксцентрик Колотов сакчы артыннан кинәт килеп чыга да, циркта сюрприз ясагандай, түбәннән очкан тупны башы белән капкага юллый. 29нчы минут – 2:0. Тиз, катлаулы һәм матур! Һичшиксез, бу «Колотовка»

исәпләнгән вариант, күпләр моны булдыра алмас иде».

1975 елда Кубоклар кубогы ярымфиналында Виктор Колотов тагын бер могҗизалы тупны Голландия футболчылары капкасына кертә. Шул матчта катнашкан Леонид Буряк әлеге эпизодны менә болай исенә төшерә: «Трошкин почмактагы флаг янына кадәр үк китә. Ә сул фланг буйлап Колотов йөгерә һәм, нидер сизенгәндәй, һаман тизләнә бара, Трошкиннан ерактагырак штангага чыгар өчен, бераз почмакны кисә. Трошкин кинәт кенә тупны, 2–3 метр калдырып, капкага параллель тибә. Һәм Колотов, безнең җитез Витек, башы белән тупка килеп керә. Гол!»

Колотов бик күп туп кертә, ил җыелмасында уйнаганда гына да 55 матчта – 22 туп! Болай сөйлиләр: легендар испан капкачысы Рикардо Замора, 1971 елда уен кырында аны күргәннән соң: «Нинди «алтынчы» (Киев «Динамосы» өчен беренче матчларында Виктор 6 нчы сан астында чыгыш ясый – авт.) булсын бу, аның аркасында «тугызлы» булырга тиеш!» – дип кычкырып җибәрә. Тиздән Колотов чыннан да 9 саны астында уйный башлый...

Шунысын да искәртү мөһим: бомбардир Колотов җыелмада да, клубта да һөҗүмче түгел, бәлки ярымсакчы позициясендә чыгыш ясый. Һәм еш кына хәлиткеч булган голлар аның кырда һәр уендагы гаять зур эшенең бер өлеше генә. «Виктор Колотов уенының диапазоны кабатланмас! – дип ышандыра киевлеләрнең атаклы тренеры Валерий Лобановский үзенең «Бесконечный матч» китабында. – Ул барысын да шулкадәр дөрес һәм вакытлы эшли, трибуналардагы беренче матчтан соң ук аны үзенең яраткан футболчысы иткән җанатарлары гаҗәпләнеп туя алмый. Кыска арагамы, уртачамы, ерак арагамы, тупны кемгә дә булса тапшыргач, ул капкага таба оча. Аны туктаталар, төртәләр, тарталар, әмма тыя алмыйлар – ул һәрвакыт тупны ничек тә беренче булып эләктерергә һәм капкага кертергә омтыла».

Трибуналар Колотовның чыдамлыгына таң кала, киреәксә, ул өченче, дүртенче таймны да уйнаячак, һәр беренче икесе кебек үк бик шәп уйнаячак, дип шаяртталар. Лобановский төгәллек кертә: «Гадәттә футболчылар көчләрен саклап калырга тырышса, Колотов исә сәгать ярымда үзен бер дә кызганмый уйный, кайвакыт үзен-үзе белештермәс хәлгә җитә». Командадашлары менә бу эпизодны еш исләренә төшерә. Кубоклар кубогы ярымфиналында җиңгәч, Виктор, душтан чыккач, әкрен генә сораган имеш: «Егетләр, исәп-хисап нинди соң?»

Суперкубок-75 өчен Мюнхен «Бавариясе» белән тарихи матчта немец сакчысы Колотовның ботына аяк киеменең шиплары белән килеп кадала. «Динамо» капитанын уен кырыннан носилкага салып алып чыгалар. «Аның боты тапалган итне хәтерләтә иде – бәйләр өчен бинтым көчкә җитте. Әмма кан бинт аша да чыкты, – дип сөйли команда докторы Виктор Берковский. – «Тизрәк!» – дип ашыктыра мине Виктор. Мин аны ничек кенә тыярга тырышмыйм, бәйләп бетерүгә үк, ул сикереп торды һәм кырга йөгереп кереп китте. Бинтларыннан кан саркый, күзләре яна! Немецлар аңардан куркып читкә тайпыла». Күрәмсең, суперкубокны шулай гына яулап буладыр...

Ниһаять, дөньяга шундый уенчыны бүләк иткән футбол мәктәбе турында сөйләр вакыт җитте.

ОЛИМПИЙКАГА ДА КАНӘГАТЬ!

Юдинода Колотовлар яшәгән, каралып беткән иске агач барак урманга терәлеп үк тора. Биредә, урман авызында, малайлар иртәдән кичкә кадәр туп тибә. Виктор үзен белә башлаганнан бирле футбол уйнавын искә төшергәләгән. Әмма Колотовны чынлап уйнарга балалар секциясе тренеры Геннадий Востоков өйрәткән. Үзенең беренче остазын Виктор гомерендәге иң яхшы тренеры, дип санаган...

18 яшендә тимер юл һөнәри-техник училищесын тәмамлаганда Колотовны көтмәгәндә Яшел Үзәндәге «Б» классында чыгыш ясаган «Чайка» командасына чакыралар. Әлеге тәкъдим Викторның үзе өчен генә көтелмәгән була: озын аяклы, тиз, чыдам футболчыны балалар-үсмерләр турнирларында иң яхшы сакчы дип тә, иң яхшы һөҗүмче дип тә тапкалыйлар – ул башкалардан аерылып тора. «Чайка» командасында да югалып калмый: беренче сезонда ук 24 туп кертә һәм иң яхшы бомбардир дип табыла.

«Безнең соңгы уенга исә минем арттан ике машина килде: берсе Казаннан, икенчесе Йошкар-Оладан. «Рубин» җитәкчесе җитезрәк булып чыкты һәм мине Казанга алып китте. Җирле җитәкчелек үз «татарын» читкә җибәрергә теләмәде», – дип тасвирлый Колотов үзенең Казан клубына күчүен. Яшь талантка «Рубинда» нәрсә вәгъдә иткәннәр икән? Тарихта бу турыда мәгълүмат юк. Ихтимал, бернәрсә дә ышандырмаганнардыр, ул чакта әле контракт дигән нәрсә таралмаган булган, Колотов та үзе өчен нәрсәдер таләп итүчеләрдән түгел. «Ул гади авыл егете, эшчән, тырыш кеше. Аңа бернәрсә дә кирәкми иде. Футболны бик ярата, командага алып, олимпийка биргәннәренә дә канәгать». (Виктор Колотовның Казан «Рубинындагы» клубташы Николай Пензин хатирәләреннән).

Колотов ул – Аллаһ биргән талант, дип кабатлаудан туктамый футбол йолдызлары аның җыелма команда уенчысы булган вакытында. Әмма илебез киңлекләрендә, үз вакытында күреп алмаганга, чынлап торып ачылмый юкка чыккан талантлар да бик күп бит. Кем белә, 1970 елның көзендә Казанга Гавриил Дмитриевич Качалин килмәсә, булачак футбол йолдызының язмышы бәлки башкачарак язылыр иде. Дөнья футболы турында лекцияләр белән чыгыш ясаганнан соң, СССРның атказанган тренеры стадионда «Рубин» белән Омскиның «Иртыш» командасы очрашуын карый. Әлеге матчта Колотов ике тапкыр гол кертә, мэтрны исә «Викторның гаҗәеп буй-сыны, йомшак, сыгылмалы мускуллары, нык сөяге, фантастик хезмәт сөючәнлеге» таң калдыра, һәм ул аны ил җыелма командасы тренерына тәкъдим итә.

Аннары барысы да әкияттәге кебек булып чыга. Икенче лигада уйнаучы беркем дә белмәгән спортчы СССР җыелмасы өчен беренче матчында ук югославларга гол кертә, аннары рәттән өч уенда да туп керми калмый... 1972 елда инде Колотов – Европа чемпионаты көмеш бүләге иясе, җыелма команданың һәм Киев «Динамосының» танылган лидеры. Мадридның «Реал» командасы тренеры Мигель Муньос исә, киевлеләрдән кемне үз командагызга алыр идегез, дигән сорауга, уйлап та тормыйча һәм һич икеләнмичә: «Колотовны, Блохинны һәм Мунтянны», – дип җавап бирә.

БЕЗДӘГЕ СОҢГЫ МАТЧ

Трибуналардан караганда барысы да әкияттәгедәй җиңел күренсә дә, тренировкаларда Колотов манма тиргә батканчы тырыша. «1971 елда, инде «Динамода» чакта, әллә травма, әллә дисквалификация аркасында Витя бермәл уйнамый торды. Казанга кайтып, безнең белән шөгыльләнде. Бездән соң да калып күнегүләр ясый, язгы һава торышының көйсезләнүенә дә исе китми, үзен бер дә кызганмый инде. Безнең исебез китә иде...» (Николай Пензин хатирәләреннән).

Ә менә футбол йолдызының Киевтәге графигы. Иртәнге сәгать 6 да йокыдан тору, зарядка, җиде дә утызга – өеннән унбер чакрымдагы институтка. Аннары – шундук тренировкага, аннары – кабат институт. «Төшке аштан соң – икенче тренировка, һәм мин кичке сәгать сигезләрдә генә өемә кайтып егылам. Ат кебек арый идем!» – дигән Виктор Колотов соңгы әңгәмәләренең берсендә.

Аңа бернинди йолдыз чире дә йокмаган. Гади, аз сүзле, бик тыныч һәм бик намуслы. Дусты Владимир Бырся 90 нчы еллар башында эшсез калгач, командасына администратор итеп чакырган (Виктор ул чакта тренер булган инде). Күп еллар узгач кына, Колотовның дустына хезмәт хакын... үз кесәсеннән түләве ачыкланган.

...Казан һәм Татарстан өчен соңгы матчын Виктор Колотов 1972 елның көз азагында уйный. Автономияле республикалар кубогы финалы була, анда чыгышлары белән республикалардан булган, хәзер югары лига командаларында уйнаучылар катнаша ала. Кагыйдә буларак, аларның күбесе, сәбәп табып, баш тарта. Ул вакытка инде ил чемпионы һәм Европа чемпионаты призеры булган Виктор исә баш тартмый. Мин ул матчны хәтерлим: Колотов штраф линиясе артыннан капканың нәкъ аскы почмагына турылады. Хәлиткеч тупны кертте. Үз эшен эшләде һәм кабат китеп барды...

2004 елда Яшел Үзәндә, кайчандыр үзе уйнаган стадионда Виктор Колотовка һәйкәл ачылды. Биредә хәзер ел саен бөек футболчы истәлегенә багышланган турнир үткәрелә. ■

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Каһарманнар буыны **НИНДИ** була

Идел–Урал Штаты **НИГӘ** төзелмәгән

Кол Гали турында **НӘРСӘЛӘР** беләбез

Сугышта **НИНДИ** җырлар юаныч булган

Сталин **КЕМНЕ** аягүрә алкышлаган

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Әхәт Юлашев – генерал-майор. СССР хәрби көчләрендә кырык еллык хезмәт дәверендә взвод командиры дәрәҗәсеннән башлап, Кавказ арьягы, Урта Азия, Байкал арьягы һәм Себернең һава чикләрен саклау өчен һава һөҗүменә каршы оборона буенча аерым армиянең радиотехник гаскәрләре башлыгына кадәр юл уза. 1980 елда Әфганстандагы радиотехника гаскәрләренең хәрби әзерлеген күтәрүдә катнаша. 2001 елдан «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасын җитәкли.

ГЕНЕРАЛ **ЯЗМЫШЫ**

Сугыш башланганда, урамда башка балалар белән атышлы уйнап йөргән малай гына була әле ул. Ә Ватан сугышы тәмамлануга, вакыт ягыннан – кырык елга, ә юллар озынлыгы ягыннан меңнәрчә чакрымга сузылган үз хәрби карьерасы башлана. «Һәркем өчен үрнәк булырлык», – дип бәя бирде Әхәт Юлашевка Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, аңа «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» орденын тапшырганда.

МАКСАТКА ОЧЫП БАРЫРГА

Диксон утравыннан Төньяк полюска нибары ике сәгать очасы. Мин җитәкчелек иткән һава һөҗүменә каршы оборона буенча радиотехника гаскәрләренең бер өлеше әнә шундый ерак почмакларда – Төньяк Боз океаны яр буйларында һәм андагы утрауларда урнашкан иде. Шул җиде ел хезмәт вакытында төрле хәл булды. Бервакыт Визе утравында җил радиолокация антеннасын ваткан дигән хәбәр килде. Бу минем өчен бер нәрсәне генә аңлата: анда эшкә җигелгән рота сугышка әзерлексез хәлдә калды. Утрауга кичекмәстән запас антенна илтергә кирәк, тик ул вертолетка сыймый. Җитәкчелеккә шалтыраткан идем, ә җавап урынына: «Әхәт, антенна күтәреп алып бару куркыныч. Үзең хәл ит», – дигәнне генә ишетергә насыйп булды. Һәм мин «очарга» дигән карар кылдым. Вертолет командиры: «Антенна бик чайкала башласа, миңа аны өзеп ташлап калдырырга туры киләчәк, югыйсә вертолет идарәсен югалтачак», – ди. Утрауга килеп җиткәндә, җил көчәйде – безнең вертолетка асылган антеннаны йомычка урынына селкетә. «Тагын бераз гына түзәм дә ташлыйм!» – дип кычкыра командир. Ләкин илтеп җиткерәсе бик килә бит! Әнә шулай минутларны саный-саный, антеннаны китереп тапшыра алдык. Бик сак кына төшердек. Безне инде анда кадерле кунаклардай каршы алдылар. Хәер, без дә буш кул белән килмәдек – җиләк-җимеш, яшелчә төягән идек – ул якларда бик тансык нәрсәләр. Әлеге кырыс, хәтта вакыт-вакыт рәхимсез салкын Себер яклары тормышымдагы бик якты мизгелләр булып хәтергә уелды.

БАШКА ТОРМЫШ

Сугышны Казахстанда каршыладым. Без, малайлар, нинди зур кайгы килгәнен әүвәл аңламадык та. Беренче көннәрдә үк ир-атларны фронтка алып китә башладылар. Без шулар янына машина арбасына сикереп менәбез дә, вокзалга кадәр үзләрен кысып кочаклап барабыз. Безнең өчен дә башка тормыш башланды, миңа инде укырга да кирәк түгел кебек тоелды. Без күбрәк атышлы уеннар уйнадык, мин аларда башлап йөрүче булдым. «Сугыш» уены күрше авыллар – мәктәп белән мәктәп арасында иде. Әле тегеләй-болай гына түгел – чып-чын разведкалар ясап! Мине военком ничек күреп алгандыр, анысын белмим, ләкин өлгерлегем монда мөһим роль уйнагандыр, дип уйлыйм.

«Син казахча беләсеңме?» – дип сорады ул. Миңа бу тел ят түгел иде: рус мәктәбендә дә казахныкында да укырга өлгердем. «Димәк, минем белән мобилизациягә барасың!» – дип куймасынмы! Шунан соң ике ел военком белән кышлаклар буйлап йөрергә туры килде. Җигелгән атта көненә еш кына 20–30 чакрым узабыз. Мин ат йөртүче дә, тәрҗемәче дә булдым. Кыскасы, мәктәпне мин күбрәк әнә шулай юлда йөреп уздырдым. Һәм менә киләчәккә юл сайлар вакыт җитте. «Кем буласың килә?» – дип сорый военком. «Институтка керәсем килә, юристлыкка», – дим. «Син-

Фото: Александр Ефремов

нән нинди юрист чыксын? Әйдә хәрби училищега! Әнә Мәскәүдән безгә разнарядка да килде».

ЯЗМЫШТАН КАЧЫП БУЛМЫЙ

Мин башкалага трамвай тәрәзәсеннән күзем дә алмыйча, гаҗәпләнүдән авыз ачып карап бардым. Хәтта үз тукталышымны да үтеп киткәнмен. Менә мин казармада. Каршымда буш тимер карават, урын-җир урынына – бер дистә газета. «Син ястык күтеп торыр дигән идеңме әллә?» – дип төрттерә хәрби училище хезмәткәре. Уку елы башын без Мәскәү янындагы Кашира каласында – бәрәңге басуында каршыладык. Сентябрьдә көн салкын иде, куллар боз булып катты, йокы бүлмәләрендә түшәмнән су үтә, ашау ягы коточкыч... «Әйдә качыйк моннан!» – дип котыртып карыйм дустымны. Ә кая барасың? Өйгә, Казахстанга кайтырга була – анда җылы! Тимер юл вагонына «куяннар» булып эләгә алдык – баш күктә! Мәскәүгә көн буе барасы. Тик башкалага барып җитә алмадык. Яшеренгән урыныбыздан безне хәрби комендатура патруле тартып чыгарды. Һәм тагын Каширага, тагын басуга... Кәеф кырылды, дип әйтү аз булыр! Ләкин алда язмышның кызыклы борылышы көткән икән. Шушы барлык бәла-казалардан соң Мәскәү безне кайнар душ һәм җылы киемнәр белән каршы алды. Ә хәрби училищедагы төшке ашны әйтәсе дә юк – беренче, икенче аш, акмай белән ак ипи, әле компоты да бар! Шуннан соң качу турында нинди уй булсын, ди, без калырга карар бирдек. Хәрби карьерам әнә шулай башланды.

ХӘРБИ ХЕЗМӘТТӘ КЫРЫК ЕЛ

1980 елда мин, инде полковник дәрәҗәсендә, Әфганстанда радиотехник гаскәрләрнең хезмәтен оештыру һәм команда пунктын көйләүдә ярдәм күрсәттем. Сугышларда турыдан-туры катнашмасам да, кызу вакытларга эләккән булды. Хәтеремдә: Кандагар тирәсендә дошманнар безнең радиолокация ротасын тар-мар иткән, дигән хәбәр ирешә. Миңа радиолокация системасының һәм сугышчылар составының ни хәлдә икәнен төгәл ачыкларга кирәк иде. Пистолет белән коралланып, бердәнбер автоматчы озатуында Кабулдан сәфәр чыктым. Юлда безне алгы сак хезмәте каршы алды. Кандагар оборонасын тәэмин итүче генералны чакырдылар. «Каравылсыз гына ничек юлга чыгарга була? Барыгыз, китегез моннан! Сине хәзер атып үтерәләр, башкаларны да исән калдырмыйлар!» – дип кычкыра башлады генерал. Ике көннән, бу юлы инде самолетка утыртып, кире Кабулга кайтарып җибәрделәр. Тиешле урынга без могҗиза белән генә барып җитә алдык...

Укуны тәмамлаганнан соң, башта мине Азәрбайҗанга юлладылар. Каспий диңгезе буена – Иран белән һава чикләрен саклаучылар янына эләктем. Аннары мине язмыш карсыз, зәмһәрир салкынлы Байкал аръягына, илле градус эссесе көйдергән Төркмәнстанга, суык төньяк җилләре искән Себергә алып китте... Хәрби юлымның кырык елы да Советлар Союзының төрле чикләрендә узды – беркайчан да үзәктә хезмәт итмәдем. Гаиләм һәрвакыт янымда булды. Безнең күченү дә бик гади, җиңел иде: бөтен нәрсәбез ике чемоданга сыеп бетә – мин ике кулыма шул чемоданнарны, ә хатыным Галина балаларыбыз Руслан белән Людмиланы күтәрә. Шул рәвешле без бер унбиш тапкыр юлга чыкканбыздыр.

«ӘЙДӘ БЕЗГӘ!»

Мин Казанга Бөтендөнья татар конгрессының икенче корылтаена Ташкентның татар диаспорасыннан делегат булып килдем. Андагы чыгышымның ахырында Татарстан Президентына өч китап бүләк итәргә теләвем турында җиткердем. Бу –Үзбәкстаннан сугышка алынган һәм яу кырында һәлак булган татарлар турында Хәтер китаплары иде. Минтимер Шәймиев урыныннан торып яныма килде дә кочаклап рәхмәт әйтте. «Син ник Казанда түгел?» – дип сорады ул. Мөгаен, тормышымдагы яңа чор әнә шул сораудан башлангандыр. Күп нәрсәдә Минтимер Шәрип улының ярдәмен тоеп, мин гаиләм белән шактый тиз арада Татарстанга күченеп килә алдым. Ел ярымнан соң телефоным шалтырый. «Син ни белән мәшгуль?» – дип сорау бирә бу юлы генерал Сәетгәрәев. «Менә нишләргә микән дип уйлап йөргән чак әле», – дип җавап бирдем аңа. «Әйдә, безгә кил, сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары комитетына!»

Республика районнары минем өчен аерым игътибарда булды. Кайчандыр ил буйлап йөргән кебек, мин Татарстан районнарын гиздем. Ветераннар һәм аларның тол хатыннарының, Әфганстанда, Чечняда сугышларда катнашучыларның нинди шартларда гомер кичергәнен үз күзем белән күрү мөһим иде. Фронтовикларга телефон сузу мәсьәләсен министрга кадәр диярлек барып хәл итәргә туры килгәләде, фатир турында әйтеп тә торасы юк! Бу ниндидер социаль авыру кебек иде. Бәхеткә, аны җиңеп чыга алдык. Кышка йортны ничек төзекләндереп булуы яки утын белән тәэмин итү турында Президентка да мөрәҗәгать иттем, хакимият башлыклары белән дә сөйләштем. Хәзер андый мәсьәләләр бетте диярлек. Ләкин әле дә юк-юк дигәндә дә бер хат килеп төшә, әйтик, менә бүгенге кебек – бер тол хатын өен сипләүдә ярдәм сорый...

КҮЗЛӘР ЯНЫП ТОРГАНДА

Миңа авыр холыклы яшүсмерләр белән шактый еш эшләргә туры килде. Кагыйдә буларак, андый очрашуларны милициянең балалар бүлмәсендә оештыралар иде. Менә каршыңда инде яманаты чыккан хулиган малай утыра, һәм син, дөресен әйткәндә, аны инде ничек акылга утыртырга икәнен дә белмисең. Андый вакытларда мин үземнең мәктәп елларым, сугыш, кешеләрнең батырлыгы турында сөйли башлый идем... Мондый әңгәмәгә карата мөнәсәбәт төрлечә була ала. Ләкин ике арада сөйләшү күпере корыла, ә бу инде уңышка бер адым, дигән сүз.

Мәктәпләргә дә баргаларга туры килде. Әле биш ел элек кенә республикада хәрби хезмәткә чакыру эше шактый катлаулы иде. Егетләр еш кына армия_ дән качып калу җаен эзли. Без очрашулар уздырып, әңгәмәләр кордык. «Ә сез үзегез солдат булдыгызмы соң?» – дип, бер малай булса да сорамый калмый. Чынбарлыкны сөйләргә туры килә. Бернәрсәне дә яшереп калдырмадым. Хәрби хезмәтнең кыенлыклары турында да сөйләдем. Хәзер хәлләр яхшыга үзгәрде. Өстәвенә, махсус кадет мәктәпләре дә барлыкка килде. Мин аларда үткәрелә торган кичә-бәйрәмнәргә барырга тырышам. Һичшиксез, хәрби кием киеп. Малайлар андыйны бик үз итә. Ә миңа исә бу киемгә караганда, аларның күзендә ялтырап очкын кабынуы ошый. ■

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Әзерләде:
Ольга Туманская

ИДЕЛ–УРАЛ ШТАТЫ

Журналыбызның апрель санында басылып чыккан «Татарлар – дәүләт төзү юлында» дип аталган мәкаләдә сүз татарларның милләт буларак оешуы, аның тамырлары турында барды. Бүген авторыбыз, татар тарихы турындагы сүзен дәвам итеп, 1917 елгы революцион өермәләр чоры турында сөйли.



Автор:
Индус Таһиров

Идел–Урал штатын төзү башлангычы Милләт мәҗлесе тарихына бәйле. 1917 елның маенда Мәскәүдә I Бөтенроссия мөселманнары съездында Нижгардан Габдулла Сөләймани исемле мулла Россияне штатлар рәвешендә үзгәртеп кору һәм анда татарлар өчен махсус штат булдыру идеясен күтәрә. Дөрес, бу бердәнбер тәкъдим булмый. Ләкин нәкъ менә шушы тәкъдим татар күңелендә тамыр җәя, башка фикерләрнең уңай яклары белән баетылып, 1917 елның көзендә тормышка да аша башлый.

Милләт мәҗлесенә сайлаулар үткәрү турындагы карар 1917 елның июлендә өч мөселман съездының уртак җыелышында кабул ителә, һәм аңа яшерен рәвештә тавыш бирү принцибы нигезендә гомум сайлаулар да үткәрелә.

Шул ук елның 20 ноябрендә Уфада Милләт мәҗлесе җыелып, Садри Максуди җитәкчелегендә эшен дә башлап җибәрә. Аның эшчәнлеге 1918 елның 11 февраленә кадәр дәвам итә. Бу уңайдан «Известия Всероссийского Мусульманского Военного Шуро» болай дип яза: «Хәзерге заманда һәр милләт үзенең эчке тормышын төзү белән мәшгуль. Инде ниндидер съездлар, кәгазь резолюцияләрнең вакыты үтте. Иске җимереклекләр нигезендә Россия халыкларының яңа, якты киләчәкләрен төзергә кирәк. Милләт мәҗлесе нәкъ менә шул практик эш белән шөгыльләнә». Мәҗлестә Бөтенроссия Мөселман хәрби шурасының рәисе 22 яшьлек прапорщик Ильяс Алкин күтәреп чыккан татарчылык рухы хөкем сөрә. «Безнең, – ди ул үз чыгышында, – тарихи хәтеребез көчле, һәм без, аңа таянып, нинди генә юллар белән булмасын, Татарстанны барлыкка китерергә тиешбез».

Мәҗлес өчен иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе татар-башкорт мөнәсәбәтләре була. Аны хәл итү юлларын эзләүдә, шушы ике туганлаш халыкны үзара аңлашу юлына бастыру өчен зур көч куючыларның берсе Галимҗан Ибраһимов була. Ул башкорт һәм татарларның уртак дәүләте булырга тиешлеген алга сөрә. Төрле газета битләрендә аның моны дәлилләгән мәкаләләре бастырыла.

Ләкин Зәки Вәлиди җитәкчелегендәге иҗтимагый хәрәкәт башкорт автономиясен булдыру юлына ныклап баскан була. Штатны булдыру өчен башкортлар белән аңлашу, арадашлык итү вазыйфасы Галимҗан Ибраһимовка йөкләнә.

Шул ук 1917 елның декабрь аенда Оренбург шәһәрендә башкорт корылтае җыелып, Башкорт Республикасы игълан ителә. Ибраһимов, Оренбургка барып, корылтайда тирән эчтәлекле доклад ясый һәм бик күпләрне Штатка кушылу идеясенә күндерә. Ләкин инде булды дигәндә, Зәки Вәлиди койрыгын бора, «татарлар яһүдләр кебек алар» дип, башкортларны Идел–Урал штатына кушылмаска өнди[1].

Ләкин ничек кенә булмасын, Галимҗан Ибраһимов Зәки Вәлидине Мәҗлескә килергә күндерә. Ул анда килә һәм чыгыш ясый. Чыгышында татарларны куркаклыкта гаепли, милли мөхтәрият һәм территориаль автономия арасында койрык болгап йөрүчеләр, дип атый. Әмма шулай булса да, ул Штатка кушылырга ризалык бирә.

Ләкин, әгәр дә шушы зур эшләрнең башында торучының Бөтенроссия Мөселман хәрбиләре шурасының рәисе данлыклы морзалар токымының дәвамчысы Ильяс Алкин булганлыгын ассызыкламасак, бу зур гаделсезлек булыр иде.

Садри Максуди рәислегендәге Мәҗлес Идел–Урал штатын төзү Коллегиясен сайлый. Аның составына И. Алкин, С. Янгалычев, Г. Шәрәф, Ф. Мөхәммәдъяров, Ф. Сәйфи, С. Атнагулов, Г. Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин кертелә. Җитәкчелек вазыйфалары Ильяс Алкинга йөкләнә. Ә аның рәистәше итеп Галимҗан Шәрәф сайлана. Монда тагын руслардан 5, чувашлардан 2 һәм чирмешләрдән 1 кеше кертү тиешле табыла. Коллегиянең Казанда эшләргә тиешлеге фаразлана.

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

[1] Тормыш, 1917, 19 ноябрь

Хәрби шура үзенең 1918 елның 17–18 гыйнвар көннәрендә бу эшкә кичекмәстән тотынырга кирәклеге һәм Штатның Учредительный җыелышына сайлаулар үткәрү турында карар кабул итә. Һәм Казан Советы белән шушы турыда сөйләшүләр башлап җибәрә. Ләкин бу сөйләшүләр уңай нәтиҗә бирми. Чөнки халыклар дуслыгының дошманнары шәһәр халкы арасында коткы тарата: имеш, Шура шәһәрне үз кулына ала һәм татар идарәсен оештыра, хан заманнары әйләнеп кайта һ.б.лар.

Шушы уйдырмаларга җавап итеп, Хәрби шура, Мөселман хәрби округы комитеты, мөселман хәрби комитеты, инде татарлаштырылган 95нче полк вәкилләре 31 гыйнвар көнне Казан халкына мөрәҗәгатъ кабул итә. Анда мондый сүзләр бар: «Рус туганнар – солдатлар, крестьяннар, эшчеләр! Инде ике ай буе шәһәрдә әшәке провокацион имеш-мимешләр таратыла. Имеш, мөселман оешмалары җирле совет хөкүмәтен кулга алырга тели». Мөрәҗәгатьтә тагын мондый сүзләр бар: «Безме соң инде гасырлар буе иске режим тарафыннан изелгән, сезнең белән янәшә тынычлык, яхшы күршелек мөнәсәбәтләрендә яшәгән революцион демократия, инде менә азатлыкның якты кояшы чыккан көннәрдә бозылышырга тиешбез? Юк, юк һәм кабат юк!»

Хәрби шураның шулкадәр ачык позициясен Казан Советы җитәкчеләре күрмәмешкә салышалар һәм, шул ук вакытта съезд делегатлары арасына чөй кагып, аларны бер-берсенә каршы куярга маташалар. Һәм максатларына ирешәләр дә. Шушы шартларда, ни кызганыч, милли әһелләребез арасында аңлашылмаучанлык арта. Милләт мәҗлесе һәм Хәрби шура арасында да нинди дер фикер каршылыклары чыга.

Хәрби шура штат игълан итүне II Бөтенроссия Мөселман хәрби съездында кабул итүне кирәк таба. Тиз арада тыл һәм фронттагы хәрби частьләрдән 200 делегат сайлана, һәм 1918 елның 8 гыйнварында съезд үзенең эшен башлап та җибәрә. Аны Ильяс Алкин ача. Йосыф Мозаффаров, кулына Штат картасын тотып, аның асылы турында доклад ясый. Картаны Галимҗан Шәрәф төзегән була. Шул ук көнне съезд, Совет властен яклап, III Бөтенроссия Советлар съездының карарларын тулысы белән таныганлыгын белдерә. Тик менә Казан Советы аларны танырга теләми. Аның җитәкчеләре Брест солыхына да, III Бөтенроссия Советлар съездының Россияне федерация итеп игълан иткән карарына да каршы чыгалар. Һәм инде, әлбәттә, Идел–Урал штатына да каршы булалар. Зур каршылыклар күрсәтеп, аны игълан итүне булдырмаска тырышалар. Һәм татар «сулларына» таянып, аларның куллары белән съезд җитәкчелеген кулга алалар.

1918 елның 28 февралендә игълан ителергә тиешле Штат игълан ителми кала. Ни кызганыч, бу эшкә Мирсәет Солтангалиев һәм Шамил Усманов җитәкчелек итә. Соңрак алар хаталарын таныйлар, эшләгән гамәлләренә үкенәләр. Тик инде соң була.

Съезд эшен Болак артына күчерергә мәҗбүр була. Аны таркату өчен, Мәскәүдән ул вакытта Бөтенроссия мөселман комиссариаты җитәкчесе Мулланур Вахитов 300 кешелек матрослар отряды җибәрә. Шуның белән Идел–Урал штаты идеясе юкка чыга.

Ни кызганыч, әле бүгенге көнгәчә шушы идеяне татарларның Россиядән чыгуга юнәлтелгән адымнары рәвешендә күрсәтә килүчеләр бар. Югыйсә Штатны төзү турындагы документта аның Совет Россиясе составында шартнамәле республика булырга, анда тышкы эшләр, банк-финанс системасы, тимер юллар үзәк хакимият карамагында булырга тиешлеге күрсәтелгән.

Ә бит, әгәр дә шул вакытта ук шундый шартнамә барлыкка килгән булса, Россиянең чын федератив дәүләткә әверелүенә юл ачылган булыр иде. Татарстан өчен, башка республикалар кебек үк, СССР төзелгәндә аның тулы хокуклы әгъзасына әверелү ихтималы юк булмый. Һәм бәлки СССР да таркалмаган булыр иде.

Бу, әлбәттә, фаразлар гына. Чөнки реаль тарих күпкә катлаулырак. Аңа абруйлы аерым шәхесләрнең йогынтысы зур була. Аларның үзара мөнәсәбәтләре беренче урынга чыга. Әйтик, Зәки Вәлиди һәм аның көрәштәшләре тулысы белән Штат идеясенә күнеп, Штат игълан ителгән булса, бу ике халыкның үзбилгеләнү принцибына нигезләнгән республикасы төзеләчәк иде. Гаяз Исхакый Зәки Вәлидине Идел–Урал Штатына аяк чалучы, дип бәяләгән һәм аны шуның өчен беркайчан да гафу итмәячәген әйтә торган булган[2]. Ләкин большевиклар, бигрәк тә Сталин моңардан бик оста файдалана, татар белән башкортны үзара каршы куяр өчен булдыра алганның барын да эшли. Халыкларның үзбилгеләнү хокукы өстән билгеләү принцибына алыштырыла. Шушы юнәлештәге адымнарның берсе 1918 елның 22 мартында Иосиф Сталин һәм Мулланур Вахитов тарафыннан имзаланган Татар–Башкорт Республикасы турындагы Нигезләмә була. Әлеге республиканың территориясе Галимҗан Шәрәф төзегән Идел–Урал штатының территориясенә тәңгәл килә. Тик бу документ, гамәлгә ашыру өчен түгел, ә Идел–Урал проектын бөтенләе белән юкка чыгару өчен генә дөнья күргән бер уен булып чыга.

Шул ук елның июль ахырында Мулланур Вахитов Мәскәүдән Казанга килә. Шәһәр аклар кулына күчкәч, алар тарафыннан атып үтерелә. Бу каһарманның үлеме милли азатлык юлындагы беренче иң зур корбан була. Ләкин соңгысы булмый, упкын яңа корбаннар сорый... Революция үз балаларын үзе ашый, дип юкка гына әйтелмәгәндер, күрәсең.

Большевикларга исә Идел–Урал штаты да, Татар–Башкорт республикасы да кирәкми. Әлеге Республика Сталин планнарында бер уен гына була. 1922 елда Ленинга җибәргән бер хатында ул мондый уеннарны туктатыр вакыт җитте, чөнки моңа миллиләр (националлар) үзләре дә ышана башладылар, дип яза.

Татар–Башкорт республикасы да бер максатка – Гражданнар сугышы вакытында татар-башкорт потенциалын тулысы белән файдалануга юнәлтелгән уен гына була. Һәм 1919 елның 13 декабре көнне РКП (б) Политбюросы Милли эшләр буенча халык комиссариатының проектын юкка чыгара һәм бу республиканы төзү өчен агитация алып баруны тыя.

Бервакыт республиканы Казансыз һәм Уфасыз төзү идеясе калкып чыга. Монысы кайдан чыккан, бу кемгә кирәк булган? Тик инде моңа барлык күренекле зыялылар бердәм рәвештә каршы чыгалар.

Искиткеч авыр еллар бу. Совет хөкүмәтенең халыкны, бигрәк тә крестьян халкын продразвёрстка белән талап бөлдергән Гражданнар сугышы еллары. Шушы талауларга, рәнҗетүләргә җавап буларак, сәнәкчеләр фетнәсе күтәрелә. Ул 1920 елның 7 февралендә башланып, 35 көн дәвам итә. Аны даими гаскәр көче белән канга батырып бастыралар.

[2] «Мәдәни җомга», № 9, 2018

КОЛ ГАЛИ ҺӘМ АНЫҢ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ӘСӘРЕ

Автор:
Фаяз Хуҗин

Татарны татар иткән, язма әдәбиятыбызга нигез салып, абруебызны дөньякүләм дәрәҗәгә күтәргән күренекле шәхесләребез арасында болгар шагыйре Кол Гали исеме дә бар. Аның «Кыйссаи Йосыф» поэмасы гасырлар буе укучылар кулыннан төшмәгән, күпләр аны яттан белгән, көйләп укыганнар, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кулланганнар. Кол Гали бүген дә онытылмый. Киресенчә, аңа булган кызыксыну көчәйгәннән-көчәя генә бара.

«Кыйссаи Йосыф» авторын Бакый Урманче мәрмәр сында мәңгеләштерде, Нурихан Фәттах «Кол Гали» трагедиясен иҗат итте. Башкалабызның бер урамына Кол Гали исеме бирелде. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү көннәрендә барлыкка килгән паркта аңа һәйкәл ачылды. Шагыйрь исеменә багышлап җырлар, шигырьләр, поэмалар языла. Йосыф белән Зөләйха исә балет сәхнәсендә җанланалар…

Шунысы кызык: фән дөньясында «Кыйссаи Йосыф» поэмасына иң әүвәл Генрих Фляйшер исемле немец галиме игътибар итә. Ул бу әсәрне үзенең 1831 елда басылып чыккан китабында телгә ала. Баксаң, «Кыссаи Йосыф» кулъязмасы Германиянең Дрезден шәһәрендәге мирасханәләрнең берсендә саклана икән. Ул әле XVII гасыр ахырында ук Казанның Иске бистәсендә яшәүче Динмөхәммәд Саттаров исемле бер тылмач тарафыннан язып алынган була.

Шул ук вакытта, элегрәк тә булмаса әле, үзебезнең атаклы татар галиме һәм шагыйре Габдерәхим Утыз-Имәни әл-Болгари (1754–1834) «Кыйссаи Йосыф»ның күп кенә борынгы кулъязмаларын җыя башлый, аларны чагыштырып өйрәнә һәм әсәрне төп текстын басмага әзерли. Китап 1839 елда Казан университеты нәшриятында дөнья күрә. Шуннан башлап ул һәр елны диярлек (!) зур тиражлар белән чыгып тора һәм Көнчыгышны өйрәнүче галимнәрнең югары бәясенә лаек була. Поэманы фәнни нигездә ныклап өйрәнү башлана.

ПОЭМАНЫҢ АВТОРЫ КЕМ?

Әсәрнең тәмамлау өлешендә текстны язучы шагыйрь үзе турында болай ди:

Моны язган зәгыйфьнең аты –
Гали…
Өмет баглыйм мин гөнаһлы
Син Тәңрегә,
Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле
Син иямә,
Кыл мәрхәмәт-шәфкать миңа –
Кол Галигә,
Кайгылы бу җанымны син шат
кыл имди.

Фотолар: Александр Ефремов; автордан алынды

«Гәүһәр таштыр, ләкин һәр таш гәүһәр улмас,
Гәүһәр кадерен тимә кемсә кыяс кыйлмас».

Гол Гали

Авторы: Бакый Урманче.

Шагыйрь поэманың язылып бетү вакытын күрсәтә: «Мәүлям миңа кылган ярдәм аркасында, изге, бөек рәҗәп ае утызында, тарих елының алты йөз тугызында бу зәгыйфь кол бу китапны төзде имди». Димәк, «Кыйссаи Йосыф»ка һиҗри белән 609 елда, рәҗәп аеның 30 нчы көнендә, хәзерге календарьга күчереп исәпләсәң, 1212 елның 9 декабрендә нокта куелган була. Ләкин поэманың кайбер нөсхәләрендә аның тәмамлану датасы итеп һиҗри белән 630 ел, рәҗәп аеның 30 нчы көне күрсәтелгән. Бу безнеңчә 1233 елның 13 апреленә туры килә. Галимнәр, өстәмә дәлилләр китереп, «Кыйссаи Йосыф»ны чыннан да 1236 елгы монгол-татар яулары алдыннан язылган дип уйлыйлар.

Кол Гали бу әсәрендә шәхсән үзе турында бернинди мәгълүмат та китерми. Кем ул, кайчан туган, нинди нәселдән, тормышта нинди хезмәт белән шөгыльләнгән, гаиләсе булганмы-юкмы? Бу сораулар җавапсыз калган.

Галимнәр хәтта Кол Галинең кайсы халык шагыйре булуы турында да бәхәсләшеп алдылар. Дөрестән дә, ул бит әсәрендә үзенең милләтен күрсәтмәгән. Тел галимнәре фикеренчә, поэманың теле огуз, ягъни хәзерге төркмән, төрек теле элементларына бай. Уйгур-карлук һәм кыпчак телләренең үзенчәлекләре дә Кол Гали өчен чит түгел. Шулай булырга тиеш тә, чөнки поэма Урта гасырлар шигърияте дөньясында, шул исәптән Урта Идел төбәгендә дә киң таралган катнаш төрки телдә язылган. Ә менә кайбер галимнәр «Кыйссаи Йосыф»ның авторын угыз халыклары арасыннан, хәзерге Төркия җирлегеннән, Урта Азия якларыннан эзләделәр. Ләкин ул, һичшиксез, – болгар шагыйре. Моның шулай икәнлегенә төп һәм иң ышандыргыч дәлилләр кире каккысыз: «Кыйссаи Йосыф»ның безгә мәгълүм барлык кульязмалары да диярлек татарлар яши торган төбәкләрдә табып алынган. Башка төбәкләрдә яшәүче төрки халыклар (башкортлар, казахлар, үзбәкләр, төркмәннәр, төрекләр, азәрбайҗаннар) поэманы белмиләр, үзләренеке итеп танымыйлар.

Легенда-риваять кебек халык авыз иҗаты әсәрләре ышанычлы тарихи чыганаклар була алмый, әлбәттә. Әмма аларны читләтеп үтү дә ярамас кебек. Таҗетдин Ялчыголның 1806 елда борынгы кульязмалар, шәҗәрәләр, риваятьләр һәм башка төрле чыганаклар кулланып язылган «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») әсәрендә Кол Мирхаҗи бәк улы Кол Галинең Зәй төбәгендә тууы, егет булып җитешкәч, белем эстәп, Хәрәзм якларына чыгып китүе, аннан соң туган якларына, атасы йортына кайтып, халыкка хезмәт итүе, монгол яулары вакытында һәлак булуы бәян ителгән.

Кол Галинең кайбер риваятьләрдә китерелгән туган елы – 1183 ел. Аны Болгар иленең шул чордагы башкаласы Биләрдә туган диючеләр дә бар. Шулай икән, «Кыйссаи Йосыф»ны шагыйрь 50 яшендә иҗат иткән булып чыга. 53 яшендә, ягъни 1236 елның көзендә бакыйлыкка күчә.

Тагын бер тапкыр кабатлап әйтәм: боларның барысы да Кол Гали биографиясендәге фәнни яктан расланып җитмәгән фактлар. Бөек шагыйрьнең кем булуы турында язучы Вахит Имамовның «Утлы дала» романын укып та белә аласыз. Әлегрәк «Кыссаи Йосыф» авторы образын Нурихан Фәттах үзенең заманында Камал театрында шаулап барган «Кол Гали» трагедиясендә гәүдәләндергән иде. Ләкин болары да – бары тик язучы фантазиясе генә.

«КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫ

Поэманың эчтәлеге, сюжеты бик борынгы дини һәи мифологик легендаларга нигезләнгән. Бу легендаларның эзләре Коръәндә дә бар. Коръәнгә алар яһүд һәм христианнарның изге китаплары булган Тәүраттан һәм Инҗилдән килеп кергән.

Ягкуб пәйгамбәрнең унике баласы арасыннан иң сөеклесе, башкалардан илаһи чибәрлеге белән аерылып торганы, әле унбер яшен генә тутырган Йосыф исемлесе беркөн хикмәтле төш күрә. Имештер, кояш, ай һәм йолдызлар аның каршына төшеп баш игәннәр. Уянгач, аңлатып-юрап бирүен үтенеп, Йосыф төшен атасына сөйли. Атасы төшне бик зур дәрәҗәгә ирешү галәмәте дип фаразлый, аны беркемгә дә сөйләмәскә, сер итеп сакларга куша. Әмма Ягкубның үги кызы әлеге сөйләшүне ишетеп кала һәм аны шундук агаларына җиткерә. Тегеләрнең күңелләрендә көнчелек хисе кабына һәм алар Йосыфтан үч алырга карар кылалар. Әтиләреннән Йосыфны үзләре белән сахрага алып чыгарга рөхсәт сорыйлар. Ягкуб, авырсынып кына булса да, рөхсәтен бирә.

Йорттан ераклашуга, аталары күздән югалу белән, агалары Йосыфны төрлечә кыерсыта башлыйлар, хәтта үтермәкче булалар, ахыр чиктә, аягын-кулын бәйләп, ташландык коега ыргыталар. Кич белән өйгә кайткач, әтиләренең: «Кайда минем Йосыфым?» – дигән соравына, алдалап: «Аны бүре ашады, менә билгесе», – дип, энеләренең кәҗә бәтие каныны буялган күлмәген күрсәтәләр. Ата кеше һуштан язып егыла, олы кайгыдан күзләре сукырая.

Берзаман кое янына сәүдә кәрваны килеп туктый. Алар Йосыфны аяусыз үлемнән коткаралар һәм үзләре белән Мисырга алып китәләр. Мисыр халкы, Йосыфны күреп, хәйран кала: «Ул, – диделәр, – адәмнәргә охшамаган, күктән иңгән фәрештәдер». Шәһәр халкы Йосыфны күрергә ашкына. Кәрван башлыгы бу хәлдән файдаланып калырга уйлый: Йосыфны зиннәтле сарайның уртасына куелган урындыкка утыртып, бер динар акча бәясенә халыкка күрсәтә, аннан соң «гүзәл товарын» базарга чыгара.

Беркөнне базарга Мисыр хөкемдары Кыйтфир белән аның хатыны Зөләйха килә. Беренче тапкыр Зөләйха белән укучы шунда очраша. Аның тарихы әсәрдә болайрак сурәтләнә. Ул Мәгърибтәге бер дәүләттә патша булып тору-



Кол Гали. 1965ел.
Мәрмәр.
Авторы: Бакый Урманче.

чы Тәймуснын кызы була. Менә шул кыз бервакыт төшендә Йосыфның сурәтен күрә һәм аңа үлеп гашыйк була. Атасы-анасы чарасызлыктан аптырый. Зөләйха Йосыфны тагын бер тапкыр төшендә күрә һәм сорый: «Әйтче, кем син, торган җирең кайда?» Йосыф телгә килә, үзенең Мисыр хөкемдары булуын әйтә, мине күрергә теләсәң, Мисырга кил, ди. Зөләйха төшен атасына сөйли, үзен Мисырга җибәрүен үтенә. Әтисе, Тәймус, Мисыр патшасы Кыйтфиргә хат яза: «Бер кызым бар, ул тик сине теләр имди, риза булсаң, безгә белдер, үз илчеңне җибәр имди». Тиздән Мисырдан уңай хәбәр килә һәм Тәймус кызын ерак юлга озата.

Татлы хыяллар белән Зөләйха Мисыр иленә килеп җитә, әмма кыз хозурына хыялындагы гүзәл егет урынына олы яшьтәге Кыйтфир килеп баса. Зөләйха һуштан язар хәлгә җитә. Ул язмышына буйсына, әмма үзенең пакьлеген саклый, Кыйтфир янына, Зөләйха кыяфәтенә кереп пәри кызы йөри.

Күп вакытлар үтә. Менә беркөн Йосыфны мәйданга алып чыгалар. Зөләйха да шунда була һәм ул, уйлап та тормыйча, хезмәтчеләренә аны сатып алырга боера.

Алты-җиде елдан Йосыф буй җиткән егеткә әверелә. Зөләйханың аңа карата гыйшык уты тагын да көчлерәк булып яна башлый. Бер туры китереп, ул Йосыфка үзенең гыйшкын ачып сала. Егет исә аның мәхәббәтен кире кага, Кыйтфир патшага хыянәт итү турында уйлап та карамый. Әлеге вакыйга икенче көнне үк бөтен Мисыр халкына мәгълүм була. Имеш, Зөләйха үзенең колына гашыйк булган. Тегесе, имеш, аңа буйсынмаган... Китә гайбәт, усал көлешүләр. Зөләйха мондыйларга сабак бирергә була. Зур мәҗлес әзерләп, табынга аксөякләрнең хатыннарын чакыра. Һәрберсенә пычак һәм әфлисун бирә. «Әфлисунны турагыз!» – дип боера. Нәкъ шул вакыт залга Йосыф килеп керә. Хатын-кызлар егетнең гүзәллеген күреп таң кала.

Шулай алар сихерләнеп карадылар,
Үзләренең бармакларын турадылар,
Турауларын һич кенә дә тоймадылар, –
Һәммәсе дә шулкадәрле хәйран имди.
Зөләйха әйтте: «Инде сез күрдегезме,
Йөзем нидән сулганлыгын белдегезме,
Бер күрүдә кулыгызны кистегезме,
Акылыгызны җуйдыгызмы?» –
дияр имди.

...Зөләйха катгый карарга килә: «Асыл егет әмремә йә буйсынсын, йә яптырам – зинданда ул тоткын була». Йосыф унике ел буена зинданда ятарга мәҗбүр ителә. Биредә ул төшләрне оста юраучы буларак таныла.

Беркөн Мисыр патшасы гаҗәп төш күрә: имеш, җиде симез сыерны җиде арык сыер тотып ашый, тулып җиткән җиде башакны корып беткән җиде буш башак йота. Сарайдагылар төшне юрый алмый. Ахыр чиктә зиндандагы Йосыфка мөрәҗәгать итәләр. Аның юравы болай була: «...Нәкъ җиде ел иген уңа, төрле нигъмәт-азык белән дөнья тула, аннан соңра корылык һәм кытлык була, – нәкъ җиде ел зур авырлык булыр имди». Патша Йосыфны тоткынлыктан азат итә. Йосыф аңа алдан ук илне киләсе ачлыктан саклау чараларын күреп куярга киңәш итә. Егетнең акылына таң калган хөкемдар патшалыкны аңа тапшыра. Йосыф ачлык чорына әзерләнә башлый: күп иген иктерә, еллык уңышның бер өлешен дәүләт амбарларына салдыра.

Яңадан Зөләйхага әйләнеп кайтыйк. Берзаман Йосыф, йөгерек атына атланып, гаскәре белән сахрага чыга һәм... бер читтәрәк күзләре сукырайган, иске-москы киемнәр кигән мескен бер карчыкны күреп, туктап кала. Бу карчык... Зөләйха булып чыга. «Кырык ел буе синең гыйшкыңда янып, шундый көнгә калдым», – ди. Баштарак бу хәлгә Йосыф ышанмый, мәхәббәтеңне расларлык дәлил кирәк, ди. Зөләйха аның камчысын сорап ала. Камчы дөрләп яна башлый.

Зөләйха әйтте: «Күрдеңме, аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга таң калдыңмы?
Кулыңны пешергәнгә түзалмадыңмы? –
Ул ут мине кырык ел көйдерә имди!»

Йосыф Зөләйханың ихласлыгына инана. Алланың рәхмәте белән Зөләйхага яшьлеге кире кайта, күзләре ачыла, тулган айдай йөзе нур булып балкый. Алар, ниһаять, кавышалар.

...Кайчандыр Йосыф үзе юраган ачлык килеп җитә. Ягкуб үз янына улларын чакырып ала: «Ашлык сорап, Мисыр патшасына барырга кирәк, аның бик игелекле һәм юмарт дигән даны бөтен җиһанга таралган, башка чарабыз юк», – дип белдерә. Угыллар Мисырга китәләр. Аларны Йосыф олы хөрмәт белән каршы ала. Ахыр чиктә, Мисырга берничә тапкыр кылган сәяхәттән соң, туганнар кавышалар, Ягкуб карт үзенең сөекле улын күрү бәхетенә ирешә. Гаиләдә шатлык, бәхет тантана итә.

Әсәренең эчтәлеге белән танышканнан соң, «Кем соң ул Кол Гали?» дигән сорауга яңадан әйләнеп кайтыйк әле. Күренеп тора, ул искиткеч талант иясе генә түгел, бәлки күп телләр белеп (аның Йосыфы гына да бит 72 телдә сөйләшә), үзенә кадәр яшәгән Шәрык әдипләренең бөтен иҗатын, бигрәк тә фарсы шагыйре Фирдәүсинең атаклы «Йосыф вә Зөләйха» исемле зур поэмасын җентекләп өйрәнгән олы галим дә.

Кол Гали иҗат иткән поэманың нигезендә төш күрү вакыйгасыннан башланып киткән фаҗигале язмыш – ата һәм угыл мәхәббәте. Бу инде егет белән кызның мәхәббәт тарихы гына түгел Эчтәлек күпкә тирәнрәк, киңрәк, баерак. Әсәрнең үзәгендә хөкемдар һәм гади халык бәхете проблемасы. Хөкемдар нинди булырга тиеш? Шагыйрь шул сорауга җавап эзли һәм таба. Ул аны әсәрнең төп каһарманы булган Йосыфның кешелек сыйфатлары аша күрсәтә. Йосыф тугрылык, гаделлек, зирәклек, юмартлык, кыюлык һәм батырлык, олы җанлылык, тыйнаклык кебек гүзәл сыйфатларга ия. Шуңа күрә дә халык аны ярата, үз итә, якын күрә. Сезгә ничектер, миңа шулай тоела: Кол Гали үзе дә шул сыйфатларга ия булгандыр. Гаделлеккә һәм тугрылыкка, зирәклеккә һәм батырлыкка дан җырлаган шагыйрьне мин башкача күз алдына китерә алмыйм.

ТАТАРСТАННЫҢ ҮЛЕМСЕЗ ПОЛКЫ: МӘҢГЕ ХӘТЕРДӘ!

Җиңү көнендә илебездә һәм аннан читтә дә «Үлемсез полк» бөтенхалык акциясе узды – меңнәрчә россиялеләр, башка ил гражданнары илебезне саклап калучылар һәм фашизмны җиңүчеләрнең – аталарының, бабаларының, бабаларының аталарының портретлары белән мәйданнарга чыкты. Бу бик күркәм акция, ул мантыйкый дәвам ителергә лаек, дип карар иттеләр «Татарстан» журналы хезмәткәрләре. Һәм укучыларына шундый тәкъдим белән чыкты: әйдәгез, бергәләп «Татарстанның үлемсез полкы» дигән махсус чыгарылышны әзерлик, һәм теләгән һәркем анда шул коточкыч сугышта катнашкан туганнарының, танышларының, предприятие ветераннарының бәһасез фотографияләрен – дәрәҗәләренә һәм бүләкләренә бәйсез рәвештә – урнаштыра алсын! Ә фотографияләрне – геройлар турында кыскача мәгълүматлар белән баетырга! Без ышанабыз – бу безнең сезнең белән бергә сугышта катнашучылар турындагы истәлекләрне мәңгеләштерүгә керткән тыйнак өлешебез булыр, ә «Үлемсез полк» җыентыгын предприятиеләрдә һәм гаиләләрдә мәңге сакларлар.

Үзләренең каһарман бабалары турында сөйләп, «Татарстан» журналының махсус проектында катнашырга теләүчеләр өчен – телефоныбыз:

(843) 222-09-76

«Татарстанның үлемсез полкы» махсус чыгарылышының беренче сәхифәләре – журналның әлеге санында ук!

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Рем Афзал улы Афзалов



1914 елның 24 июнендә Апас районының Урта Балтай авылында туган.

Казан университетының рабфагында укый, авиация заводында эшли. 30 нчы еллар ахырында Кызыл Армия сафларына чакырыла, совет-фин сугышында катнаша. Сугыштан соң Казан авиация заводында профком рәисе булып эшли. Бөек Ватан сугышы фронтларында – 1942 елдан. 3 нче Украина фронты гаскәрләре сафында Украинаны, Молдавияне, Венгрияне, Румынияне, Югославияне азат итүдә катнаша. 1 декабрьдә гвардия өлкән лейтенанты Афзалов ротасы Дунапатай авылы районында Днепрны кичеп чыга. Плацдармны кулга төшергәндә рота дошманның 100 гә якын солдатын һәм офицерын юк итә һәм 145ен әсирлеккә төшерә. СССР Югары Советының 1945 елның 24 мартындагы указы белән немец-фашист басып алучылары белән сугыш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгән һәм шул вакытта күрсәткән кыюлыгы һәм батырлыгы өчен гвардия өлкән лейтенанты Афзалов Рем Афзаловичка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Җиңү көнен укчы батальоны командиры дәрәҗәсендә каршылый. Ленин ордены, ике Алтын Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнгән. 1983 елның 7 февралендә вафат була, Ташкентта Геройлар аллеясендә күмелә.

Материалны улы Афзалов Руслан Ремович тәкъдим итте. Казан.



ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Виктор Михайлович Антонов

1919 елның 23 февралендә туган. Ленинград фронтында сугыша. 1942 елның 26 август санында «Ленинградская правда» тугыз кызылармиячевең батырлыгы турында яза, алар арасында комсомолец Виктор Антонов та була. Кинәт һөҗүм итеп, безнең сугышчылар немецларны үз позицияләреннән кубарып чыгаралар, аннары берничә көн дәвамында, яулап алган җир кисәген бирмичә, дошманның чагыштырмача зуррак көчкә ия булган һөҗүмнәрен кире кайтарып торалар. Тугыз сугышчы да һәлак була, ләкин чигенми, дип хәбәр итә газета. Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Шиланка авылына да кара кәгазь китә. Виктор Антоновның хатынына иренең батырларча үлеме турында хәбәр итәләр. Ә берничә айдан авылга герой үзе кайтып килә – култык таякларында, әмма исән! Күкрәгендә Сугышчан Кызыл Байрак һәм Дан орденнары. Антонов тугыз сугышчы арасында исән калган бердәнбер кеше була. Авыр яралы, аңсыз килеш, аны сугыш кырыннан табып алганнар һәм Ленинград госпиталенә илткәннәр икән, ә хирурглар аны теге дөньядан кире кайтарганнар, дисәң дә була...

Тыныч заманда ветеран шактый вакыт Степан Разин исемендәге колхозга җитәкчелек итә, Черняховский исемендәге колхозның партоешма секретаре була, район сельхозтехникасында эшли. 1987 елның 6 маенда вафат була.



Виктор Михайлович беренче рәттә сулда

Материалны Борис Викторович Антонов тәкъдим итте

БЕССМЕРТНЫЙ ПОДВИГ ДЕВЯТИ ГЕРОЕВ

ЛЕНИНГРАДСКИЙ ФРОНТ. (Спец. корр. ТАСС). Подразделение старшего лейтенанта товарища Гродецкого атаковало противника, засевшего на железнодорожной насыпи. Атака была стремительной. Подняв винтовки над головой, бойцы преодолели водный рубеж и, пробежав несколько десятков метров, ворвались на железнодорожное полотно.

Немцы, вынужденные отступить, пытались было задержаться в траншеях и у расположенной неподалеку высотки. Но бойцы тов. Гродецкого преследовали их, выбили из траншеи, завладели высоткой, и продолжали теснить врага.

Девять бойцов остались на высотке и заняли круговую оборону. Вскоре гитлеровцы двинулись в атаку. Одну за другой бросали они на высотку мелкие группы солдат. Отважные бойцы расстреливали немцев в упор. Младший лейтенант тов. Лаврентьев убил более двух десятков гитлеровцев. Пулеметчик комсомолец тов. Чусовитин косил врага меткими очередями.

Рубеж оказался неприступным. Тогда гитлеровцы подтянули сюда около роты солдат и стали обстреливать высотку с фланга.

Над девятью смельчаками нависла грозная опасность, но эти твердо решили держаться до последнего.

Прошли первые сутки боя. Утром немцы снова предприняли атаку. Из рубежа девяти бойцов двинулось около сотни гитлеровских головорезов.

— Ни шагу назад! — крикнул комсомолец тов. Антонов.

Старший сержант тов. Тиходеп, несмотря на ранение, вел огонь по врагу и уложил из автомата около 30 немцев. Снайпер тов. Джакия убил немецкого офицера.

Противник обрушил на бесстрашных бойцов шквальный артиллерийский огонь, но они продолжали отстреливаться последними патронами. От вражеских снарядов и пуль уже невозможно было никуда скрыться, им уйти. Девять героев пали смертью храбрых, но не отдали врагу отвоеванной земли.

С волнением наблюдали за неравной схваткой артиллеристы старшего лейтенанта тов. Сурина. Когда гитлеровцы попытались ворваться на высотку, артиллеристы обрушили на их головы десятки снарядов. Ни один немецкий солдат не ушел живым. Так был открыт счет мести за смерть героев.

Ленинградцы никогда не забудут подвига девяти воинов-патриотов, стойко выдержавших бешеный натиск врага и не отошедших со своего рубежа. Вечная слава героям — Ефиму Лаврентьеву, Виктору Антонову, Егору Злобину, Хабибулле Зулмарпову, Михаилу Трифонову, Константину Чусовитину, Василию Тиходепу, Николаю Джакия и Зиннату Гиниятуллину.

А. БЕЙЛИН.

Из газеты «Ленинградская правда» за 26 августа 1942 года.

x x x

Среди 9 героев, проявивших мужество и отвагу в боях за небольшую высоту в самые трудные для Ленинграда дни, был и Виктор Антонов — из села Шиланка. Это он воскликнул: «Ни шагу назад!», воодушевляя своих боевых товарищей на борьбу.

Всем смертям назло наш земляк Виктор Антонов остался жив, остальные погибли в кровопролитных боях за эту высоту. Оставив последний патрон для себя, он вместе со своим боевым другом Е. Лаврентьевым под сильным артиллерийским огнем начал ползти к проходу. Вскоре рядом с ними разорвался снаряд. Навсегда остался лежать на поле сражения и его последний боевой друг. А сам он был тяжело контужен. В. Антонов не помнит, сколько времени пролежал он в таком состоянии.

(Окончание на 4-й стр.).

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Госман Мөбәрәкша улы Җиһаншин

1926 елның 14 ноябрендә ТАССРның Кызыл Армия (хәзерге Чистай) районының Каргалы авылында туган. Армиягә чакырылу турында повестканы 17 яше туларга өч көн кала, 1943 елның 11 ноябрендә ала. Ерак Көнчыгышта империячел Япониягә каршы сугыша. Аркасына 32 килограммлы сугыш припаслары аскан килеш Зур Хинган сырты аша өч көн буе үтүне, тау елгаларын кичеп чыгуны еш исенә төшереп сөйли. Елгаларның көчле агымы бик күп полкташларының гомерен өзгән – агым аларны агызып алып киткән…

Сугышчан хәрәкәтләрдә катнашканы өчен, Госман Җиһаншин Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Туган авылына демобилизациядән соң – 1950 елның 1 маенда гына кайта. Педагогия институтын тәмамлый, укытучы, партиянең Чистай райкомы инструкторы булып эшли.

Материалны улы Булат Җиһаншин тәкъдим итте. Казан.

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Муллаҗан Мөбәракша улы Җиһаншин

1910 елның 10 февралендә Татарстан АССРның Чистай районы Каргалы авылында туган. Фин сугышында (1939 ел) катнашкан, демобилизацияләнеп, туган авылына кайткан. 1941 елда доброволец булып фашистларга каршы сугышка киткән. Төньяк-Көнбатыш фронтында сугышкан, Старая Русса янындагы канкойгыч бәрелешләрдә катнашкан. Германияне җиңгәннән соң, Ерак Көнчыгышка – Япония белән сугышка җибәрелгән.

II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Сугышчан казанышлар өчен», «Японияне җиңгән өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән. Сугыштан кайткач, суд приставы булып эшләгән. 1989 елның 3 маенда вафат булган.

Материалны оныгының улы Әмир Нәбиуллин тәкъдим итте. Казан.

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Евгения Макаровна Чаплинская

1913 елда Киевта туган, шунда ук фельдшер-акушерлык училищесын тәмамлаган. Евгения Чаплинская өчен сугыш 1941 елның 22 июненнән күпкә иртәрәк башлана. 1939 елда Көнбатыш Украинаны һәм Көнбатыш Белоруссияне СССРга кушкан чакта, Евгения һәм аның шулай ук табиб ире хезмәт иткән поезд-госпиталь шартлатыла. Ире һәлак була, Евгения нindидер могҗиза белән исән кала… Фашистлар белән сугыш башланганда, Чаплинская – инде хәрәкәттәге армиядә, укчы дивизиясендә. 1942 елда ул Яңа Чишмәгә җибәрелә. Шактый озак вакыт биредә бердәнбер дипломлы белгеч булып тора, юлсызлык аша, теләсә нинди һава торышында, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында тирә-як авыллардагы авырулар янына ашыга.

Материал Яңа Чишмә үзәк хастаханәсе тарафыннан тәкъдим ителде

Николай Константинович Маланчев



1918 елның 19 декабрендә туган. Рядовой сугышчы булып укчылар дивизиясендә сугыша. Сугышны тулысынча кичә, яралана. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнгән. Сугыштан соң Яңа Чишмәгә әйләнеп кайта, колхозда эшли. Гаиләдә җиде бала үстерәләр. 2004 елда вафат була.

Материалны Любовь Маланчева тәкъдим итте. Яңа Чишмә

Михаил Леонтьевич Сыров

1911 елның 30 октябрендә туган. Сугышның беренче елында ук фронтка китә. Чигенә, аннары оккупацияләнгән территорияләрне фашистлардан азат итүдә катнаша. Өлкән сержант, 616 нчы аерым сапёр батальонының взвод командиры Михаил Сыров Берлинга кадәр барып җитә. Балаларына һәм онықларына сугыш турында сөйләгәндә, еш кына шундый сүзләрне кабатлый: «Ничек кенә авыр булмасын, сапёр бер кагыйдәне һәрвакыт исендә тотарга тиеш: сапёр һәрвакыт ышанычлы эшли, сапёрга ялгышырга ярамый». III дәрәҗә Дан ордены кавалеры Михаил Сыров һәр эшен шулай намуслы, ышанычлы итеп башкара... Ул фани дөньядан 1990 елда китте.

Материалны оныгы Любовь Маланчева тәкъдим итте.
Яңа Чишмә

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Виктор Иванович Архипов

1944 елның көзендә, Рига операциясе башланган чакта, Виктор Архиповка унтугыз яшь тулып кына киткән була әле, ә артында инде – сугышның бер генә елы түгел. Сугышчан батырлыклары, дошманның контратакаларын кайтаруда күрсәткән ныклыгы өчен «Сугышчан казанышлары өчен» медале белән бүләкләнгән ул. 1944 елның җәендә Витебск нығытылган районының чылбырын өзгән өчен – «Батырлык өчен» медале белән.

...Тоташ бомба чокырларыннан торган үле җир. Дошман авиациясенең чираттагы һөҗүменнән соң безнең оборона линиясе әнә шундый халәттә була. Ә инде гитлерчылар атака ясарга керешкәч, җир, әйтерсең, җанланып китә. Җимерелгән траншеялардан, туфрак белән күмелгән пулемёт ояларыннан исән калучылар дошманнарга ата башлый. Дивизионның хәрби порядоклары үзәгендә – өлкән сержант Архиповның 76 мм лы орудиесе. Орудиесенең төзәгече сафтан чыккан, шуңа күрә утны чама белән юнәлтергә туры килә аңа. Уңышлы очыртылган снарядлар дошманның ут позицияләренә җитеп, аларны юкка чыгара. Виктор берничә ату белән ике ут ноктасын сафтан чыгаруга һәм өч дистәләп фашистны юк итүгә ирешә. Рига янындагы сугышлар өчен өлкән сержант Архипов III дәрәҗә Дан орденына лаек була.

Алда – Көнчыгыш Пруссия башкаласы Кёнигсберг. Кёнигсберг «нығытма шәһәр» дип йөртелә. Фронт командованиесе приказы белән мәгърур нығытманы алу өчен штурм төркемнәре оештырыла. Кёнигсбергны штурмлаганы, ике ут ноктасын һәм ике артиллерия орудиесен сафтан чыгарганы, һәм шулай ук 70тән артык гитлерчыны юк иткәне өчен гвардия өлкән сержанты Виктор Иванович Архиповны II дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләргә, дип язылган була боерыкта. Җиңүгә нибары 8 көн вакыт калган була инде.

Материал «Дәүләт гамәли оптика институты Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Александр Тихонович Биткин

Армиягә 1942 елның августында Татарстан АССРның Акташ районвоенкоматы тарафыннан 18 яше тулганчы чакырыла. Башка яңа чакырылыш егетләре белән бергә Александр Биткинны да Тормыш Юлы буенча блокададагы Ленинградка озаталар. Балтикада матрос-артиллерист булып хезмәт итә егет. 1943 елның гыйнвар аенда Ленинград блокадасын өзү өчен оештырылган «Искра» операциясендә, 1944 елның гыйнварында Ленинград янында немецларны тар-мар итү операциясендә катнаша.

«1943 елның12 гыйнвары аеруча суык иде, – дип искә ала Александр Тихонович. – 8 сәгать 45 минутта «Фашист ныгытмаларына каршы… огонь!» – дип команда бирелде. Артиллерия 2 сәгать 20 минут дәвамында дошман оборонасын ватты һәм җимерде. Сәгать 11 дә гвардия миномётларының залплары яңгырады. Нева аша штурмга пехота килеп керде. 7 тәүлек буе канкойгыч сугыш барды. 18 гыйнварда «Искра» операциясе тәгәлләнде.

Бер елдан соң, 1944 елның 14 гыйнварында, морякларны зур сборга җыялар һәм ПУ Балт мөрәҗәгатен укыйлар: «Балтиец, син Невский асфальтында Ленинград балаларының канын күрдең, син хастаханәләр һәм балалар ясленләре, мәктәп һәм музей диварларында фашист снарядлары җимергән бинаһая тишекләрне күрдең! Боларның барысы өчен фашист хәшәрәтләреннән үч алыр вакыт җитте!» Александр Биткин хезмәт иткән дивизион 85 ммлы зенит орудиеләре артиллерия группасына керә, Ленинград порты пирсларыннан дошман балкаларына ут яудыра. Операция барышында дошман Нарвага чигенергә мәҗбүр була.

1944 елның 27 гыйнвар кичендә 324 орудиедән атылган 24 артиллерия салюты залпы бөтен дөньяга 900 көнлек блокаданың өзелүе, Ленинградның җиңүе турында хәбәр итә.

Матрос Биткинны алда әле Нарва һәм Таллин, Моонзунд, Лимель һәм Швитой, Кёнигсберг һәм Либава көтә.

Материал «Дәүләт гамәли оптика институты Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

Марс Әшрәф улы Вәлидов



«Сугыш минем өчен (ул чакта мин унбиш яшьлек үсмер идем) 1942 елның июнь ахырында Хәрби-Диңгез флотының Юнгалар мәктәбенә кабул ителгән көнемнән башланды. Архангельскида безне киендерделәр, командаларга бүлгәләделәр һәм төнлә транспорт белән Соловецк утрауларына илтеп куйдылар. Анда без үзебезгә торак, уку бүлмәләре, ашханәләр төзергә һәм утрауны, андагы объектларны дошман десантыннан сакларга тиеш идек.

1943 елның июлендә, Юнгалар мәктәбен тәмамлагач, мине Кара диңгез флоты торпеда катерларының беренче бригадасына моторчы итеп җибәрделәр. Бригада составында Кара диңгез флотының төп базасы – Поти шәһәрен хәрби саклауда катнаштым. 1944 елның язында мине Кара диңгез флоты торпеда катерларының икенче Новороссийск бригадасына күчерделәр, аның составында Румыния һәм Болгарияне азат итүдә катнаштым. Сугышны Болгариядә, Бургаста тәмамладым.

1943 һәм 1944 еллар хәтеремдә теләсә нинди һава торышында һәм тәүлекнең теләсә кайсы вакытындагы тоташ диңгез походлары буларак уелып калды, алар еш кына бомбалар һәм артиллерия атышлары астында үтә иде, аларда без сугышчан дусларыбызны да югалта бардык. Үлем – сугыш вакытында гадәти хәл. Ә инде сугыштан соң, өйгә кайткач, үзем белән бергә фронтка киткән ике йөз егеттән нибары ике дистәдән азрагы гына әйләнеп кайтуын белеп алдым. Әнә шулчак күз алдымда сугышның коточкыч фаҗигале картинасы ачылды.

Флотта хезмәт итү чорыннан Ялтаны, Севастопольне, Одессаны, Констанцаны, Варнаны һәм Бургасны азат иткәндәге сугыш хәрәкәтләребез аеруча ачык истә калды.

Сугышчан һәм хезмәттәге казанышларым өчен тугыз медаль һәм өч орден белән бүләкләндем».

Материал «Дәүләт гамәли оптика институты Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

Юрий Иванович Молодцов

«Мин, ефрейтор-автоматчы, 271 нче гвардия укчы полкының 1 нче укчы батальоны ротасында хезмәт иттем. Висла елгасындагы Мангуш плацдармында 1944 елның 19 августында иртәнге сәгать 5 тә һөҗүмне башларга, дошманны траншеяларыннан чыгарып, Геленув һәм Геленувск авылларын алырга, шоссе юлын кулга төшерергә һәм оборонага басарга боерык алынды. «Ура!» кычкырып, без траншеяларга ташландык һәм дошманны тар-мар иттек. Геленув авылы юлында нарат урманы бар иде, аннан безгә пулялар яңгыры ява башлады. Алга бару мөмкин түгел иде. Әрәмәлеккә сул яктан үтеп кергәч, атышның югарыдан алып барылуын аңладык. Пулемётчы нарат агачы башыннан ата иде. Пулемётчыга автоматтан 2–3 кыска очередь җибәрдек. Пулемёт килеп төште, ә пулемётчы һаман да нарат башында калды. Ул, безнең гаскәрләрне туктатып торыр өчен, анда бәйләп калдырылган булып чыкты. Авылга килеп кергәч, иң кырый йортта немецларның тәрәзәдә танк пулемёты урнаштыруларын күреп алдык. Ишекне ачып, һәркайсыбыз берәр граната ташладык. Расчёт юкка чыгарылды. Авылда башка немецлар юк иде. Безнең рота Геленувск авылы каршында оборонага урнашты. Биредә, оборонада, без 1945 елның гыйнвар аена кадәр тордык. 1944 елның 21 сентябрендәге сугышлар өчен мин «Батырлык өчен» медале белән бүләкләндем.

Польшаны азат итү өчен барган сугышларда байтак дусларымның үз гомерләрен корбан иткән көнне беркайчан да онытмам. Сугыш турында искә алырга мөмкин һәм кирәк, иң мөһиме, боларның берсе дә кабатланмасын иде».

Материал «Дәүләт гамәли оптика институты Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Камил Сабир улы Мостафин

«1942 елның сентябрь аенда Харьков пехота училищесына килеп җиттем. 5 айлык укулардан соң, безне укчы дивизиянең отделение командирлары итеп фронтка озаттылар. Курск дугасы янындагы Дала фронты Баш командованиесенең резервы составында еш кына сугышларга кердек. «Фердинанд» үзйөрешле орудие снаряды ярчыгыннан яраландым. Автоматымны ярчык урталай ярды. Медсанбатка үзем барып җиттем. Дәваланганнан соң башка частька эләктем…

Украинадагы Речуш елгасы исемдә, каршыдагы текә ярда фашистлар урнашкан. Без уч төбендәгедәй күренеп торабыз. Елганы аркылы чыгарга кирәк иде. Немецлар безгә ут яудырып тора. Батальоннан аз гына кеше исән калды: өлкән лейтенант, ике кече лейтенант, старшина һәм 16 солдат. Без, каршы ярга чыгып, позиция алдык. Яшерендек. Чигенергә ярамый! Обозларыбыз артта калды. Караңгыда җимерелгән немец танкына барып чыктык. Старшина белән солдатлар аның янына шуышып, берничә әрҗә патрон һәм пулемёт та китерделәр. Караңгыда безгә таба ябырылган кешеләрнең саны 500 дән ким түгел кебек иде. Без аларны пулемёт уты белән каршыладык. Немецлар чигенделәр, ләкин 2–3 сәгатьтән һөҗүм тагын кабатланды. Алар безгә төннәрен бишәр тапкыр һөҗүм итте. Шул рәвешле өч тәүлекне үткәрдек. Бәхеткә, югалтуларсыз. Бу операция өчен мине Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

41 нче Гвардия мотоукчы дивизиясе составында бөтен Украинаны үттем. Сугышны, фашистларның калган төркемнәрен юкка чыгаруда катнашып, Румыниядә төгәлләдем».

Материал «Дәүләт гамәли оптика институты Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Александр Рубенович Шахназаров

Фото: «Выбор» газетасы



1927 елның 19 ноябрендә Әстерхан өлкәсенең Чаган авылында туган. 1942 елның җәендә Александр Шахназаров – елга техникумы студенты – «Волховстрой» буксирына кочегар итеп практика үтәргә җибәрелә. Сталинград сугышы башлангач, буксир Идел хәрби флотилиясе составына кертелә. Дошман уты астында буксир Саратовтан һәм Камышиннан Сталинградка солдатлар, техника, сугыш кирәк-яраклары ташый. Иң авыр вакыт – Сарепта районы кичүендә эшләү була, анда «Волховстрой» һәм тагын тугыз судно тоташ бомбалар яңгыры астында сталинградчылар белән сул як ярны бәйләнештә тота. Ун көн эчендә ун судноның бары икесе – «Сократ» белән «Волховстрой» гына исән кала, ләкин ул да, бомба төшкәннән соң, ремонтка озатыла… Елга техникумыннан Сталинград сугышы учагына эләккән 144 студент-практикантның 26сы гына исән чыга.

1945 елның апрелендә Александр Шахназаров үз ирке белән Кызыл армиягә китә һәм артиллерия училищесына җибәрелә, аны 1947 елда тәмамлый. Артиллерия полкы командиры була, аннан 25 ел Казан Суворов училищесында укыта. Запаска чыгарылганнан соң, Александр Рубенович КАИда физик тәрбия кафедрасында өлкән укытучы булып эшли.

II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән.

Материал КМТТУ-КАИ тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Иван Васильевич Данилов

1898 елның 11 ноябрендә Казан губернасының Чебоксар өязе Аттиково авылында туган. Бөек Ватан сугышы алдыннан медицина фәннәре кандидаты Иван Данилов Казан дәүләт медицина институтының акушерлык-гинекология клиникасында ординатор булып эшли. Сугышның беренче көннәрендә Казан шәһәрендәге 1667 нче эвакуация госпиталенең хирургия бүлегенә башлык итеп билгеләнә. 1941 елның августыннан хәрәкәттәге армиягә чакырыла. Фронт юлын беренче линия 519 нчы күчмә кыр хирургиясе госпитале башлыгы вазыйфасында башлый. 1943 елдан Ленинград һәм Волхов фронтларының 8 нче армиясендә армия гинекологы була. Биш озын сугыш елы – бу фронт хирургыннан көн саен үз-үзен тулысынча багышлауны һәм батырлыкны таләп иткән хезмәт. Сугыш аның өчен 1945 елның декабрендә тәмамлана. Сугыштан соңгы елларда медицина фәннәре докторы Иван Данилов ун ел буе Казан дәүләт табибларның белемен күтәрү институтына җитәкчелек итә (1952–1962 еллар), 2 нче номерлы акушерлык һәм гинекология кафедрасы мөдире була (1956–1971 еллар).

I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Сугышчан казанышлар өчен», «Ленинград оборонасы өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

1972 елның 2 февралендә вафат була.

Материал КДМА тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

София Яковлевна Порсева

1923 елның 28 июлендә Сарапулда туган. 1941 елның 26 июнендә, урта мәктәпне гел бишкә генә тәмамлап, үзе теләп, фронтка китә. 1941 елның августыннан ноябренә кадәр Алабугада радистлар курсында укый. Аннан соң 30 нчы укчы дивизиягә җибәрелә. Бервакыт, бу Орловщинада була, дивизия алдына безнең оборона линиясе каршында торган дошманның санын һәм техник тәэмин ителешен ачыклау бурычы куела. Шушы максатта разведка ротасыннан дошман тылына 18 сугышчыны һәм ике радистны җибәрәләр. Радистларның берсе София була. Орлов сазлыклары баткак һәм узу өчен авыр. Сугышчы Порсеваның иңнәрендә радиостанция, кулларында ике ВАС-80 тукландыру батареясы, әмма ул үз бурычын үти. Ике елдан артык ул Орлов һәм Белоруссия сазлыкларын ерып йөри, атышлар вакытында Курск дугасы җирләренә сыенып ята, Көнчыгыш Пруссиягә кадәр барып җитә. Кёнигсберг ныгытмасы өчен барган сугышлар аның фронт биографиясендә соңгысы була. Кёнигсберг янында София контузия ала.

Сугыштан соң София Яковлевна медицина институтын, аспирантураны тәмамлый. 30 елга якын медицина академиясендә (элекке ГИДУВ) педиатрия кафедрасында ассистент булып эшли.

II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Сугышчан казанышлар өчен», «Батырлык өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Материал КДМА тарафыннан тәкъдим ителде

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Леопольд Матвеевич Рахлин

Бөек Ватан сугышы башланганда Леопольд Рахлин – медицина фәннәре докторы, профессор, Казан ГИДУВының терапия кафедрасы мөдире. Чакырылышка эләкми, әмма шунда ук фронтка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка китә. Хәрәкәттәге армиягә 1942 елда җибәрелә –челюскинчыларны коткару экспедициясендә катнашкан Рахлин-табибның уникаль тәҗрибәсе игътибарга алына. «Мине, элекке полярник буларак, Карелия фронтының 14 нче һәм 19 нчы армияләренә баш терапевт итеп билгеләделәр», – дип искә ала Леопольд Матвеевич. Җиңүне Норвегиядә каршылый. 1946 елда демобилизацияләнә һәм ГИДУВка әйләнеп кайта. 1946 елдан 1953 елга кадәр – институтның фәнни бүлегендә директор урынбасары.

I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт Билгесе» орденнары, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Совет Поляр аръягы оборонасы өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән. 1994 елның 2 июнендә Казанда вафат була.

Материал КДМА тарафыннан тәкъдим ителде

Карелия фронты. 1943 ел.


Карелия фронты. 1944 ел. Казан коллегалары белән.

КМҖБ: Җиңү тарихы

Бөтен Сугыш еллары дәвамында 16 нчы завод Пе-2 һәм Як-3 самолётларына урнаштырыласы ВК-105 моторларын җитештерә. Һәр илле минут саен яңа җыелган двигатель конвейердан төшеп тора.

Моторлар төзү заводында Макар Михайлович Лукин исеменнән дә танылганрак исем юктыр. Авыр сугыш вакытында, 1942 елдан 1946 елга кадәр, ул 16 нчы заводка җитәкчелек иткән. Легендар директор җитештерүнең үсешен дүрт тапкыр арттыруга ирешкән.

1945 елның 16 сентябрендә Лукин Социалистик Хезмәт Герое исеменә һәм шулай ук инженерлык авиациясе хезмәтенең генерал-майоры хәрби дәрәҗәсенә лаек була. Лукин биш Ленин ордены белән бүләкләнгән. Казанның авиатөзелеш районындагы бер урам аның исемен йөртә. Предприятие территориясендә Макар Лукинга горельеф куелган.

Материалны КМҖБ тәкъдим итте



Фото: Александр Ефремов

Николай Семёнович Немыкин



1922 елда Курск өлкәсенең Домановка авылында туган. Бөек Ватан сугышының беренчче аенда ук Кызыл Армиягә чакырыла. 1941 елның 23 июленнән фронтта. Бөтен сугышны үтә. Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен», «Сугышчан казанышлар өчен» (ике тапкыр), «Кёнигсбергны алган өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Василий Михайлович Кутасин



1926 елда Рязань өлкәсенең Ижевское авылында туган. 1941 елдан 1943 елга кадәр – Казанда авиация заводында токарь. 1944 елда Кызыл Армиягә чакырыла, һава укчысы булып хезмәт итә. 1951 елда сержант дәрәҗәсендә демобилизацияләнә.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Бронислав Казимирович Буханевич

1914 елның 1 ноябрендә Украинада, Житомир өлкәсенең Пилипо-Кошары авылында туа. 1938 елда Харьков пехота училищесын тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башлангында – Одесса пехота училищесы курсантларының взвод командиры. 1941 елда Көньяк-Көнбатыш фронты сугышларында катнаша, аннары тылга, Уральск шәһәренә, хәрәкәттәге армия өчен офицерлар әзерләргә җибәрелә. 1944 елның гыйнварыннан – тагын хәрәкәттәге армиядә. Войско Польское 3 нче укчы дивизиясенең 8 нче укчы полкы укчы батальонына командалык итә. 1945 елның февраленнән 1947 елның маена кадәр – Войско Польскоеның Беренче армиясе офицерлары составын кабат әзерләү буенча укыту эшендә.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Зәйди Зәйнулла улы Вәлиев

1918 елда Татарстан АССРның Ютазы районы Каразирек авылында туа. 1940 елның май аеннан 1941 елның июненә кадәр артиллерия полкына караган хәрби-топография мәктәбендә укый. Бөек Ватан сугышы башланганнан соң 527 нче артиллерия полкына топовзвод командиры вазыйфасына билгеләнә. Бөтен сугышны үтә, Мәскәүне саклауда катнаша, шулай ук Көньяк, Үзәк һәм Беренче Украина фронтларында сугыша. Топовзвод, полк идарәсе взводы белән командалык итә, дивизионның һәм полкның разведка башлыгы, артиллерия полкы һәм артиллерия бригадасында топография хезмәте башлыгы була. Александр Невский, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Мәскәү оборонасы өчен», «Берлинны алган өчен», «Праганы азат иткән өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Августина Емельяновна Склярова

1924 елда Чувашиядә, Мариинский Посадта туган. 1941 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Чебоксар хәрби элемтә училищесын тәмамлаганнан соң, Ленинград фронтына җибәрелә, телеграфист булып хезмәт итә. 1945 елда демобилизацияләнә. «Ленинград оборонасы өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Михаил Кириллович Борисов

1927 елда Татарстан АССРның Ширәмәт районы Байданкино авылында туган. 1943 елда җиде классны тәмамлап, колхозда бригадир булып эшли. 1944 елның декабрендә Кызыл Армиягә, авиациягә чакырыла. 1951 елның маенда кече инженер-лейтенант дәрәҗәсендә демобилизацияләнә. «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Наталья Ефимовна Павлычева

1923 елда Татарстан АССРның Яшел Үзән районы Чулпаниха авылында туган. Бөек Ватан сугышында 1942 елның ноябреннән 1945 елның маена кадәр 379 нчы аерым зенит артиллерия дивизионы ПВОсының 7 нче корпусы составында катнаша. 1945 елның декабрендә мобилизацияләнә.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Николай Павлович Фадеичев



1913 елда Брянскида туган. Кызыл Армиягә сугыш башланганның өченче көнендә чакырыла. Мәскәүне саклауда катнаша. Хәрәкәттәге армиядә – Бөек Ватан сугышы тәмамланганчыга кадәр. Взвод командиры, рота командиры урынбасары, сапёр ротасы командиры була. Польшаны, Германияне азат итүдә катнаша. Җиңүне 44 нче гвардия укчы дивизиясенең хәрби-техник тәэминаты башлыгы вазыйфасында каршылый. 1945 елның ноябрендә демобилизацияләнә. Гвардия майоры, Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Мәскәү оборонасы өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Яков Григорьевич Скляров



1918 елда Украинада, Первозвановка авылында туган. Кызыл Армиягә 1938 елда чакырыла. Сугышны 2 нче Ленинград укчы-пулемёт училищесы курсанты буларак каршылый. Ленинград фронтында – Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк. Җиңү көненә кадәр сугыша. Рота командиры урынбасары була. 1942 елның апреленнән – рота командиры. 1943 елда яралана, ике ай ярым госпитальдә үткәрә, аннары – яңадан фронт. Ике Кызыл Йолдыз ордены, «Сугышчан казанышлар өчен», «Ленинград оборонасы өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Материалны «Казан Гипронииавиапром» АҖ тәкъдим итте

Виктор Николаевич Алексеев

1921 елның 10 сентябрендә туган. 1941 елда Пенза артиллерия училищесын тәмамлаганнан соң, Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Сугыш башлану хәбәрен билгеләнгән урынына барган чакта поездда ишетә. Ерак Көнчыгыш фронтының 101 нче укчы дивизиясенең 169 нчы танкларга каршы аерым истребительләр дивизионында хезмәт итә. Японияга каршы сугышта катнаша. 1945 елның августында алдынгы десант составында, төп көчләр өчен һөҗүм итү плацдармын тәэмин итеп, Шумшу утравына (Курил утрауларының берсе) төшеп утыра. Ике Кызыл Йолдыз ордены, Кызыл Байрак һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Сугыштан соң 40 ел Казан электротехника заводында эшли. 2017 елның 9 гыйнварында вафат була.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

Тәлгать Абдулвәли улы Райманов

1923 елның 26 декабрендә Башкортостанда, Яңа Колчура авылында туган. Фронтка комсомол путёвкасы белән китә. Мәскәү оборонасында, Сталинград сугышында катнаша. 1943 елда, кыска сроклы курсларны тәмамлагач, кече лейтенант дәрәҗәсенә ия була, автоматчылар взводына җитәкчелек итә. Тәлгать Райманов өч тапкыр авыр яралана, дүртенче тапкырында – Молдавиядә, күкрәгенә пуля ярчыгы эләгә. 1945 елда, берничә ай буе госпитальләрдә дәваланганнан соң, Югары офицерлар мәктәбенә җибәрелә. 1959 елда демобилизацияләнә.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

Василий Иванович Смирнов

1944 елдан Бөек Ватан сугышында катнаша. Һава оборонасы гаскәрләрендә хезмәт итә, илебез башкаласын дошман авиациясе һөҗүмнәреннән саклый. 1945 елның 24 июнендә Василий Смирнов Мәскәүдәге Кызыл мәйданда үткән Җиңү Парадында катнаша. Сугыштан соң Казан электротехника заводында эшли, предприятиенең гражданлык оборонасы штабы начальнигы урынбасары була. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнгән.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

Анатолий Степанович Трифонов

1923 елда Казанда туган. 1942 елның җәендә армиягә чакырыла, Мәскәүдәге кыска сроклы курслардан соң, күзәтүче-разведчик белгечлегенә ия була һәм 97 нче «катюшалар» гвардия миномёт полкының 388 нче дивизионына кабул ителә. Фронтта – 1942 елның сентябреннән, Воронеж, Степной, Дон һәм Икенче Украина фронтлары составында сугышларда катнаша. 1943 елның мартында, немецлар контратакасы вакытында, чолганышта кала һәм дивизионның документларын ышанычлы рәвештә яшереп, үзебезнекеләр ягына чыга ала. Авылны немецлардан азат иткәннән соң, документлар частька әйләнеп кайткач, сугышчыны орденга тәкъдим итәләр. 1944 елның гыйнварында Мәскәү артиллерия училищесына җибәрелә, ике елдан аны тәмамлап, кече лейтенант дәрәҗәсенә ия була. 1947 елда демобилизацияләнеп, туган шәһәренә әйләнеп кайта. Утыз елдан артык Казан электротехника заводында эшли.

Анатолий Трифонов 1945 елның 24 июнендә Мәскәүдәге Кызыл мәйданда Җиңү парадында катнаша. Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Равил Сөләйман улы Гыйльфанов

1929 елның 29 маенда Казанда туган. 1943 елда, 14 яшьлек үсмер килеш, 708 нче хәрби заводта (хәзер Казан электротехника заводы) токарь булып эшли башлый. 1944 елның августында ВМФның Соловецк Юнгалар мәктәбенә кабул ителә. Уку дәвамында утраудга дошман десантлары төшүгә каршылык күрсәтү операцияләрендә катнаша.

Гыйльфанов Р.С. Юнгалар мәктәбе.

1945 елның августында, юнгалар мәктәбен тәмамлагач, Балтыйк флотының 1 нче Кызыл Байраклы торпеда катерлары бригадасына җибәрелә. Юнга-моторчы Гыйльфанов хезмәт иткән катер күптән түгел барган сугыш урыннарыннан диңгез юлы белән качарга омтылган вермахт сугышчыларын эләктерү өчен оештырылган махсус корабльләр группасына тапшырыла.

1952 елда демобилизацияләнә. 1957 елдан 1993 елга кадәр Казан электротехника заводында эшли башлый. Монда 26 ел дәвамында баш инженер булып эшли. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Ушаков, «Поляр арьягы оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнгән. Хезмәттәге казанышлары өчен «Почёт Билгесе» ордены белән бүләкләнгән. Оборона техникасы һәм эшләнмәләре серияләре үзләштерү һәм җитештерү өчен СССР Дәүләт премиясе лауреаты.

Гыйльфанов Р.С. – торпеда катеры матросы.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Виталий Порфирьевич Логвиненко

1920 елның 28 мартында УССРның Кировоград өлкәсе Знаменка шәһәрендә туган. Сугыш башлану авиация техник-лейтенанты Виталий Логвиненконың Ленинградта – яңа техниканы үзләштерү өчен ВВС академиясе филиалында командировкада булган чагына туры килә. Озакламый ул Югары Башкомандующий Ставкасы каршындагы ерак очышлы авиациягә җибәрелә. Логвиненконы Ерак авиациянең 890нчы авиация-бомбардировка полкына исәпкә кертәләр. Ул «ТБ-7» экипажы составында Берлинны бомбага тотуда катнаша. Дошманның ерак тылына барлыгы 86 сугышчан очыш ясый. 1943 елда Берлинга бомба ташларга очасы самолёты һавага күтәрелгән чакта һәлакәткә дучар була. Логвиненко могҗиза белән исән кала, ләкин, тәне пешеп, шактый гына җәрәхәтләр дә ала. Сигез ай буе госпитальләрдә ятканнан соң, врачлар аның турында «очыш өчен ярамый» дигән вердикт чыгара. Үз полкына кире кайткач, Виталий хезмәтен инде җирдә дәвам итә...

1958 елда демобилизацияләнә. 1962 елга кадәр, лаеклы ялга киткәнче, Казан электротехника заводында эшли.

Ике Кызыл Йолдыз ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, төрле медальләр белән бүләкләнгән.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Галимҗан Рәхимҗан улы Мостафин



Мостафин Г.Р. (уңда). 1945 ел, гыйнвар, Литва.

1926 елның 26 декабрендә Башкортостанның Трунтаеш авылында туган. Армиягә 1944 елның февраль аенда чакырыла, фронтта – 1944 елның мартыннан. Элемтәче Галимҗан Мостафин элемтә линияләренең өзлексез эшләвен тәэмин итә, зыян килгән кабельләрне ялгый – еш кына дошман пулялары астында, канкойгыч сугышлар барган чакта. Көньяк Украинаны, Кырымны, Балтыйк буен азат итүдә катнаша. 3 нче Белоруссия фронты составында Кёнигсбергны штурмлауда катнаша. 1945 елда Җиңү көнен Көнчыгыш Пруссиядә каршылый. Җиңүдән соң 2 нче Ерак Көнчыгыш фронтында Японияга каршы сугышта була, Көньяк Сахалинны азат итүдә катнаша, яралана. 1947 елга кадәр Галимҗан Мостафин үз хәрби подразделениесе составында Сахалинда элемтә линияләре суза, аннары тагын 30 ел дәвамында чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Отставкадагы майор.

II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Кёнигсбергны алган өчен», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен», «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Мостафин Г.Р. (сулда).

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

ТАТАРСТАННЫҢ *Үлемсез* ПОЛКЫ

Георгий Михайлович Фролов

1923 елның 24 апрелендә Владимир өлкәсенең Гороховец шәһәрендә туган. Армиягә 1941 елда Арчадан чакырыла һәм Ульяновск очучылар училищесына җибәрелә. Фронтта – 1942 елдан. 569 нчы Кызыл Байраклы III дәрәҗә Суворов орденлы Осовецк штурм авиациясе полкында техник булып хезмәт итә. Гвардия старшинасы Георгий Фролов Ил-2 штурмовикларын очышларга әзерли. Полк урнашкан аэродромнарны берничә тапкыр бомбага да тоталар, бер тапкыр, ялгышып, хәтта – күрше полк очучылары да...

Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Материалны Казан электротехника заводы тәкъдим итте

569 нчы ШАПка орден тапшыру.

Полкның очучылар составы. 1945 ел. Германия.



Кадерле ветераннарыбыз! Хөрмәтле татарстанлылар!

Тимур Халиков,
«Россиянең үлемсез полкы» Бөтенроссия иҗтимагый гражданлык-патриотик хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлеге рәисе.

Кирилл Шабалин,
Казандагы «Үлемсез полк» йөреше координаторы.

Игелекле традициягә әверелгән «Үлемсез полк» хәрәкәте илдәге иң якты, халыкчан, кешеләрне берләштерүче вакыйга булып тора. Без – туган илне саклаучыларның, фашизмны җиңеп, дөньяда тынычлыкны саклап калганнарның буыны – аны ихластан хуплыйбыз. Һәм бу хәтер, ватандашларыбыз кайда гына яшәмәсен, язмыш аларны кая гына илтеп ташламасын, буыннан буынга күчеп бара.

Татарстан Республикасында, бөтен илебездәге кебек үк, дистәләгән еллар буена халыкның намусы һәм батырлыгы турында, Бөек Ватан сугышы геройлары: армия һәм флот ветераннары, тыл хезмәтчәннәре һәм партизаннар, фашист лагерьлары тоткыннары, блокада кичерүчеләр, каршылык хәрәкәте сугышчылары хакындагы хатирәләрне сакларга омтылыш яшәде. Хәтта катлаулы 90 нчы елларда да ветераннар, дәүләт хакимияте органнары, җәмәгатьчелек органнары көче белән республиканың яшь буынына патриотик тәрбия бирү буенча эш дәвам итте. Россия Президенты Владимир Путин бик дөрес әйтте: «Үлемсез полк»ның кыйммәте шунда: бу инициатива кабинетларда, администрация структураларында түгел, ә безнең кешеләрнең йөрәкләрендә туды. «Үлемсез полк» – абсолют чиста һәм ихлас проект, ул шундый булып калырга да тиеш».

Бүгенге көндә «Үлемсез полк» йөреше республиканың зур шәһәрләрендә дә, иң кечкенә җирлекләрендә дә үтә. Елдан-ел, өстән бирелгән күрсәтмә буенча түгел, «Үлемсез полк»ка катнашучыларның саны арта бара, торган саен күбрәк кешеләр үзләренең Ватанны саклаган якыннарының һәм туганнарының фотографияләрен һәм документларын табып алалар. 2015 елдагы Җиңү паркындагы беренче йөрештә 3000 кеше катнашкан булса, 2017 елда инде Казанның үзәк урамнарыннан 120 000 катнашучы үтте, быел исә алар тагын да күбрәк булды. Без «Үлемсез полк»ка, барысы бергә иңгә-иң куеп, Татарстанның барлык җитәкчеләре, беренче Президент Минтимер Шәрип улы Шәймиев, Президент Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, ветераннар, Казан шәһәре һәм республика кешеләре чыгуына шатланабыз.

«Үлемсез полк» координаторларының яшь буыны исеменнән без республиканың барлык халкына хәтерне саклаулары һәм Бөек көн – Җиңү көне булган 9 Майда «Үлемсез полк» йөрешендә актив катнашулары өчен рәхмәт белдерәбез!

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+



КҮПМЕ СОЛДАТНЫҢ ЙӨРӘГЕН ҖЫЛЫТКАН...

Без аларны 9 нчы майда кечкенәдән җырлап үстек – һәйкәлләр, Мәңгелек ут һәм Бөек Ватан сугышының тере шаһитлары булган, сафлары елдан-ел сирәгәя барган ветераннар каршында. «День Победы», «Священная война», «Катюша», «Тёмная ночь», «В землянке», «Смуглянка», «Синий платочек»...

Луиза Янсуар
әзерләде

Ә татарча җырлардан нindiләрен беләбез? Сугыш вакытында солдатлар йөрәгә аша узганнарны? Нинди җырларны җырлый-җырлый утка кергән татар солдатлары, нindiләрне җырлап юанганнар сугыш афәте беразга гына тынып торган чакларда окоп, землянкаларда. Миңа калса, халык хәтерендә булган җырларны җырлаганнар алар. Татар җырларының борынгыдан килгән генофондында сакланган көйләрне. Музыка белгечләренең әйтүенә караганда, лирик эчтәлекле халык җырлары белән беррәттән, фронтка йөргән җырчы бригадаларның репертуарында өстенлекне патриотик җырлар алып торган: «Каз канаты», «Илкәем», «Комсомолка Гөлсара», «Уракчы кыз» һ.б. Алар совет чоры солдатларына сугышчан дәрт, рух өстәргә тиеш булган.

Совет иленең башка милләттән булган солдатлары белән бергә, татар солдатлары да, аңлашыла ки, «Священная война», «В землянке», «Катюша»ларны җырлаган. Ул җырларның да күпчелеге асылда сугыштан соң популярлашып, чын мәгънәсендә халыкка таралган. Татар җырларыннан бу очракта иң беренче булып хәтергә Муса Җәлил сүзләренә Салих Сәйдәшев иҗат иткән «Җырларым» килеп төшә.

Фотолар язучыларның шәхси архивларыннан һәм http://waralbum.ru/ сайтыннан алынды.

«УЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ ӨЧЕН КАЙГЫРА...»

Җырларым

Муса Җәлил сүзләре • Салих Сәйдәшев көе



Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хакыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Әмма бу җыр – сугышның үзе узганнан соңгы постфактум. 1943 елның 26 ноябре датасы белән тамгаланган Җәлил шигыре шагыйрь үзе әсирлеккә төшкәч язылa һәм бары тик сугыш беткәннән соң гына илгә әйләнеп кайта. Ул Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәрләре»нең 2 нчесендә теркәлгән беренче шигырь – дәфтәр шушы текст белән ачылып китә. Ә менә җыр буларак ул гомумән 50 нче еллардан соң гына халыкка тарала. Чөнки «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләр тупланган Җәлил китабы үзе дә тәүге кат 1953 елда гына дөнья күрә.

Төгәлрәк итеп әйтсәк, Салих Сәйдәшев «Җырларым»ны 1954 елның февраль аенда иҗат итә. Бу вакытта күренекле композитор инде каты авыру хәлдә була. «Җырларым»ның текстын ул бик ошата. Халык та бик җылы итеп кабул иткән әлеге җырны аның «соңгы җыры» дип әйтсәк тә була. «Җырларым»ны беренче башкаручы – Халидә Зәбирова. Җырчы аны беренче мәртәбә Татар композиторлары пленумында 1955 елның 19 маенда башкара.

1942 нче елның җәендә Муса Җәлил фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, аның җитәкчеләреннән берсе була, бик күп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Берлиндагы Моабит төрмәсенә ябалар. Үлем җәзасы көткәндә язган шигырьләрен Җәлил үзе ясаган кечкенә генә дәфтәрләргә теркәп бара. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда «Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән беләләр. Беренче дәфтәргә Муса Җәлилнең алтмыш шигыре теркәлгән, һәм дәфтәрнең соңгы битенә васыять язылган:

«Моны язды татарның билгеле шагыйре М. Җәлил. 1942 елны сугышка керде һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, сәяси яшерен оешмага катнашуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлкем, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 енең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән шагыйрьнең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул.

1943, декабрь».

Бу дәфтәрне 1944 елның февралендә Тегель төрмәсеннән Габбас Шәрипов исемле әсир алып чыга. Аннан ул аны Нигъмәт Терегулов дигән кешегә тапшыра. 1946 елны Терегулов дәфтәрне Татарстан Язучылар берлегенә китереп бирә.

Икенче дәфтәрне Муса Җәлил саклар өчен Бельгия партизаны Андре Тиммерманска биргән. Әлеге намуслы кеше 1947 нче елда аларны безнең илебезгә җибәрә.

Җәлилнең өченче дәфтәре дә булган, дигән фикер бар. Ләкин әлегә ул табылмады, аны эзләү дәвам итә. 1944 елның 25 августында Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалыйлар. Җәлилчеләр соңгы сәгатьләрендә дөнья белән кулларына Коръән тотып хушлашалар.

Җәлил исемен илебез халкы горурлык белән искә ала. Һәр буын аны йөрәгендә саклый. Аның көрәше һәм эшчәнлеге – күпләр өчен кыюлык һәм батырлык үрнәге.



«ТАТАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ТАНГОСЫ»

Көтәм сине

Әхмәт Ерикәй сүзләре • Сара Садыйкова көе

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, көләч йөзле иркәм?
Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм.

Сагыналар сине матур кошлар,
Сагыналар сине якын дуслар.
Күңелем эзли сине кич-иртән,
Мин сине һаман сагынып көтәм.

Китмисең минем йөрәгемнән,
Төшмисең минем телләремнән.
Көн саен, сәгать саен, иркәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм.

Кайт, иркәм, тизрәк-тизрәк миңа,
Синнән башка юк тормыш миңа.
«Көт, иркәм, кайтам», дигән сүзең
Музыка төсле тоела миңа.

Әле 1941нче елда һәм аннан соң туып калган буын вәкилләре дә бу җырның ни дәрәҗәдә халык арасында популяр булуын яхшы хәтерли. Ә аларның әниләре Сара Садыйкованың Әхмәт Ерикәй сүзләренә иҗат иткән һәм аңа җан өргән, мәңгелек гомер биргән җыры астында биегән дә, елаган да, сагынган, өметләнгән, көткән дә.

Сара Садыйкова татар музыка-җыр сәнгатендә беренчеләрдән булып танго, фокстрот, блюз өслүбендәге әсәрләр иҗат итә башлый. «Көтәм сине» тангосын ул 1942 елда яза. Аның беренче башкаручысы – Фәхри Насретдинов. Ә аннан соңгы башкаручыларын исәпләп, санап та, очына чыгарлык түгел. Ярату һәм наз бөркелеп торган, сүз белән моң гармониясе яшәгән әлеге сәнгать әсәрен бүген дә бик яраталар. Ул кеше хисләре исән чакта яши торган үлемсез классикабызның искитмәле матур үрнәге, татар җырларының алтын фондының бизәге.

Әйтергә кирәк, «Көтәм сине» иҗат ителгән чорда Сара Садыйкова һәм Фәхри Насретдинов фронттагы солдатларның рухын күтәрер өчен җырчы бригадалар составында солдатлар янына чыгып йөри торган була. Заманында әлеге бригадаларда йөргән кайбер җырчылар «Көтәм сине» җырын кат-кат соратып җырлатуларын, көтеп алуларын, ул җыр яңгыраганда әзмәвердәй ирләрнең дә күз яшьләрен тыя алмауларын искә төшерә. Җырның жанрын төгәл белмәсә дә, халык яхшы абайлый: клубларда, кичәләрдә «тансы көе» дип атап йөртә торган була. «Теге тансы көен уйна әле», – дип, аны сорап уйнатуларын бер истәлегендә язучы Рабит Батулла да искә ала. «Без – яшьләр – үзебезнең тангога, беренче татар тангосына, Сара Садыйкова көенә рәхәтләнеп бии идек», – ди ул. «Күпме йөрәкне кавыштырган икән ул җыр», – дигән иде аның хакында бер сөйләшеп утырганда Сара Садыйкованың кызы Әлфия апа Айдарская да.

Әлеге җырны Сара Садыйкова 1942 елда якын дусты сугышка китеп хәбәрсез югалгач иҗат итә. Хәрби хастаханәләрдә ята торган яралы сугышчылар – русмы ул, татармы, башка милләт вәкилеме – шушы җырны җырлап юана торган булалар. Олег Лундстрем җитәкчелегендәге эстрада оркестры башкаруында ул Европа залларында, бәллүр люстралар астында зиннәтле күлмәкләр киеп алган туташ вә ханымнар, фырт әфәнделәр биеп әйләнгәндә яңгырарга тиештер кебек тоелып китә... Әмма юк, затлы бу татар җыры үтә дә натуралистик, романтик булмаган шартларда яңгырап торган. Һәм яу кырында үлем белән якалашып яткан, ачтан, салкыннан интеккән күпме солдатның йөрәген җылыткан...

КАЙСЫ БУЫНДА ӨЗЕЛЕР?..

Тагын бик күп алар Бөек Ватан сугышы турындагы җырлар – Марсель Галиев сүзләренә Луиза Батыр-Болгари иҗат иткән «Кайту», Әнгам Атнабаев сүзләренә Рим Хәсәнов иҗат иткән «Егетләр солдаттан кайталар», Самат Шакир сүзләренә Фасил Әхмәтов иҗат иткән «Яраннар чәчәк аткан», Разил Вәлиев сүзләренә Рәшит Абдуллин иҗат иткән «Егерме миллион» һ.б. бик күпләр.

Бөек Ватан сугышы безнең өчен көннән-көн коры мәгълүмати факт төсмерен генә ала бара. Y буыны вәкилләре әле совет чорына караган кинофильмнардан, матур әдәбияттан, әби-бабайлар сөйләгән истәлекләрдән, гаилә альбомында сакланган фотолардан аның дәһшәтен күпмедер дәрәҗәдә тоя, йөрәге аша кичерә. Ә менә 95нче елдан соңгылар, шартлы рәвештә Z буыны дип атап йөртелүчеләр һәм аннан соңгылар инде «Үлемсез полк» белән чыккан мәйданнардагы фотолар аша гына ваемлый аны. Виртуаль пространство – компьютер уеннары мәйданындагы вакыйгалардан әллә ни аерылмый алар өчен бу сугыш.

Яралар йомыла бара. Әрнү басыла төшә. Бу җырлар да, бәлки, кемнәр өчендер инде абстракт



«ҖИЛ ЙӨРИ КУРГАННАР АРТЫНДА...» *Солдатлар*

Роберт Әхмәтҗанов сүзләре • Фәтхерахман Әхмәдиев көе

Озатып, вокзаллар каршында
маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
дөньяны күрмәгән балалар.

Балалар керделәр утларга,
балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
калдылар еракта йокларга...

«Балалар, торыгыз, балалар,
ашыгыз суына табында!..»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син ана,
айларны, елларны санап бар.
Йөрәктә һаман яшь, гел бала–
кайтмаган солдатлар, солдатлар...

Ана ул йокламый, сабые
юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле,
Мәйданда Мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
җил йөри курганнар артында...

Бу җырдан башка бер генә Җиңү бәйрәме, митингы да узмый иде без үскәндә. Хәзер дә узмый дип беләм. Бу XX гасырның дәһшәтле вакыйгасы – Бөек Ватан сугышы турында язылган иң тетрәндергеч һәм сискәндергеч шигырьләрнең һәм иҗат ителгән җырларның берсе. Без ретроспективада сугыш барган еллардагы, аның эчендә (яу кырында) һәм, шулай дип әйтергә яраса, перифериясендә (тылда) аның сулышын тоеп торучыларның әсәрләренә кагылдык. Берсе – Германиядә һәлак булган һәм сүзләре кабат иленә кайтып ирешкән, үтә халыкчан аһәңе, пафосы белән аерылып торган шагыйрь сүзе һәм аның җырдагы чагылышы. Икенчесе – «авыр җан сөйгәннәрнең булмавы» дип, әле Беренче бөтендөнья сугышыннан ярларын көткән «Гөлҗамал»лардан килгән сагышны XX йөз башы тенденцияләренә – модерн рухына төреп биргән хатын-кыз рефлексиясе. Ә өченчесе инде этиләре сугышта калып һәлак булган, үзләре ятим, ач-ялангач булып үскән, балачагы харап булган буынның тарихи чынбарлыкны яңадан торгызырга, анализ аша үткәреп, ваемларга омтылуының бер билгесе.

Кайчандыр Роберт Әхмәтҗановның бу җыры турында язучы Ибраһим Нуруллин: «Әгәр Роберт Әхмәтҗан, бүтән берни дә язмыйча, бары «Солдатлар» исемле шигырен генә биргән булса да, исеме әдәбиятыбыз тарихына кереп калыр иде... Шагыйрь унтугыз яшьлек лейтенантларны, унсигез яшьлек солдатларны шинельләренә төренеп мәңгелек йокыга талган балалар дип атый. Менә шушы зур шигъри табыш әсәрне тылсымлы итә».

1935 елда туган Роберт Әхмәтҗанов «Без 41нче ел балалары» дигән Мөхәммәт Мәһдиевлар буыныннан аз гына өлкәнрәк. Ул әтисе Вәли Әхмәтҗанов фронтка киткәндә инде хәлләрне азмы-күпме белешердәй яшьтәге олан була. Роберт Әхмәтҗанов иҗатыннан сугыш, афәт дәһшәте шәрран ярып, бөркелеп, шартлап, тетенләп тора – Вьетнам булсынмы ул, Чернобыльмы, Хиросимамы, Боснияме, Әфганмы, Чечнямы... Бер имин, тыныч кына булып, кояшка, чикерткәләр, тургайлар җырына күмелеп утырган балачак дәүләтең кинәттән бомбага тотылып шартласа, колагыңа инде шул яңгырау тавышы гомер бакый ишетелеп тора, күрәсең. Һәм курганнар артында йөргән җил дә үзен гел сиздерә – үтәли кистерә...

яңгырашка ия була бара. Минем күзәткәнем бар: 18–20 яшьтәге татар яшьләре, мәсәлән, Сара Садыйкованың «Көтәм сине» җырын «прикольный» дип таба, ретрога, винилга мода кабат әйләнеп кайткан хәзерге көндә аны яңа заман дискотекаларында, тусовкаларында «әйләндерә». Бу җырлар артында реаль язмышлар, табу-югалтулар, хәтта үлем барлыгын күз алдына китерми дә...

Польша язучысы Януш Леон Вишневскийның бер әңгәмәсенә юлыкканым бар. Анда ул кызларының Икенче бөтендөнья сугышы дигән вакыйгага абстракт, аналитик ноктадан карарга өндәп, Холокост фактына да нейтральлек саклауны алга сөрүләре турында сөйли. «Асылда, шулай итеп алар поляк-яһүд дигән бүленеш булырга тиеш түгел, дигән гуманлы карашны алга сөрәләр, алар глобализм бастырып килгән шартларда лояль һәм һәркемгә комфорт шартлар вәгъдә итүче яңа дөнья төзергә омтылалар», – ди. Шунда ук бераз ачынулы итеп өстәп тә куя: «Әмма моның дөрес юлмы, юкмы икәнен вакыт кына күрсәтә алачак...»

Җирдә һәр нәрсәдән эз кала. Кешедән – бигрәк тә. Бу җырлардан без шул югалган кешеләрнең эзләрен барлый алабыз. Ә калганы, чынлап та, Вакыт эше.

«БИТЛЕК»ЛЕ БИЮЧЕ

«Алтын битлек» премиясен тапшыру тантанасына ул ап-ачык итеп «Барыбер» сүзе язылган футболка киеп килгән иде. Матбугатка ул моны үзе кияргә теләгән пинжәкне репетициядә онытып калдырган булуы белән аңлатты. «Тантана» премиясе тапшыру кичәсендә дә Нурбәк нәкъ әнә шул футболкадан иде... Ләкин шаянлык һәм шамакайлык – чын җитди максатларга ирешү өчен, Нурбәкнең чын актер буларак кия торган битлекләре генә ул.

Автор:
Олеся Бондаревская

ХУШ, БАЛЕТ?

26 яшендә һич көтмәгәндә Нурбәк Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында биюче карьерасын туктатырга карар кыла һәм Санкт-Петербургка балетмейстерлыкка укырга китеп бара. Моңа ике нәрсә этәрә: яшь кеше өчен һөнәри үсеш мөһим дип санаган әти-әнисенең теләге һәм, ниһаять, атасы – атаклы язучы һәм драматург Рабит Батулла күләгәсеннән чыгу нияте.

– Чынлыкта, мин әллә ни төптән уйлап тормадым. Ни телим, шуны гына эшләдем. Ләкин әти-әнием өчен хәлләрнең коточкычлыгы шуннан гыйбарәт булды: ике елдан соң мин Санкт-Петербург консерваториясен ташлап, Театр сәнгате академиясенең актерлык осталыгы курсларына укырга кердем. Сиңа 26 яшь булып, ошбу гомереңнең күп өлешен классик балет белән шөгыльләнәсең икән, һәркем синең тормыш юлың инде билгеләп, сызып куелган дип уйлый. Ә мин нульдән башладым, – дип сөйли Нурбәк.

АВАНТЮРИЗМ НӘСЕЛДӘН КИЛӘ

Нурбәкләр гаиләсендә тормыштагы урыныңны эзләү ниндидер гореф-гадәт диярлек, нәселдән килгән нәрсә кебек. Нурбәк уйлавынча, бәлки, барысы да бабасыннан башлангандыр. Ул гомеренең беренче яртысында мөгаллим була. Гаилә шактый яхшы көн күрә, хәтта шулкадәр шәп ки, авылдашлар алар хакында «артык яхшы яшиләр» дип сөйләнә башлый. Катлаулы чорлар бу – үткән гасырның 30 нчы еллары. Бабай бөтенесен ташлый да, гаиләсен алып, күрше авылга күченеп китә һәм балта остасына әйләнә. Уңышка да ирешә: берничә елдан машина ала да, элекке авылдашларын шаккатырып, алар яныннан җилдереп узып китә. Дөрес, берничә көннән салмыш килеш агачка бәрелеп, ул машинаны ватып-изеп тә бетерә...

– Мин аның турында еш уйлыйм. Борынгылар кушканча, җиде буынымны белмәсәм дә, гомумән алганда, ата-бабалар рухы минем өчен бик мөһим. Нәкъ менә нәсел тамырлары безнең кем булуыбызны билгели. Әнием ягыннан әбием 102 яшькә кадәр яшәде, әлеге озын гомерлелек гены миңа да күчкәндер дип өметләнәм, – дип сөйли Нурбәк. – Әнием гаилә учагын саклаучы. Ә әтием аркасында исә (кайчак аңа да карамастан) мин бүген ирешкәннәремнең барысына да ирешә алдым.

НУРИЕВ ТҮГЕЛ

Нурбәкнең балетны сайлавы (яки балетның аны сайлавы) турында гаилә риваятьләре шактый. Аларның берсе мондыйрак: әтисе улын ниндидер татар концертында сәхнә артына алып керә, ә бер номер вакытында кемдер аны «бар, бие» дип сәхнәгә этеп чыгара... Җиде яшендә Нурбәк хореография училищесына укырга керә. Бераздан сәләтле Нурбәктә «икенче Нуриев»не күрә башлыйлар. Ләкин яшь егетнең үзе – Нурбәк булып каласы килә. Бервакыт, ул чакта инде опера һәм балет театрында ике ел чамасы биегән Нурбәк, спектакль-манифест куярга карар кыла һәм аны «Минем Нуриев» дип атый. Бу спектакльдә егет бер үк вакытта режиссёр да, биюче дә, актёр да була. Әлеге куелыш шактый күп физик һәм рухи тырышлык бәрабәренә тормышка ашырыла. Батулла Нуриевне үзе күргәнчә, үзе тойганча уйный, шул рәвешле ул һәркемгә: «Мин ул түгел. Мин – башка», – дип ирештерергә тели. Әлеге спектакль Нурбәк өчен тормыш юлының башлангыч ноктaларыннан берсенә әверелә.

– Хәзер Нуриев мине катлаулы, күпкатлы шәхес буларак кызыксындыра. Ләкин биюче буларак, ул тагын да күбрәк нәрсәгә ирешә алыр иде кебек тоела, – дип саный Нурбәк.

НУЛЬ ХАЛӘТЕНДӘ

Санкт-Петербургта егет бию белән бар көченә шөгыльләнүне туктата һәм актёрлык осталыгы

Фото: Рәмис Нәҗмиев

серләрен өйрәнү эшенә чума. Моның өчен ул шактый үзенчәлекле, актёрлык уку йортларының кайберләре кабул да итмәгән Николай Демидов системасын сайлый. «Нуль»гә әйләнеп, бушана, тышкы һәм эчке хисси тавышлардан арына белү, сәхнәгә бары бер идея белән генә сугарылып чыгу – Нурбәкне менә нәрсәгә өйрәтәләр. Курсташлары белән Островский пьесасыннан бер өзекне сәхнәләштергәндә, репетицияләр болайрак уза: егерме минут – пьесага баштанаяк кереп китү, ике сәгать – максатчан рәвештә «юләр сату»...

– Бер карасаң, мондый техника белән нәрсәгә ирешеп була соң? Ләкин бервакыт репетициядә мин ролемнең текстын сөйләргә әзерләнеп, авызымны ачтым да үзем өчен көтмәгәндә Островский авызы белән сөйләп киттем. Бу – абсолют яңалык, яңа нәрсә иде. Әлеге белемнәр миңа никадәр булышты һәм булыша икәнен сөйләп тору артык. Проблема шунда: югары уку йортларының һәм училищеләрнең күбесендә актёрларны уйнарга – аның персонажы нәрсә хис иткәнен күрсәтергә мәҗбүр итәләр. Шунлыктан бик күпләр шулкадәр тырышып уйный һәм, тамашачы нәрсә өчен акча түләгәнен күрсен өчен, артыгын тырышып җибәрә, – дип аңлата Нурбәк. – Әмма Россия һәм Татарстанның сәхнә сәнгатенә үз эчендә һәм дөньякүләм тенденцияләрдә активрак хәрәкәт итәргә күптән вакыт. Әгәр театрда барысы да профессионал булып, ни эшләгәнен төшенеп, яхшы итеп башкара икән, тамашачы андый театрдан китмәячәк. Хәтта консерватив карашлы тамашачы булса да. Үзенең авангард стиле, гауга куптарырлык алымнары белән билгеле хореограф Пина Бауш карьерасының уңышлы бер чорында үзәктән читтәге Вупперталь шәһәренә күченә һәм бу калага contemporary dance (контемпорари данс, заманча бию) алып килә. Кешеләр башта тамаша залыннан ризасызлык, канәгатьсезлек белдереп чыгып китә. Аннары кире кайта башлыйлар. Ә берничә елдан Вупперталь театры дан казана, аны дөньяның барлык театр фестивальләрендә колач җәеп каршы алалар.

ӘҮВӘЛГЕГӘ КИРЕ КАЙТУ

Лев Гумилёвның пассионарлык теориясе раслаганча, милләт чәчәк атар алдыннан ниндидер этәргеч яки дрейф – якты, алдынгы сыйфатларга ия шәхесләр барлыкка килү чоры була. Язмабыз герое фикеренчә, татар милләте хәзер нәкъ менә шундый фазада. Нурбәкнең кабатланмас сыйфатларыннан берсе исә – нинди генә иҗади үрләргә омтылмасын, халкының гореф-гадәте, йолалары һәрчак аның белән. Академиядәге остазы Алиса Иванова шәкерте турында менә нәрсә сөйли:

– Беренче курс студентларына йөкләнгән биремнәрнең берсен якынча «Бүлмәдә ялгызың» дип атарга була иде. Нурбәк намазга әзерләнүен сурәтләгән этюдны бик җентекләп әзерләде. Рус егетләре өчен бу яңалык иде...

«Алтын битлек» театр премиясе жюрие, тамашачылары һәм тәнкыйтьчеләре өчен дә «Әлиф»* спектакле әнә шундый яңалык булды. 2016 елда Казанга һәм биюгә – бу юлы инде заманча биюгә – кире кайткан Нурбәк анда төп һәм бердәнбер рольне башкара.

МОГҖИЗАГА ТИҢ

Бу спектакль Нурбәк белән хезмәттәшләренең үзенчәлекле нияте – фарсы алфавитын һәм фарсы шигъриятен, бөтен «үле» хәрефләре белән бергә, тән хәрәкәте, бию теленә күчерү идеясе нигезендә туа. Ләкин әлеге мәсьәлә бик катлаулы булып чыга. Репетицияләр барышында режиссёр Туфан Имаметдинов спектакльгә нигез итеп «Туган тел» шигырен алырга тәкъдим ясый, хореограф Марсель Нуриев белән композитор Эльмир Низамов та аның фикерен хуплый. Нәтиҗәдә, өч кисәктән торган спектакль барлыкка килә. Беренче кисәктә Нурбәк гарәп хәрефләрендәге татар әлифбасын бии, ә хатын-кыз тавышлары хәрефләрнең авазын җиткерә. Икенче кисәктә бер тавыш шул ук хәрефләрне көйли, башкасы сүзләр әйтә, өченчесе шигырь юлларын укый. Соңгы кисәктә барысы да бер бөтенгә берләшә. Биюче шагыйрьне гәүдәләндерә һәм шигырь иҗат ителгән чор белән хушлаша.

«Әлиф» Көнбатыштагы тәрдәшләренә охшамаган: анда читтән күчермәләрнең шәүләсе дә юк – лексикада да, композициядә дә, концепциядә дә. Аның үзенчәлелеге могҗизага тиң», – дип бәя бирә спектакльгә «Коммерсант» газетасында балет тәнкыйтьчесе Татьяна Кузнецова.

«МЕССЕДЖ» БАРЫП ИРЕШТЕ

– «Алтын битлек»не тапшырганда, нинди хис-тойгылар кичердем? Дулкынланудыр, мөгаен. Эш шунда ки, мин дә, минем катнашымдагы спектакль дә бу премиягә моңарчы һичкайчан тәкъдим ителмәде, ул ниндидер бик теләп, омтылып алган бүләгем түгел. Әле өстәвенә бу спектакль, «Минем Нуриев» спектакленә караганда, минем өчен күпкә җиңелрәк бирелде, – дип сөйли Нурбәк. – Ләкин шунысы искиткеч – безнең «месседж»ны ишеттеләр. Без зур сәхнәдән торып, тел югалу проблемасына үз карашыбыз турында сөйли алдык. Ә премия номинантлары арасына кергәч, ниһаять, безне монда, Татарстанда да ишеттеләр. Аңарчы безнең хәтта репетиция өчен дә урыныбыз юк иде. Кайда репетиция ясау мөмкинлеге бар – рус яшь тамашачылар театрында, Кариев исемендәге татар яшь тамашачылар театрында, спектакльне шунда әзерли идек. Кариев театрында хәзер үзебезнең даими мәйданчыгыбыз булачак. Тик бу әле бер кечкенә мәсьәләнең генә хәл ителүе...

ТАТАР МӘДӘНИ КОДЫН ЗАМАНЧА БИЮ ТЕЛЕНӘ САЛУ

– Кайвакыт мин үземә бик күп протест рухы кереп оялаган дигән фикергә киләм. Ләкин бу минем әле бик зур үсештә булмавымны гына раслый. Рухият күзлегеннән караганда, көрәш белән янып яшәү дөрес түгел, – ди Нурбәк. Һәм бабасы кебек ул да, максатына ирешү өчен, альтернатив юллар эзли. Хәзер Нурбәк берничә яңа проект әзерли. Пина Бауш кеше күңеленең яшерен хәрәкәтләрен күрә, аларны пластика һәм сюжет ярдәмендә сәхнәгә күчерә белгән. Нурбәк исә борынгы һәм хәзерге татар мәдәни кодын бүген бар дөнья өчен уртак заманча бию теленә сала. Шәмаил – нәфис язу геометриясенә яшеренгән гакыл турында; күзәтү, тамаша кылу өчен дөньяда бик популяр япон будосы яки һинд каларипаяттусыннан бер дә калышмаган татар көрәше турында; Рабит Батулланың абсурд жанрында язылган, сәхнәгә менгерү өчен хәзер бик кулай вакыт булган пьесасы турында сүз бара. Татар телен ничек итеп һәркем өчен кызыклы зурлыкка, үргә әйләндерергә – Нурбәк Батулла бу сорауның җавабын табуга бик якын килгән сыман. Т

*«Әлиф» – гарәп әлифбасының беренче хәрефе.

2018 елның 21 мартында Татарстанның «Ел китабы» бәйгесенә йомгак ясалды. Китапларны сайлауда республиканың 1510 китапханәсе катнашты. Конкурска 381 китап куелып, шуларның 51е – татарча проза әсәре, 75е – татарча шигъри басмалар, 44е – балалар китабы, 49ы – русча китап, 92се – татарча публицистик һәм фәнни-популяр басма, 70е – русча публицистик һәм фәнни-популяр басма. Конкурс нәтиҗәләре буенча алты номинациядә җиңүчеләр билгеләнде. Матур әдәбиятка караган әсәрләрдән төп җиңүчеләр түбәндәгеләр:

«Татарча проза әсәре» номинациясендә:
- I урын – Нәбирә Гыйматдинова (Бикчурова) «Сөйлим, тыңла...»;
- II урын – Айгөл Әхмәтгалиева (Муллагалиева) «Таллыкүлдә былбыл бар»;
- III урын – Сәйдә Зыятдинова «Яралы кош авазы».

Кызыксындыру дипломнары:
- Камил Кәримов «Игезәкләр йолдызлыгы»;
- Гөлсинә Галимуллина «Алтын ачкыч»;
- Равилә Шәйдуллина-Морат «Ялантауга ай кунган».

«Татар шигърияте» номинациясе:
- I урын – Муса Җәлил «Моабит дәфтәрләре»;
- II урын – Роберт Миңнуллин «Монда без дә бар әле!»;
- III урын – Клара Булатова «Гасыр белән гасыр арасында».

Кызыксындыру дипломнары:
- Рәмис Аймәт «Бозлы җилкәннәр»;
- Рәдиф Гаташ «Ихласнамә».

«АВЫЛ» КОДЫ, ЯКИ XXI ГАСЫР ТАТАР ПРОЗАСЫ НИЛӘР ХАКЫНДА УЙЛАНЫРГА ЧАКЫРА?



Нәбирә Гыйматдинова исеме татар укучысына яхшы таныш. Бу язучының инде тәгаенләнеп өлгергән үз аудиториясе бар. Әлеге аудитория вәкилләре аның һәр яңа әсәрен, китабын түземсезлек белән көтеп ала. Быел Нәбирә Гыйматдинованың «Сөйлим, тыңла...» китабы «Ел китабы» республика бәйгесендә беренче урынга лаек, дип табылды. Без сезне бу китап белән таныштырырга кирәк, дигән фикергә килдек.

Автор:
Луиза Янсуар

Сезне мәртәбәле урыннарга һәм дипломнарга ия булган әлеге китаплар белән таныштыруыбызны алга таба дәвам итәрбез. Әлегә җиңүчедән башлый торыйк.

КЕМ УЛ – БЕЗНЕҢ ЗАМАН КАҺАРМАНЫ?

Китап «Нурулла» дигән повесть белән ачылып китә. Әсәрнең каһарманы Нурулла – постсовет чоры әдәбиятына хас «каһарманга сусау» тенденциясенең бер чагылышы. Рус кино сәнгатендә үзгәртеп кору елларының иң популяр каһарманы Данила Бодровтан башланган бу «эзләү» Россия әдәбиятында һәм сәнгатендә әле һаман да актуальлеген югалтмый. Татар әдәбиятына килгәндә, ул гомумән дә гасырлар аша узып, төрле формацияләрне кичеп, дәүләтчелекне сагынып сызлануга кадәр барып тоташа. Әйе, чыннан да кем соң ул «безнең заман герое»? Бүгенге глобализация басымы астында калып, «кече милләт» мөһере сугылып, актив ассимиляциягә (үз туфрагында, ата-баба җирендә) дучар ителгән «татар»ның йөз тоткан лидеры кем дә, үрнәге кем? Бу сорауга җавап эзләмәсә, язучы язучы булудан туктар иде. Һәм, менә, эзли безнекеләр. Куәтеннән килгәнчә, караш киңлеге рөхсәт иткәнчә, дәгъвалары мөмкинлек биргәнчә...

Туфрак темасыннан, авыл һәм шәһәр арасындагы коллизияләрне башлыча авылга йөз борып хәл итүдән, өзлексез ностальгия-сызланудан арына алмаган татар прозасының каһарманы, аңлашыла ки, киберпространство роботы була алмый. Берничек тә. Гәрчә хәзерге авылларыбыз Интернет белән һәйбәт кенә тәэмин ителеп, яңа буын ул каһарманнар белән яхшы таныш булса да. Хиппи яисә фрик – монысы гомумән дә «татарга хас нәрсә түгел». Беләбез. Без бит әле «хайп» дигән төшенчәне ваемлауга да яңа гына килдек. Яхшымы бу, яманмы – сүз ул хакта түгел. Сүз әдәбияттагы дөнья моделе, картинасының ни дәрәҗәдә генетик кодка, тарихи кодка бәйле булуы турында. Ягъни: әле бүгенгә кадәр чүгендер, бәрәңге басуыннан башы чыкмаган, әмма инде өендә виртуаль пространствога чумып, башка дөньяның барлыгын да ваемлаган, тик аңа дәгъва кылырга җөрьәт кенә итмәгән, тәвәккәлләмәгән «гавам»ның әдәбияттагы геройларда ничек гәүдәләнеш алуын күзаллау артык кыен түгел, миңа калса.

Цинизм һәм прагматизм кушылмасыннан гыйбарәт шәһәр мәдәнияте вәкилен исә без әле бар яклап та ваемлап җиткерә алмадык. Чөнки без шәһәрдә дә авыл культурасы моделендә яшибез. Без борынгы кагыйдәләрне онытканбыз, аларның барлыгына да шикләнәбез хәзер. Юкса безне «шәһәрләр тоткан халык» дип атыйлар, затлылыкта «гаеплиләр». Әмма XX йөз башы инкыйлабларыннан соң, тулы бер катлам юкка чыгарылып, затлылык төшенчәсе «кан алмаштырган» шул.

Без һаман да ике чиктә яшәүне дәвам итәбез. Шул рәвешле, татар әдәбиятының күпчелек әсәрләрендә нарратив нигездә барыбер

дә авыл һәм туфрак сыкрануы белән бәйле булып кала бирә. «Нурулла» әсәрендә дә шулайрак. Бу очракта Нәбирә Гыйматдинованың күтәргән тема-проблематикасы актуальлеге белән укучыны җәлеп итми кала алмый: «авыл кемнәр кулына кала?»

Кайчандыр Туфан Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым» ише авыл халкы бик тә яратып караган спектакле каһарманына охшаттым Нурулланы. Аның исемендә үк «нур» дигән тамыр бар. Хатыны Саҗидә, исемен кыскартып, «Нурла» дип эндәшә үзенә. Әсәр авторы безгә алдан ук героена нинди миссия йөкләнгәнен исеме, авыл халкы арасында таралган кушаматы аша сиздереп куя – йөрәге туктап, яңадан тибеп киткән мизгеленнән башлап «әүлия» дип йөртәләр аны. «Син тегендә булып кайтканда, ниләр күрдең? Җәннәт чынлап та бармы?» – дип теңкәсенә тияләр.

Реанимациядән гомуми палатага чыгаргач, янәшә караваттагы абзый аңа:

– Ике тумыйбыз, ике үлмибез, иртән гел бүген бәйрәм дип уян, – диде.

Менә шулай... Уяна Нурулла. Үз җае, үз көе булган тормыш иртәсе гәрчә йөз төрле мәшәкатьләре, аһ-зары, үкенеч-көенечләре белән бусага төбендә үк сагаласа да, ул разый иде. Йөрәге бер туктап алган кеше моны бөтен вөҗүде, бөтен күзәнәкләре белән тоя. Шуңа күрә ир һәр иртәдә бәйрәмчә киенде: моңарчы шкафта сәргәгән өр-яңа костюм-чалбарлар, күлмәк-галстуклар берәм-берәм кузгатыла башлагач, хатыны, шикләнеп:

– Ник алай көязләнәсең, Нурла? – диде. – Элек өстеңдә джинсы белән свитер гына иде.

– Бәйрәм бит, бичәсе.

– Саташма инде, гап-гади көн, Нурла!..

Шактый схематик коры сюжетны Нәбирә Гыйматдиновага хас стильдәге линияле булмаган хикәяләү җанландыра. Кинематографиядә флэшбеклар дип йөртелгән алымнар, ягъни мәсәлән, үткән белән бүгенге арасындагы «кара тишекләрдән» бөркелеп килеп чыккан хатирәләр, рефлексия, фрагментлар. Төнге һаваны кистереп яктыртып алган яшендәй алар. Психоделик кабатлаулар үтемле кулланыла әсәрдә. Мәхәббәт линиясенең үстерелешендә аеруча – нәкъ менә шулар аша без Саҗидәгә өйләнеп яшәгән Нурулланың Туйбикәсе кем икәнен дә, ни өчен әлеге образның аның уенда һәрдаим калкып торуын да, шулай ук рәхәтлек белән бергә җәза да булып яшәвен ваемлыйбыз. «Нибарысы төш кенә иде ул» дип кабатлый әлеге тормышны җигелеп тарткан, балалар үстереп, җимерелеп барган колхозны үз кулына алган әзмәвер ир-ат, үткәннәре искә төшеп, йөрәге тотканда. «Шул колхоз дип йөрәгең челтәрләнде ич инде, Нурла», – ди аңа Саҗидәсе. Әмма тора-бара аңлыйбыз: колхоз дип күпме чапса да, бу эшне ул белә. Хикмәт колхозда түгел, хикмәт аның үз өендә яраткан кешесе белән яшәп, кайтырга ымсынып, ашкынып тормавында. Атлантида сыман югалып барган авылны саклау миссиясен үз җилкәләренә алуны табигый санаган, шуңа куәте җиткән «Нурла» шәхси тормышын баштан ук ялгышка кора, тора-бара үкенечкә әйләнгән бу хата аны тәүлек буена бимазалый. Йөрәге яшәлми калган (яшәлергә тиеш булган!) тормышның үкенеченнән челтәрләнә.

Мәхәббәт һәм намус, мәхәббәт һәм бурыч, мәхәббәт һәм җәмгыять каршылыкларының үстерелеше бу конфликтның мәңгелек булуын тагын бер мәртәбә раслый. Яратуда табигый стихиясендә булган кеше, җәмгыятькә яраклашып, үзенең асылын авызлыклап яшәргә мәҗбүр ителә. Авыл пространствосында яшәгән затлар өчен бу бигрәк тә актуаль. Әмма Нәбирә Гыйматдинова каһарманнары үзләренең горур һәм хөр булулары белән аерылып тора. Шуңа да «Нурла»ның миссиясе әлегә үтәләчәк, дигән ышаныч белән калабыз:

...Тау сыртында ап-ак киемнән ике кеше чалгы белән печән чаба иде. Кем кушкан, йа?.. Нурулла әлеге аймакка беркайчан да тимер ургыч керттермәде. Бабайлар каны тамган уентыкны ул ел саен ике-өч карт белән чистартыр һәм азактан шәһитләр рухына дога кылдыртыр иде...

Юк, кешеләр аның күзенә генә күренә иде. Китеп барышы, ахрысы... Теге чакта, йөрәк чыгымлаганда, ул бит кыр уртасындагы өстәл тирәсенә тезелешеп утырган аксакаллар белән очрашкан иде. Китеп барышы, әйе... Хәзер аяклары җирдән аерыла да... Ни үкенеч, фанилыкта күпме эшләре өелеп кала... Чү, икәүнең берсе Габбас бабасы түгелме соң? Ә аның кырыенда теге яшь хәзрәт! Тәгаен үзе!

Нурулла дык-дык җиргә басып карады. Хәтта үкчәсе чатнады. Шөкер, аяк асты каты иде.

Инвесторлар кулына калган һәм нигездә табыш алу өчен генә җан асраган авыллар турындагы теманы төрлечә күтәреп карадылар һәм күтәрүне дәвам итәләр каләм әһелләре. Нәбирә Гыйматдинова әсәрендә без ияләшкән традицион өслүбенә тугры булып кала: Гарсиа Маркеслардан килгән, үзенә кадәр татар әдәбиятында Фәүзия Бәйрәмовалар кулланган «магик реализм» элементларын мулдан куллана. «Нурулла» XXI гасыр татар авылы трансформациясен күрсәтүче әсәрләр чылбырында үз лаеклы урынын алып, укучысын табып өлгерде. Алда безне яңа каһарманнар көтә.

– Язучы өчен иң беренче чиратта ихласлык кирәк. Әгәр төчеләнеп язасың икән, алдыйсың икән, укучы сиңа ышанмый башлый. «Ахырын нигә күңелсез тәмамлыйсың, нигә гашыйклар бергә калмый?» – дигән сорауларны еш ишетергә туры килде. Әгәр мин аларны бергә калдырсам, бу тормыш дөреслегенә туры килмәячәк. Ясалмалык язучы өчен иң куркыныч әйбер. Аннан соң, синең әсәреңнән укучы нинди дә булса яңалык табарга, фәһем алырга тиеш. Әгәр ул боларны синсез дә белеп тора икән, синең язуыңның бер мәгънәсе дә юк.

Язучы Марат Кәбиров белән әңгәмәдән өзек, «Шәһри Казан» газетасы.

АСФАЛЬТКА ТАМЫР ҖӘЙГӘН АГАЧЛАР

Икенче повесть – «Сөйлим, тыңла...» – теманы киңрәк масштабка алып чыгуы һәм инде шәһәр җирлегендә, яссылыгында провинциядән килгән кешенең үзен эзләве, табуы, раславы турындагы темасы белән үзенчәлекле. Бу үзенә күрә «Москва слезам не верит» героинясы типажының заманча коллизияләр белән баетылган тормышы.

Эчке катламнары, агымнары буенча да, күтәрелгән тема һәм проблемалар, аларның хәл ителеше ягыннан да элгәресеннән күпкә катлаулырак әсәр. Вакытывакыты белән мин хатын-кыз язмышына – аның гадәти булмаган борылышларына багышланган популяр сериал тамашачысыдай

да хис иттем үземне: без 90 нчы елларда бөтен ил белән елый-елый караган «Богатые тоже плачут», «Просто Мария», мәсәлән. Дөрес, милли-тарихи җирлектә, үзебезнең мәдәни кодлар нигезендә корылган сюжет белән.

Нәбирә Гыйматдинованың үзенчәлеге дә шунда: «сериал», ягъни киң кулланылыш өчен яраклы булган, хәтта ки «массачыл» дип әйтсәк тә буладыр, продуктның (тышчасы турында сүз бара) үзәгенә барыбер дә фәлсәфи-эстетик оеткы (эчтәлек турында әйтүем) сала белә ул. Шуңа да әсәрләре киң катлам укучыга кызыклы һәм әдәби кыйммәтен дә югалтмый.

«Бөтенесенә дә кәҗәләр гаепле иде...» дигән юллар белән башланып китә повесть. Әсәрнең төп каһарманы Мәликә – институтның чит телләр бүлеге студенты – сөйгәне Ильяс белән Әмәт бистәсендәге тау битендә, табигать кочагында, имтиханнарга әзерләнеп ята. Бу әле метро төшенчәсенең «М» хәрефе дә булмаган узган гасырның 70–80 нче еллары. Иҗтимагый-икътисадый вазгыять икенче, бәндәләр башка кыйммәтләрне югарырак куя. Озакламый югары кыйммәтләр белән яшәгән, «намус», «кеше хакы» төшенчәләрен санлаган (һәрхәлдә, аның гражданнарына шулай тоелган) Совет империясе җимереләчәк, ә аның каһиннәре башка Аллага иман китерәчәк. Мәликә әле боларны ваемламый, ә менә шәһәр егете Ильясның әти-әниләре инде сиземли – егетне, укуын тәмамлагач, чит илгә җибәрергә ниятлиләр, аңа хатын буларак та яхшы партия күздә тотылган булып чыга. Бу планнар кысасына авыл гыйбады – «Кәҗә Габдрахман» кызы берничек тә керми, билгеле. Әнә, ул үзе дә эченнән генә гасабиланып пышылдый: «Мин бу кушаматымнан зерә хурлана идем, шөкер, шәһәрдә ул – йомылган сер, һәм аның турында иң якын кешем – Ильяс та белмәскә тиеш».

Ильяс зур миссияләр башкару омтылышы белән яшәүче, дөньяны идеаллаштыручы үз чорының хәсрәт күрмичә, җитеш шартларда үскән «алтын яшьләре» вәкиле булып килеп баса безнең күз алдыбызга. Себергә китеп халыкны агарту хыялы белән яна. Кайчандыр мондыйрак хыяллар белән янган Габдрахман Әпсәләмов герое – Мансур хәтернең бер читеннән йөгереп уза. Әмма иллюзияләр белән яшәп, аларны җыңә алган, тормышта үз урынын эзләү-югалтулар аша барыбер эзләп тапкан Мансурдан аермалы буларак, Ильяс намуссыз һәм умырткасыз адәм булып чыга.

Язмыш Әмәт яланында «кәҗә» кушаматын яшергән Мәликәне... Сәлимә исемле кәҗә һәм унбиш баш кәҗә асраучы Дәүләтша карт белән очраштыра. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, дип юкка әйтмиләрдер. Картның карчыгы дөнья куйганнан бирле боегып калган һәм саудырмый интектергән кәҗәләре кызга чат ябыша. Дәүләтша бабайның нәни генә җан асрый торган «бизнесы» да икән бу үзенә күрә. Шулай итеп, Мәликә кәҗә саварга Әмәт бистәсендәге картның ихатасына барып йөри башлый. «Затлы» кияү егете Ильясны аның бу гамәле чыгырдан чыгара, билгеле. Җитмәсә, әниләре Мәликәгә өйләнмәскә дигән шарт куя – андый киленне өебезгә аяк та бастырмыйбыз, диләр. Дәүләтша карт яшьләрне үз йортында яшәргә чакыра. Шулай итеп алар куышка тиенә.

– Биш ел буе ми черетә-черетә тел өйрәнеп, кәҗәләр белән матавыкланырга тиле штоли мин! Минем шикелле егетләр алтын бәһасенә тиң! Министрлыкның чит илләр белән элемтәләр урнаштыру бүлегенә эшкә керәм! Никакой мөгез, никакой тояк! – диде егет.

Загста язылышкач та, ирем белән мөнәсәбәтләрне көйләдем:

– Син эшлә, – дидем. – Ә хайваннарны мин үзем карыйм.

– Һы, дипломлы кәҗә белгече! Оят түгелме?

– Түгел, Ильяс. Вакытлыча бит ул. Мин дә эшләр идем, Казанга туристлар агыла. Агентлыкларга тәрҗемәчеләр төркеме туплыйлар. Хезмәт хаклары да ярыйсы, ди. Дәүләтша бабай кызганыч...

Ни хикмәт, агентлыклар мине кызыксындырмый башлады, чөнки миндә башка юнәлештәге талант ачылды: мин сатуалу мәсьәләсендә яхшы гына алдыртам икән лә. Тикмәгә генә ике «сәүдәгәр»дән тумаган шул: базарда умартачы әти бал сатса, әни халыкны сөт-каймак белән кинәндерә иде. Мәңгелеккә генә иртәрәк күченделәр...

Менә шулай «төшеп калганнардан» булмаган, эшлекле, булдыклы хатыны «кәҗә бизнесын» уңышлы гына алып киткәндә, Ильясның, әти-әни ярдәме тимәгәч, эшләре әллә ни пешми. Хәерче тормышта яшәүләре, сәләмә машинада йөрүе белән бәйли ул үзенең эштән уңмавын. Азрак мая туплаган Мәликә, кредит акчалары өстәп, иренә әйбәт машина алып бирә, «килмешәк килен» булып яшәргә теләмәвен әйтә, «әйдә, әти-әниең белән күрешик, килешик» дип, Ильясны үгетләргә керешә. Һәм менә шунда иренең аннан оялуы, хәтта ки җирәнүе үк ачыклана. «Син бит кәҗә хатыны! Ничек оялмыйча таныштырырмын ди! Безнең әти дә, әни дә профессорлар!..»

Дөньядагы иске кагыйдәләр тора-бара барысын да үз урынына утырта: Ильяс гаиләсенә кайтып сыена да алар ярдәме белән Германиягә китеп бара. Бурычка баткан һәм көтмәгәндә-уйламаганда бернинди терәк-ярдәмсез, таянычсыз калган Мәликә Дәүләтша карт йортында торып кала. Тиздән картның да хәле начарлана, ул йортын һәм хуҗалыгын Мәликәгә калдырырга теләвен әйтә...

Менә шундый борылышларга корылган әсәр алга таба дөньялар болганып китеп, бер система икенчесен алмаштырган бер чорда Мәликәнең ничек итеп хәләл көче белән үз эшен булдыруын – кыйбласын табуын сурәтли. Кешеләрдә дә бик күп тапкырлар алдана ул, ир-атлар тарафыннан да рәнҗетелә, тормышның төбенә төшеп, эчә дә, сукбайлыкка да чыга, әмма барыбер күтәрелергә көч таба. Ә язмышы кәҗәләр белән юкка гына үрелмәгән булып чыга. Кешегә кушаматны да юкка бирмиләр авыл җирендә...

Кайчандыр тулы бер чор кешеләре өчен «тормышка юллама һәм кулланма» буларак кабул ителгән «Москва слезам не верит» фильмындагы гыйбрәтле җырда уйландыра торган юллар бар:

Москву рябины красили, дубы стояли князями,
Но не они, а ясени без спросу наросли.
Москва не зря надеется, что вся в листву оденется,
Москва найдёт для деревца хоть краешек земли.

«Сөйлим, тыңла...» әсәренең каһарманына бик тә туры килә бу юллар. Үз җире өчен җаваплылык тойган, аны бакча итә алырдай Нуруллалар һәм, таш шәһәргә килеп тә, каты бәгырьлегә әверелмәгән, кала чатырманнарында адашып калмаган, умырткасы булган корычагач Мәликәләр барлыгын күрсәтә ул безгә. Бу корыч-агач теләсә кайсы ташка тамыр җәеп, дөньяны ямьләү сәләтенә ия, дип расларга омтыла автор. Һәм ышандыра да. Без андыйларны тормышта аз белмибез чөнки.

Нәбирә Гыйматдинова әсәрендәге чишелеш аша тагын әле шул фәлсәфәне дә ваемларга мөмкин: тир түгеп үз көнеңне күрү, җир җимертеп тормыш алып бару канында булган кешеләрнең безнең заман шартларында әле тагын кеше дә булып кала алулары гаять әһәмиятле. Ә кешене кайчак кеше аяктан егып, дүрт аяклы хайван да коткара ала...

«ТАБИГАТЬ КЕШЕ ХАТАСЫН ТӨЗӘТӘЧӘК»?!

Алдагы ике повесте – «Кәтәнә» белән «Хатыннар сагышы»нда – күтәргән темалары да, аларның чишелеше дә шактый кызыклы, оригиналь. «Хатыннар сагышы» повесте минем өчен китаптагы әсәрләрдән һәм вакыйгалар үстерелеше, һәм чишелеше, һәм героинялары галереясының төрлелеге ягыннан иң кызыклысы булды.

Китаптагы хикәяләр катламына да бераз орынып узасым килә. Алар төрле – тематикасы ягыннан да, стилистикасы буенча да, сурәтләү өчен алынган җирлеге, ягъни хронотоп ягыннан да. Гасырлар буйлап сәяхәткә алып чыгып, кыйсса жанрына тартым хикәяләүгә дә чакыра безне автор, кискен реалистик буяулары белән дә игътибарны җәлеп итә, әлеге дә баягы, югарыда искә алынган, магик реализм элементларын кушып җибәреп, сюрреалистик лабиринтларга да әйди.

Хикәяләр арасыннан күңелемә иң якыны «Акмаңгай» булды. Без бу хикәяне кыскартылган вариантта журнал битләрендә дә тәкъдим иткән идек (№9, 2016). Әлеге әсәрендә Нәбирә Гыйматдинова миңа тагын бер ягы белән киңрәк ачылды: юморы, чәчрәп торган иронисе белән. Хикәясендә лирика белән фарс дигән ике чик арасында куалап йөртә ул укучысын.

Алымы буенча әллә ни зур яңалык булмаса да (әсәрдә хикәяләүнең хайван авызыннан һәм караш ноктасыннан (бу очракта, Акмаңгай атлы сыер турында сүз бара) тәкъдим ителүе гайре табигый яңалык түгел)), сурәтләү осталыгы буенча ул шактый кызыклы һәм оригиналь килеп чыккан. Монда язучы дөньябызның, заман шартлары, таләпләренә җавап биреп, табигатьтән, димәк ки, үзенең табигатеннән дә, бөтенләе белән аерыла баруына ишарә итә. Бу хәлнең чынлыкта нәрсәгә китерүен ваемларга, безгә дә күрсәтергә омтыла. Менә табигый шартларда яшәп, үз туфрагында тәрбияләнеп үскән сыер ханым Акмаңгай белән ясалма ысул белән үрчетелгән Франция кунагы Мадамның әңгәмәсе:

«Унөчле» ямансулап башын аска игән, ул яңа танышы мактанган «кораллардан» мәхрүм иде шул.

– Кайгырма әле син, мөгезең дә, койрыгың да булыр... Син яшь бит, – дигәч, тегесе:

– Булмас инде, – диде. – Кальций дигән витамин сөттә кубәйсен өчен артык җирләребезне кисеп ташлыйлар дисәк, анысы да, монысы да кирәк икән.

– Табигать безгә артык әйберләр тагып мәшәкатьләнмәс иде, «унөчле»! Йә, йә, борыныңны салындырма, син болай да матур! Безнең кебек төсе уңган кызгылт киемнән йөрмисең, тиреңефәкмени – ялык-йолык итә. Үгез әфәнделәр үлеп гашыйктыр әле сиңа.

– Үгез? Бездә андый зат күренми! – «Унөчле»нең төймә төсле түгәрәк күзләре тагын да зурайды. – Кем ул, нишли ул?

– Син соң... – Акмаңгай, оялуыннан нишләргә дә белмичә, тоягы белән җирне тырмаган булды, – ...бозаулыйсыңдыр ич?

– Бозауладым, күрсәтмәделәр генә. Аерым аранда тәрбияліләр.

Бу шартлылык, сатирик детальләштерүләр, сүз уйнатулар әсәрне бер үк вакытта категориаль яктан «массачыл» да итә, әмма нә шул эстетик трансформациясе аша тәэсир көчен дә арттыра. «Мунча ташы» белән «Сүнгән йолдызлар, «Зәңгәр шәл» шикелле ике чиктә, капма-каршы абсолютлар арасында бәргәләнгән халыкның менталитеты өчен тәгаенләнгән текст ул «Акмаңгай». Әмма карап торышка гына. Безгә, Нәбирә Гыйматдинованың гаять төрле булган укучыларына, моны аңларга, кабул итәргә һәм абсурд эченнән тирәндәрәк яткан мәгънәсен «казып алырга» гына кала хикәянең.

«Өске» катламның хозурында гына йөзмәүчеләргә аңлашыла: Акмаңгай образына безнең иң күркәм дә, иң әкәмәт тә сыйфатларыбызны сыйдырган язучы. Әлеге сыер затыннан (асылда сүзнең сыер турында бармавын яхшы аңлыйбыз!) булган каһарманга әлеге дә баягы Атлантидабызга кайтаручы миссиясе йөкләнә. Ул күпмедер дәрәҗәдә, символик гәүдәләнештә, Нурулла белән Мәликә башлаганны төгәлли, дияргә дә мөмкин: «зәгыйфь», «күндәм», «фикерсез» Мадамны асылына алып кайта. Димәк ки, ике арадагы җуелган балансны көйли. Болай булгач, агачлар янә үз туфрагында тамыр җәяр дә, ябалдашлары белән Күккә тоташыр, дигән балаларча самими, әмма өметкә гайрәт-егәр өсти торган юл калдыра:

Иртән Акмаңгай уң колагы белән тыңлап ятты. Абзар ишеге төбендә хуҗа белән хуҗабикә сөйләшә иде:

– Фәндәс, Акмаңгайга ниндидер зәгыйфь хайван ияреп кайтты. Ни кусам да китмәде.

– Нәселле сыер ул, Румия. Ярты ел элек Франциядән кайтардылар. Күндәм алар...

Сап-сары салам өстендә җәйрәп йоклаган Мадам, әлбәттә, аларны ишетмәде. Кичәге күңелле сәяхәт аны бик арыткан иде. Беркатлы Акмаңгай: «Авылда яшәсә, дустыма мөгез дә, койрык та үсәр әле. Мәрхәмәтле табигать, шәт, адәмнәрнең хатасын төзәтер», – дип уйлап куйды.

Нәбирә Гыйматдинованың юморына ияреп, шуны гына өстисе килә: төзәтергә дә бик мөмкин, маллар бит Ильяслар дәрәҗәсенә җитеп мукләнмәгән, сөрсемәгән әле. Үзебездән башлый торсак та ярап куяр, бәлки...

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

«Татарстан» журналының Әдәби премиясе 2018

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы 2018 елгы Әдәби премиягә бәйге игълан итә.

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибар итү максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульъязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән булуы һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы бәйгенең төп шарты!**

Кульъязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2018 ел дәвамында «Татарстан» журналы экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2018 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульъязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульъязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульъязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү срогы: 2018 елның 19 мартыннан 2018 елның 15 декабренә кадәр. Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

ӘТНӘНЕҢ ИҢ БИЕК НОКТАСЫ КАЙДА?

Табигатьнең иң гүзәл чоры – май уртасында Әтнә районының Ары авылында булдык. Биредә яшәүче һәр йорт хуҗасы турында аерым язма әзерләргә була! Кемдер чәч кисә, кемдер камыр ризыклары ясап сата, икенчеләр каз бәбкәләре, чебиләр чыгару белән мәшгуль, берәү мич остасы... Тагын биредә Сталин алдында чыгыш ясаган олы хөрмәткә лаек кеше яши. Кыскасы, үзенчәлекле авыл бу.

Автор:
Руфия Фазылова

1. – Әтием оста куллы иде, аннан күреп өйрәндем, – дип елмайды Наил абый.

2. Останың йорт эче дә бизәкле.

3. Бизәкле капкалы, матур йорт каршысына туктагач, бакча алдында эшләп йөрүче сөйкемле апа – Нурия Сибгатуллина белән таныштык.

4. Гарәфетдин Әхмәтҗанов оныкһәм оныкчыклары белән.

«КҮЛ БАР, ЭЧӘРГӘ СУ ЮК!»

Ары авылы җирлеге башлыгы Хәмит Гәрәев безне Әтнәгә керә торган юл чатында каршы алды.

– Арыга адашмыйча килгән кеше юк. Сез аны тиз генә таба алмаячаксыз, – дип, безгә үзенең машинасы артыннан барырга кушты.

Бактың исә, картада Ары исемле авыл юк. Шуңа күрә аны навигатор тапмый, ә юл күрсәткечләрендә Ислейтар дигән язулар тора. Ә бу Арының русча атамасы икән!

Авыл әллә ни зур түгел: 137 хуҗалык бар, 230 кеше яши. Ары – Әтнә районының иң биек ноктасында урнашкан. 224 метр биеклектә утыра ул. Арыга килеп кергәч тә, авыл уртасында җәйрәп яткан күлләргә игътибар итәсең. Без килгәндә аеруча гүзәл манзара иде: күл буенда ап-ак шомыртлар чәчәк аткан, сиреньнәр ачылырга утыра...

– Авылда әллә ничә күл бар, ә кешегә эчәргә су юк, – диде Хәмит абый.

– Ник алай? – дим.

– Белмим. Инде башня ясау өчен 300 метр тирәнлектә җир казып карадык. Су чыкмый. Булса да, эчәргә яраклы түгел. Авылда 200әр метр тирәнлектә кое казучылар бар. Су һаман юк... Мәңгелек проблема кебек.

– Ә соң халык ничек яши? – дим.

– Кайбер кешеләргә бәхет елмая: алар нигезендә казыгач су чыга. Шуннан күршеләр дә ала инде.

Авылларга килгәч, беренче сорау: мәктәп эшлиме? Арыда да шул сорауны бирдек. Башлангыч мәктәп эшли икән: дүрт бала укый.

– Ике бала калса да, мәктәп эшләргә тиеш, – диде авыл җирлеге башлыгы. – Авылның мәктәбе булмаса, ул картая. Ата-аналар да бик риза, ябылмасын, дип кенә торалар.

Без, журналистлар, авылларда күп йөргәч, һәр районга үзебезчә бәя бирәбез. Бер якта халык кунакчыл, икенчесендә күп сөйләшмәс, өченчесендә караңгырак... Арыда исә халык гади тоелды. Капка төбендә утыручы апалар, фотоаппарат белән йөрүебезне күргәч, тиз генә кереп качмыйлар. (Андыйлар да еш очрый!) Елмаеп сөйләшәләр, фотога төшәләр. Бизәкле капкалы, матур йорт каршысына туктагач, бакча алдында эшләп йөрүче сөйкемле апа – Нурия Сибгатуллина белән таныш-

1

2

3

тык. 82 яшендә икән. Улы Наил белән яши.

– Улым алтын куллы, нәрсәгә алынса, шуны булдыра. Агачтан, калайдан матур бизәкләр ясый. Мич тә чыгара. Әле дистәдистә каен себеркесе җыеп сата. Эшләмәгән эше юк, – диде Нурия апа.

Ул да түгел, капкадан Наил абый үзе дә күренде.

– Кул эшләренә каян өйрәндегез? – дигәч:

– Әтием оста куллы иде, аннан күреп эшләдем. Ә мич чыгарырга әбием Зәйнәп өйрәтте, – дип елмайды.

Ананың бүген бердәнбер теләге – калган балалары кебек үк, Наилен дә башлы-күзле итү.

«СТАЛИН АЯГҮРӘ КУЛ ЧАПТЫ!»

Арыда яшәүче, чын мәгънәсендә легендар шәхес – Гарәфетдин Әхмәтҗанов турында күптәннән ишетеп белә идем. РСФСРның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек ул. Аксакалга март аенда 90 яшь тулган. Улы Илнур, килене Зөлфия тәрбиясендә яши икән. Авылның имамы булып тора.

Әхмәтҗановлар гаиләсенә барганда, авыл җирлеге башлыгы Хәмит абый Гәрәев:

– Авылда Гарәфетдин абый сүзеннән берәү дә чыкмый. Ул ничек әйтсә, шулай була, – дигән иде.

Аксакал безне егетләрчә каршы алды! Башында түбәтәе, кулында тәсбихе…

– Гарәфетдин абый, үзегез турында сөйләшкәнче, Арының элеккерәк чагын искә алыйк әле… Сездә шактый бай мәгълүмат бар дип ишеттем, – дим.

Шулай дигәч, аксакал калын бер дәфтәр чыгарды. Бактың исә, Гарәфетдин абый авылның башыннан, һәр йортны исәпкә алып, анда яшәүчеләрнең исем-фамилияләрен, шөгыльләрен теркәп бара икән. Элеккеге муллалар вазыйфасын үз өстенә алган.

– Минем дәфтәрдә 348 кеше язылган, – диде аксакал.

– Дәфтәрне кайчан алып бара башладыгыз? – дим.

– Сугыштан соң. Сугышка кадәр авылда 389 кеше булган. Ары тарихын язучы булса, шушы дәфтәрне бирер идем. Анда бөтен исемнәр дә төгәл язылган.

Гарәфетдин абый сугышта катнашмаган, шулай да ул елларның ачысын-төчесен татыган. Атаклы мари яклары – Суслонгерга окоп казырга да барган.

– Сугышка кадәр авыл бик көчле иде, – диде аксакал. – Алты бригада гына эшләде. Һәркайсында егермедән артык ат. Сугыш башлангач, иң яхшы атларны фронтка алдылар. Эшкә яраклы ирләр дә сугышка китте.

Мин 1943 елның октябрендә, колхозга бирелгән наряд нигезендә, Суслонгерга киттем. Аннан исән-имин котылгач, Марий Элның Шелонгер станциясендә агач ташыдым. Биш кубометр чыгарасың икән, ашарга талон бирәләр: атка – солы, үзебезгә 500 грамм ипи. Әгәр көнлек норманы үти алмасаң, атың да, үзең дә ач каласың. Көндез агач чыгарабыз, ә төннәрен болында ат саклыйбыз. Учак ягып киемнәрне утта тотабыз, шул рәвешле бетләрне коябыз. Ач, ялангач… Хәтта аяк чолгавы да туздЫ. Бервакыт качып та карадык, куып тотып, кире алып кайттылар. Аннан каты итеп кыйнадылар. Безнең белән Чепья кызлары да бар иде, аларны хөкемгә тарттылар. Бәхеткә, безнең яшь тулмаган иде, исән калдык.

Гарәфетдин абыйның әтисе Сәләхетдин Арыда гына түгел, Әтнәнең дә атаклы җырчысы, биючесе булган. Алма алмагачыннан ерак китмәгән, Гарәфетдин абый да җырлый, оста итеп бии. Үзенең 90 яшьлек юбилеенда сәхнәдә ут уйнаткан.

– Хәтта сугыш елларында да җыр-биюдән туктамадым, – диде аксакал. – Еш кына районга концерт программалары белән бара идек. Ә сугыш тукгагач, авылда ансамбль оештырдык. Ул вакытта дәүләт тарафыннан куелган таләп иде бу – халыкны сәнгатькә тартырга. 1947 елда, Әтнәнең үзендә смотр-концерт булды, анда районның һәр авылыннан килгәннәр иде. Һәм соңыннан, шушы авыллардан килгән җыючыларны туплап, янә бер ансамбль оештырдылар. Шулар арасына мин дә кердем. Республиканың кайсы гына почмагында чыгыш

4

АРЫ ТАРИХЫНЫҢ ИКЕ ВАРИАНТЫ БАР.

Мөгаллимә Миләүшә Вәлиева, төрле чыганакларга таянып, түбәндәге мәгълүматлар туплаган:

«Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» дигән китабында (Казан, 1995, 108 бит) Күлле Киме нәсел шәҗәрәсе бирелгән. Шәҗәрәдә, Бәерле авылыннан өч бертуган чыгып, шуларның Айтуганы – Каенсарга, Көнтуганы – Арыга, Иртуганы Күлле Киме авылына нигез салган, диелгән. Күчеп килгән туганнарының Айтуган исемлесе Каенсар авылы урынында торып калган. Көнтуган, арырак китеп, урман эчендәге күлләр тирәсенә төпләнеп, Ары авылын төзегән. Иртуган, Каенсардан азрак читкә китеп, Күлле Киме авылына нигез салган».

Авыл тарихының икенче вариантын Гарәфетдин Әхмәтҗанов сөйләде:

– Бирелә ар кабиләсе яшәгән. Иван Грозный Казанны басып алганнан соң, халык бу якларга күченгән. Авылның исемен дә элеккеге хуҗалары хөрмәтенә Ары дип калдырганнар. Һәрхәлдә, безгә бабайлар шулай дип сөйли иде. Бу расланган тарих түгел, халык телендә йөргән риваятьләр генә…

Фото: Александр Ефремов

1. Арча районының Печмәнтау авылынан килгәннәр иде, Разия Әхмәтова тиз генә аларга 21 каз бәбкәсе алып чыгып бирде.

ясамадык без. Казан сәхнәләрен дер селкеттек.

1948 елда Гарәфетдин абый сәхнәдәшләре белән Мәскәүгә бара. Ул көннәрне бүгенгедәй хәтерли ул:

– Россия күләмендә үзешчәннәрнең концерты иде ул. Башта бер ай Казанда репетиция ясап яттык. Безнең белән танылган композитор, режиссерлар эшләде. Атаклы балетмейстер Фәйзи Гаскәров биюгә өйрәтте.

Казаннан килгән үзешчәннәр беренче булып Мәскәүнең Зур театрында чыгыш ясый. Аннан Чайковский исемендәге концертлар залына баралар. Татар җыр-биюләрен халык аеруча яратып кабул итә.

– Инде кайтып китәргә җыенганда, Кремльдә чыгыш ясарга кирәк, диделәр, – дип сөйләде Гарәфетдин абый. – Ләкин анда кемнәр булачагын алдан кисәтмәделәр. Зур дулкынлану белән Кремль сәхнәсенә мендек. Гадәттәгечә җырлап-биедек. Халык дөррәү килеп кул чапты. Шул вакыт алгы рәттә утырган ил башлыгы – Сталинга күзем төште! Ул вакытта ниләр кичергәнне сөйләп аңлата торган түгел. Пәрдәне яптылар, алкышлар тынмый. Янә пәрдә ачылды, бөтен халык аягүрә баскан иде. Алар арасында Сталин да...

...Гарәфетдин абыйның Казан, Мәскәү сәхнәләрендә алган тәҗрибәсе юкка узмый – ул гомер буе Ары, Әтнә сәхнәсеннән төшми. Авыл клубында эшли. Бик күп балаларны сәнгатькә гашыйк итә.

«БЕР СЕЗОНГА 40 МЕҢ ЧЕБИ»

Арының янә бер тырыш гаиләсенә сугылдык – Илсур һәм Разия Әхмәтовлар. 2010 елда Казаннан туган авылларына кайтып төпләнгәннәр. Һәм... инкубатор сатып алып бәбкәләр, чебиләр үрчетә башлаганнар.

– 2009 елда Бәкер шифаханәсендә ял иттем, – дип сөйләде Илсур абый. – Шунда Башкортостаннан килгән бер эшкуар белән таныштым. Берничә инкубаторы бар иде аның. Эш тәртибе турында сөйләде. Миңа бу бик кызык тоелды. Безнең Әтнә якларында инкубатор тоткан кешеләр юк. Алынып карарга кирәк, дип уйладым. Бер ел эчендә интернет аша чеби, бәбкәләр чыгару буенча бик күп мәгълүмат таптым, кат-кат укып өйрәндем. Бер тапкыр Башкортостанга Бәкердә танышкан теге дустым янына барып кайттым. Һәм 2010 елда эш башларга тәвәккәлләдем.

Март аеннан бирле Әхмәтовларның инкубаторында 40 мең тавык чебие, 15 мең каз, 10 мең күркә, 5 мең үрдәк бәбкәсе чыгарылган. Инкубатор июль аена кадәр эшли икән.

– Сорау зурмы? – дим Илсур абыйга.

– Әйе, сигезенче сезон эшлибез бит. Бер килгән кеше ел саен ала. Әтнәдән генә түгел, Арча, Биектау, Балтач районнарыннан да киләләр.

Инкубаторга йомыркаларны фәкать сатып алалар. Үзләре дә барып ала, заказ биреп, махсус машина белән дә кайтарталар. Мисал өчен, тавык чебиләренең йомыркасы Чехиядән үк килә. Аерым шуның белән шөгыльләнүчеләр бар икән. Интернет аша заказ гына бирәсең.

– Халык хәзер токымлы бәбкә, чебиләр сорый, – ди Илсур абый. – Шуңа ел саен 10 дистәләп төрле йомырка алам, үстереп карыйбыз. Кешеләргә дә тәкъдим итәм. Әйбәт үссә, киләсе елга күпләп алабыз. Мәсәлән, быел кара каз – Ланда токымына сорау зур. Узган ел сатып алучыларга берәр Ланда бәбкәсе биреп җибәргән идем, халык яраткан. Тиз үсә, итләч, зур була.

Әхмәтовлар, фермер булып теркәлеп, дәүләттән грант алганнар. Шул акчага зур бина салып куйганнар. Ул бөтен таләпләргә туры китереп эшләнгән. Бина әзер инде, кош-кортларны гына күчерәсе бар.

Разия апаны күзәтәм: без сөйләшеп торган арада да әллә ничә эш башкарды. Бакчасына чәчәк тә утырта, чебиләр янына да чыгып керде. Арча районының Печмәнтау авылыннан килгәннәр иде, тиз генә аларга 21 каз бәбкәсе алып чыгып бирде.

– Өлгереп булмый, сеңлем, эш күп, – диде Разия апа. – Әле бакча да каралмаган. Сатып алучылар да килеп кенә тора, сезон бит.

– Шәһәрдән авылга кайткач, шулай инде ул, – дигән булам.

– Ирдән калу юк, нишлисең. Зарлану түгел бу, Аллага шөкер. Ялларга хатыннары белән ике улыбыз да кайта. Бергәләшеп эшләп атабыз аны.

Илсур абый кыш көне дә тик утырмый – атна саен Агропромпаркта тавык, каз түшкәләре сата. Анда да эшне җайлаган.

– Инкубатордан чыккан бәбкә, чебиләрнең барысы да сатылып бетми, – ди Илсур абый. – Ә аларны кая куясың? Үзеңә үстерергә кала. Шулай эшлибез дә.

«ЧӘЧҮНЕ СИЗМИ ДӘ КАЛАБЫЗ»

Арының иген кырларында да булдык. Яз соң килү сәбәпле, быел чәчү соңгарак калды. Май башына эшне тәмамлаган еллар булса, быел әле ул чорга аерым районнар кырга чыкмаган да иде.

Ары җирендә чәчүгә 8 майда керешкәннәр. Без килгәндә инде эшнең 60–70 проценты тәмамланган да иде. Ике атна дигәндә эшне төгәлләргә ниятлиләр.

– Без үскәндә чәчү ай буе бара иде. Авылның бөтен ир-аты кырда булыр... Хәзер чәчүне дә, урып-җыюны да белеп булмый. Кай арада башлыйлар, кай арада төгәллиләр. Басуга чыккан ир-атлар да күренми. Сездә дә шулаймы? – дим «Дусын» ҖЧҖ бригадиры Фәрит Сабировка.

– Чынлап та, хәзер кыр эшләре тиз уза, хәтта үзебез дә сизми калабыз, – дип елмайды Фәрит абый. – Төп сәбәп – техникада. Хәзер көненә 60–70 гектар чәчәбез. Элек 20дән артмый иде. Ул вакытта әле тәүлек буе эшләдек. Бүген трактористлар иртәнге алтыдан кичке унга кадәр кырда.

Ары басуында бүген 6 кеше эшли, шул бөтен чәчүне алып барырга җитә икән. Әлеге дә баягы, сәбәп – техникада. Элек гади тракторларның чәчкеченә бер әйләнгән саен иген салырга, арттан карап барырга кирәк булса, бүген андый мәшәкать юк. Чит ил техникасы, игенне бер тутыргач, дистә гектар җир чәчә (нинди культура булуына карап).

– Эш күпкә җиңел, – ди бригадир. – Ир-атлар, элеккеге кебек трактор артына басып, тузан иснәп йөрми, ашлама белән дә агуланасы юк. Дөрес, чит ил техникасы бик кыйммәт тора. Тик анысы – икенче проблема.

Проблема дигәннән, «Дусын» ҖЧҖ җәмгыятендә ягулык, чәчү орлыклары, ашлама – барысы да җитәрлек булган. Кредит алмаганнар.

– Аякта нык торабыз, хезмәт хакы түләргә, хуҗалыкны алып барырга да әлегә мөмкинлекләр бар, – диде бригадир.

Арыда безне авыл җирлеге башлыгы янә бер гаилә белән таныштырды – Гүзәлия һәм Рафыйк Фәйзрахмановлар. Гаилә башлыгы якындагы 7–8 авылдан сөт җыя икән. Берничә техникасы бар.

– Авыл юлларын карау гел Рафыйк өстендә, – диде Хәмит Гәрәев. – Әле дә ярый шундый кешеләр бар, нәрсә булса да, ярдәмгә киләләр. Берәр чараны уздырганда акчасын да, башкасын да бирә.

Фәйзрахмановлар гаиләсендә ике баһадир егет үскән, көрәшчеләр, районның атаклы җырчылары. Үзләре әйткәнчә, «картаеп барганда» гына өченче бала – көтеп алынган кыз алып кайтканнар. Рәлинәгә өч яшь икән. Бала туганчы Гүзәлия Фәйзрахманова камыр ризыклары пешереп сату белән шөгыльләнгән. 2014 елда хәтта зур пекарня ачкан булганнар.

– Пекарняны Казанда яшәүче энем белән төзегән идек, ике миллион ярымга басты ул, – диде Гүзәлия. – Матур гына эшләп алдык. Камыр ризыклары алырга тирә-як авыллардан да килделәр. Тик әлегә аны яптык, бала белән өйдә утыргач, өлгереп булмый. Киләчәктә нәрсә булса да уйларбыз.

...Кайбер авылларга аеруча сокланып, гашыйк булып кайтабыз. Әтнә районының Ары авылы да күңелдә бик җылы тәэсирләр калдырды. Татар халкына хас төп сыйфатлар – кунакчыллык, тырышлык, гадилек бар аларда. Авыл җирлеге башлыгы Хәмит Гәрәев кат-кат янә Арыга килергә чакырды. «Бездә җиләкнең нинди төре генә юк. Кая барсаң да җиләк аланлыгы», – диде. Шулай булгач җиләкләр өлгергәч очрашырбыз!

2. – Пекарняны Казанда яшәүче энем белән төзегән идек, ике миллион ярымга басты ул, – диде Гүзәлия Фәйзрахманова.

3. Арыда авыл җирлеге башлыгы безне Фәйзрахмановлар гаиләсе белән таныштырды.

АЙ КӘЕФЕ: **ӘТНӘЧӘ**

Безнең якларда искиткеч матур урыннар бар – кайдадыр аулак төбәкләрдә, авыл җирлекләрендә, урман-кырларда, исемсез инеш буйларында... Әгәр дә туктаусыз каядыр ашыгучы ватандашлары өчен бу гүзәллекләрне үзләренең киндерләрендә мәңгеләштереп калдыручы рәссамнар булмаса, аларны гомергә бер тапкыр күрми дә калыр идең.

Әтнәдәге гүзәллек без нәкъ менә шулай таныштык та инде. Илдар Вәлиуллин шактый еллар янгын сүндерүче булып эшләгән. Әмма янгыннарны сүндерүе аның күңелен инде балачагыннан ук биләп алган сынлы сәнгатькә мәхәббәт ялкынын сүндерә алмаган. Киресенчә, ул ялкын яктырак, көчлерәк булып үрли барган – һәм аның остаханәсендә Әтнә пейзажлары шулкадәр күп җыелган ки, авылдашлары рәссамның 60 яшенә «60 еллыкка – 60 картина» дигән күргәзмә оештырганнар. Әтнә кешеләре, гаҗәпләнеп, туган җирләренең таныш урыннарын, яраткан почмакларын танып алган, ә килгән кунаклар җирдәге иң матур урыннар белән танышкан. Илдар Вәлиуллин бик яратып һәм тырышып мәңгеләштергән Әтнә районы ул көннәрдә әнә шундый рәвештә җанланган.



ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2018 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 900 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 900 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

Реклама 16+

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Г. Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры. 2013 ел.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Г. Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры. 1928 ел.

Фото «Татарстан» журналы архивыннан.